Безнен
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
МИРАС
09
сентябрь 2022
ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР



Татар боцманматы
6 бит

Буа ягы – дини төбәк
59 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС

12 +

09
(345)
сентябрь 2022

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

26

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Гомәр Толымбай

ТАРИХИ МИРАС

4 Ничек славянлашканбыз һәм руслашканбыз? *А.Чанышев*
6 Татар боцманматы. *Г.Хисамиев*
10 Данияр хан. *Л.Гобәйдуллин*
12 Таһир Ильяси сәяхәтнамәсе. *Г.Хәйретдинова*
15 1922 ел сәфәре. *Т.Ильяси*
18 «Тәндә җан бар әле» *Э.Сабирова*
22 100 ел элек татар дөньясы
26 Коръән түгелме икән?
31 Мөхәммәдия. *Б.Урманче*

ТАТАР ГАМЕ

42 Ранис Камартдинов: «Булдыклы, фикерле кешеләр кирәк!»
47 «Безнең мирас» котлый!

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразыев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рузәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррирләр
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)
Айзилә Сабирова
(843) 222-09-83 (17-92)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

**«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)**

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ДИНИ МИРАС

48 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*

54 Морад Рәмзи хакында фикер-күзәтүләр. *Х.Миңнегулов*

59 Буа ягы – дини төбәк. *Р.Каюмов*

66 Тәрбия вә тәгълим. *Ф.Фәхри*

68 Дин галиме Нургали Хәсәнов. *Р.Амишов*

74 Ислам. Дини сүзлек

75 Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре. *Ә.Рәхими*

76 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ӘДӘБИ МИРАС

78 Нури Арслан

80 Татар шигъриятендә мөһаҗирлек хәрәкәте һәм Исхакый. *Т.Галиуллин*

86 «Кыйссасел-әнбия» һәм төрки дөнья. *Р.Исламов*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

92 Хаҗ сәфәре. *Л.Лерон*

96 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

98 Илһам абый. *Ф.Сәфәргалиева*

106 «Умырзая» җыры

ТАБИГЫЙ ЯДКЯРЛӘР

108 Усак

СИХӘТЛЕ МИРАС

109 Усак дәвалый

12

ТАТАР РИЗЫГЫ

110 «Май уны»ннан соң чәйгә тәмле сый

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре

118 Мирасворд

119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Сентябрь*



98

Заказ №О-2528. Тираж – 2255 данә. Формат 70х100 $^{1}/_{16}$
Басарга кул куелды: 29.08.2022. Чыгу көне: 05.09.2022.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә:
Бакый Урманче. «Татарстан» триптихыннан фрагмент. 1976 ел

Дөнья — иске морҗа, әйләнә дә төтен кайтара.
Гомәр Толымбай



Совет язучыларының Бөтенсоюз съездында.
Гомәр Толымбай (уңда) һәм Александр Серафимович. Мәскәү, 1934 ел

ГОМӘР ТОЛЫМБАЙ*

(14.04.1900-8.05.1938)

***

Яшь чагында тизрәк үсәсе, үсеп мыеклы буласы килсә дә, картаюга таба авыша башлагач, бер дә картаясы килми икән ул. Ә бер картая башлагач, картаясың килсә дә-килмәсә дә, картаясың икән аны.

***

Картаерга акча кирәкми.

***

Үгез чөя-чөя дә, өстенә чүп өя.

***

Аска имән, өскә нарат куеп бурагач, бура бик таза була. Икмәктән соң күмәч ашагач та шуның кебек ул.

***

Исән кешенең гомере бик тиз үтә икән шул. Бичара Ярхәм бабай: «Үлеп булмый да булмый. Сызлаган аяклар белән ятам да ятам. Төне дә ел, көне дә ел», – дип зарлана иде. Авыру кешенең гомере шулайдыр. Тиз үтмидер. Ә безгә, исән кешеләргә, таң ата да кич була, таң ата да кич була. Бер дә сөйләргә дә юк, майлаган көпчәк кебек тәгәрәп кенә тора: бүген монда, иртәгә тегендә, берсекөнгә әллә кайда. Шулай итеп, әссәламугаләйкүм, кабергә якыная барасың, якыная барасың… Ә картая барган саен, үләсе килмәү үзе тагын арта бара икән!

*Гомәр Толымбай (Габделхак Җәләлетдин улы Шаһиәхмәтов) – язучы, фольклорчы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, 1934 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы. 1900 елның 14 апрелендә хәзерге Татарстанның Буа районындагы Адав-Толымбай авылында туган. Репрессия корбаны: 1937 елның 8 июнендә кулга алына һәм 1938 елның 8 маенда атып үтерелә.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Ничек славянлашканбыз һәм руслашканбыз?

Айрат Чанышев

Варягларны каршы алу: «Земля наша велика и обильна, а порядка в ней нет. Приходите княжить и владеть нами». XV гасыр елъязмасыннан миниатюра

Татар-төрки теле кысрыклана башлый

Византия белән мөнәсәбәтләр ныгыгач, христиан миссионерлары Киев каһанлыгында актив эш җәелдереп җибәрәләр. Миссионерлар, нигездә, болгар һәм серб милләтеннән була. 988 елда Киев каһаны Владимир илдә кылыч һәм мәҗбүриләү юлы белән православие дине урнаштыра. Бу адым аңа Византия белән дуслашу, христиан Аурупа киңлекләренә чыгар өчен кирәк була. Иң бе-

ренче поплар да болгарлардан һәм серблардан тора, дини кулланма, догалар да шул телдә языла. Чиркәүләрдәге гыйбадәт иске славян телендә алып барыла. Шулай итеп, славян теле дәүләт теле буларак кулланыла, татар-төрки теле чикләнә башлый. Җирле фин-угыр һәм татар-төрки халыклары да, православиегә күчеп, әкренләп славянлаша.

Бу процесс хәзер дә дәвам итә...

Мәктәпләрдәге тарих фәнендә ниндидер мифик русичларның башка халыкларга даими рәвештә каршы торулары «урман» белән «дала»ның даими көрәше итеп тасвирлана. Чынбарлыкта исә Россия дип аталучы илнең бар тарихы да фин-угыр һәм татар-төрки халыкларының бертуктаусыз славянлашуы, соңрак руслашуы процессыннан гыйбарәт. Чудь, балт, мукшы, әрҗә, мерә, морама, мещера, бәҗәнәк, кыпчак, хәзәр, бродник, карабүрек, болгар, бортас һәм татарлар – барысы да славянлашуга йөз тота. Авылда яшәгәннәре дәүләт хезмәтенә керә, шәһәргә күченгәннәре дә 2-3 буын дәвамында славянлаша, соңгы гасырларда исә руслаша. Бу процесс 12 гасыр буена дәвам итеп, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән. Хәзерге гомумглобализация шартларында исә ул коточкыч тизлек белән барып, нәтиҗәдә, Россиядә яшәүче милләтләр инкыйраз упкыны алдында калды.

Россиянең тарих концепциясе ничек булырга тиеш?

Җөмһүриятнең рәсми тарих концепциясе буенча илнең төрле этник төркемнәре арасында дуслык-татулык, тарихи бердәмлек идеяләре таратырга, үзара бәйләнешләр, хезмәттәшлек, гомуми уңышлар, уртак тату тормыш пропагандаланырга тиеш. Ә бүгенге көндәге рәсми тарих концепциясе, илне берләштерәсе урынга, киресен эшли. Бу исә тарихка гына кайтып калмый, әдәбият, сәнгать кебек өлкәләргә дә үтеп керә. В.Янның киң таралыш алган өч томлыгы, «Орда», «Коловрат» кебек фильмнар берсе дә ил бердәмлегенә эшләми, чөнки бу вакытта илнең татар, нугай, калмык кебек халыклары гына зыян күреп калмый, хәзерге көндә Россиянең төп союзнигы булган Казакъстан кебек илләрдә яшәүче төрки халыкларның тарихи һәм милли горурлыкларын да кимсетә.

Рәсми дәреслекләрдә илнең тарихы бары тик Киев Русе, Московия һәм Россиянең үткәнен сөйләүгә генә кайтып кала. Башка рус булмаган халыкларның тарихы исә бөтенләй яктыртылмый. Күрсәтелгән очракта да алар Россиянең дошманы итеп кенә тасвирлана. Мәктәп дәреслекләре, тарих дәүләт төзүче бар халыкларның тарихи суммасы булырга тиеш! Биредә славян халыклары, фин-угырлар, татар-төркиләрнең тарихи җыелмасы булсын иде. Шул очракта гына җәмгыятебездә ике яклы гадел толерантлык мөнәсәбәтләре формалаша ала. Хәзәр каһанлыгы, Идел, Азак буе Болгарстаннары, шанлы төрки каһанлыклар да, кыпчак һәм бәҗәнәк ханлыклары, Алтын Урда, аннан соңгы татар ханлыклары һәм урдалары да тарих дәреслекләрдә урын алырга тиеш. Алар үзара дошманлык мөнәсәбәтләре яссылыгында түгел, ә мәдәният казанышы буларак яктыртылсын иде. Үзара аралашу, хезмәттәшлек, союзлар, сәүдә, гомуминтеграция моментларына күбрәк басым ясарга кирәк. Ниндидер мифик Куликово орышы, шыр әкият булган Угра буендагы каршы торыш, Ярмәк походлары кебек тискәре моментларны күпертеп күрсәтергә, андый уйдырмаларны илнең тарих концепциясенә нигез итеп салырга һәм башкисәрләрдән һич кенә дә геройлар ясарга ярамый! ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2022

Татар боцманматы

Галим Хисамиев*



Босфорда Кара диңгез флоты эскадрасы

1832 елда Мисыр Сүрияне басып ала. Төрек солтаны Мәхмүд II моңа ризасызлыгын белдерә, әмма бернинди чара да күрә алмый. Шул сәбәпле, Мисыр патшасы Мөхәммәд Гали төрек солтаны җирләренә басып керүен дәвам итәргә карар кыла. Госманлы империясенә бүленү куркынычы яный. Моны күреп, әле 1829 елда гына Төркия белән сугышудан туктаган Россия императоры Николай I төрек солтанына хәрби ярдәмен тәкъдим итә. Госманлы империясенең бүленеше, аеруча Франция белән Англиянең бу төбәктә йогынтысы көчәюе Россия өчен дә куркыныч була. Төрек солтаны моңа бик теләп ризалаша, аның мөрәҗәгатен истә тотып рус хәрби флоты кораблары Босфорга кузгала.

Мисыр-Төркия кризисын көйләүдә катнашу Россия империясе өчен бик файдалы була. Шуның нәтиҗәсендә, 1833 елда Өнкәр-Искелес солыхы төзелә. Бу

---

* Галим Хисамиев – Казан дәүләт медицина университеты доценты, химия галиме, төбәкне өйрәнүче.

эшләрнең башында тәҗрибәле дипломат, Госманлы хөкүмәте вәкилләренең һәм солтанның ышанычын яулаган кенәз Алексей Федорович Орлов тора. Ул Төркиядәге барлык рус хәрбидиңгез көчләре җитәкчесе, Россиянең Төркиядәге гадәттән тыш һәм тулы вәкаләтле илчесе итеп билгеләнә. Аңа ярдәмгә генерал-лейтенант Н.И.Муравьев җибәрелә.

Госманлы солтаны Мәхмүд II

1833 елның апрелендә Босфорда 3 эскадра – 10 кораб, 5 фрегат, 2 корвет һәм башка кораблар туплана. 10 меңнән артык Россия солдатыннан (8 батальон, 24 орудие, 1 казак сотнясыннан) торган десант Босфор буендагы Өнкә-Искелес (Солтан пристане) тирәсенә лагерь булып урнаша. Мисыр патшасы, Рәсәй белән сугышудан куркып, һөҗүмен туктата. Алдарак билгеләп үткәнчә, Төркия белән Мисыр арасында 4 майда солых төзелә. Аның буенча Төркия, төп җирләрен саклап калса да, Сүрия һәм Адан биләмәләреннән мәхрүм кала. 1833 елның 23 апрелендә А.Ф.Орлов Константинопольгә (Истамбулга) килә һәм солтан Мәхмүд тирәсендә бик мөһим кешегә әверелә. Аның исә төп максаты булып Петербургта әзерләнгән һәм 8 елга исәпләнгән Рус-төрек солыхы тора. Бу солыхка 1833 елның 26 июнендә кул куела. Аның нигезендә Россия-Төркия мөнәсәбәтләренә Көнбатыш Европа илләренең тыкшынуы тыела, ихтыяҗ туса, Россия Төркиягә хәрби ярдәмгә килергә дигән карар ята. Үз чиратында, Госманлы империясе дә хәрби конфликтлар туганда Дарданелль бугазын ябарга һәм чит мәмләкәтләрнең хәрби корабларын Россиягә таба уздырмаска тиеш була. Солых төзелгәннән соң, Россия төрек территориясеннән хәрби флотын һәм гаскәрләрен чыгарырга вәгъдә итә. Чыннан да, 28 июньдә рус гаскәрләре, Кара диңгез эскадрасы корабларына төялеп, Босфордан китә һәм 11 июльдә Феодосиягә кайта. Хәрбиләр анда 42 көн карантинда торалар, чөнки бу вакытта Константинополь тирәсендә кара үләт *(чума)* эпидемиясе тарала. Шулай итеп, әлеге экспедиция 3 ай дәвам итә.

Төрек солтаны Мәхмүд II рус солдатларына тараткан медаль

Экспедициянең уңышлы тәмамлануы уңаеннан, князь А.Ф.Орловка кавалерия генералы дәрәҗәсе бирелә. Сугыш беткәннән соң, солтан Мәхмүд рус экспедициясе десантын медальләр белән бүләкли. Генерал һәм адмиралларга бриллиант сибелгән (унлап), офицерларга алтын (250 тирәсе), ә түбән чиннарга көмеш (11 меңгә якын) медаль бирелә.

Медальнең алгы ягында лавр (дәфнә) веногы эчендә күппочмаклы йолдыз һәм солтан Мәхмүд туграсы урнаштырылган. Венок астындагы овал эчендә гарәпчә һиҗри белән «1249 ел» дип күрсәтелгән. Медальнең арткы ягында лавр веногы эчендә сигезпочмаклы йолдыз белән ярымай урнашкан һәм овал эчендә милади белән «1833 ел» дип язылган. Бу медаль Константинопольдә эшләнгән. Медальне кызыл тасмага тагу өчен уем да ясалган.

Шундый ук медальләр Россия тарафыннан төрек гаскәриләре өчен дә эшләнә: медальнең алгы ягында император таҗы астында Николай Iнең вензель сурәте куелган, ә икенче ягында лавр (дәфнә) венок эчендә «1833 ел» дип язылган. Медальләрнең диаметры 11/16 дюйм.

Россия тарафыннан төрек гаскәриләре өчен эшләнгән медаль

Боцманмат Габделкаюм Хәмит улы

Мисыр-Төркия кризисында Кыр Шонталысыннан боцманмат Габделкаюм Хәмит улы да катнашкан. Архив материалларыннан күренгәнчә, Босфор вакыйгаларындагы батырлыгы өчен ул көмеш медальләр белән бүләкләнгән. Сүзне тарихи чыганакка бирик әле: *«Боцманмат Каюм Хаметов сын Саетов из резервнаго полка 3 бригады. Имеются серебряные медали в память о пребывании в 1833 г. Босфор. вспомогательнаго отряда рос.войск и спасение погибавших».* [ТР Милли архивы, 1019 нчы фонд, 1 нче тасвирлама, 113 нче эш.]

Каюм ага, 25 ел хезмәт итеп, 1858 елның ноябрендә 44 яшендә туган авылына кайтып төпләнә һәм 1890 елда 75 яшендә вафат була. 1886 нчы елгы тарихи картага күз салсак, аның йорты хәзер Рәшит Дәмир улы Вәлиевнең нигезенә туры килгәнен күрәбез. Боцманматның тәрҗемәи хәлен, нәсел-нәсәбен болай тасвирларга мөмкин.

XVIII гасыр башында Кыр Шонталасы (элегрәк – Түбән Яңа Шонтала, Түбән Шонтала) авылына нигез салучыларның берсе – Казан губернасының Нугай

юлындагы Нарат Елга авылы кешесе морза Сәет Өмет (Имәмет) улы. Бу морза, чукынмау сәбәпледер, күрәсең, өстенлекләрен югалткан һәм күчеп китәргә мәҗбүр булган. Сәетнең кызы – Сәлимә (1756 елда туган), энесе – Колмәмәт (1711-1750). Колмәмәтнең балалары: Сәет (1737), Борһан (1739), Сәгыйть (1741), Хәлимә (1744; Көрнәле кешесенә кияүгә чыккан), Калимә (1747). Сәет Колмәмәтевнең балалары: Мәүлед (1760), Хәмит, Вәлит (1778-1833) һәм Мәҗит (1788).

Сәлимә Сәет кызы – ерак бабам Әбдерәхим Тимнәкәй углы Әбүбәкергә (1748 елгы) кияүгә чыга. Аларның Әбекәй (1776-1839) һәм Өмет (1785) исемле балалары туа. Әбекәйдән – Хәкимулла (1807-1867), Хәкимулладан – Хисмәтулла (1842-1924), Хисмәтулладан – Нигъмәтулла (1875-1942), аннан әниебез Фәризә (1922-1978) дөньяга аваз сала.

1788 елда туган Мәҗит 1811 елда рекрутка алынган. Указлы мулла Вәлитнең уллары – Бикмөхәммәт (1831 елдан авылның указлы имамы) һәм Мөхәммәтша (указлы мәзин).

Габделкаюмның әтисе – Хәмит Сәетов (1771), әнисе – Гөлминә (1776), абыйлары – Хәлил (1801-1838) белән Сәмит (1808), апасы – Хәдичә (1812) һәм энесе Габденнасыйр (1820-1866). Габденнасыйрның (хатыны – Гайшә Шәрипова) балалары: Габделкәбир, Габделвәли, Габделгалим. Габделгалимнең улы – Габделәхәт, ә соңгысының кызлары – гомерләрен авыл халкына белем бирүгә багышлаган мәшһүр укытучылар: Галимова Зәйнәп һәм Кәримә апалар.

Архив документлары күрсәткәнчә, Каюм Хәмитовның тормыш иптәше – Вафия Насыйрова (1828 елгы). Аларның Камалетдин (1850-1903; хатыны – Урта Тигәнәледән Әминә Әхмәдҗан кызы), Галәветдин (1865; хатыны – Көрнәледән Ягъфәр углы Сәедбатталның кызы Миңлеҗамал), Җәләлетдин (1868) исемле уллары, Бибимаһруй (1858; ире – Ярулла Мостафа улы) һәм Бибифатыйма (1867; 1898 елда Чистай өязендәге Чирүле Шонталасыннан Хәйрулла Вәлиулла улына тормышка чыга) исемле кызлары булуы мәгълүм. Күренгәнчә, Каюм аганың балалары тирә-як авыл кешеләре белән аралашкан: килен төшереп, килен алган. Олы улы Камалетдин кантончы булган.

Искәрмә

Боцманмат дәрәҗәсе 1720 елда Петр I тарафыннан кертелә. Бу – кече офицер дәрәҗәсе. Ул такелаж эшләрен башкара, рангоут төшерә һәм күтәрә, корабтагы барлык кораллар, компас һәм руль белән эш итә, паруслы шлюпканы йөртә, орудиеләр янында күнегүләргә өйрәтә, ярдагылар белән леер элемтә урнаштыра ала торган, кораб төбе тишелгән очракта су астында «пластырь» ябыштыра белгән хәрби диңгезчеләргә бирелә. Боцманмат – үзенә буйсынган түбән чиннарның кайда булуын, нишләвен, аларның тышкы кыяфәтенең, өс киеменең пөхтәлеген, савыт-сабаларының чиста булуын контрольдә тоткан, боцман вазыйфаларын үтәгән унтер-офицер. Түбән чиннар аңа: «Галиҗәнап боцманмат!» – дип эндәшә торган булган. ■

ТАТАР ХАННАРЫ

Данияр хан

Данияр (яки Даниял) хан – 1469-1486 нчы елларда Касыйм ханы, Касыйм ханның улы, Олуг Мөхәммәднең оныгы.



Данияр Касыйм углы. ***П.А.Панкин коллекциясеннән. Рәсем «Касимовские ханы и султаны» исемле календарьдан (редакторы – Д.В.Мөхетдинов) алынды.***

Рус кенәзе өчен хәрби хезмәт

Данияр тәхеткә әтисе Касыйм вафат булгач ук утыра. Тарихи чыганаклар тәүге мәртәбә бу шәхесне 1471 елда Мәскәү кенәзенең Новгородка сәфәре вакытында искә ала. Бу вакытта ул үзенең яраннары, кенәзләре һәм казаклары белән 14 июльдә булган Шелон сугышында катнаша. Әмма аның 40 кешесе һәлак була. Даниярга, барлык әсирләрне дә кире биреп, кайтып китәргә туры килә. 1472 елда Олы Урда ханы Әхмәт гаскәре белән Алексин шәһәренә килеп җитә, әмма, көчсезлеген чамалап, әсирлеккә төшүдән курка һәм качып котыла. Коломна шәһәрендә аңа каршы чыгучылар арасында Данияр җитәкчелегендәге касыйм татарлары да була.

Ә инде 1477 елда ул янәдән Мәскәүнең Новгород сугышларында катнаша, анда касыйм татарлары полкын җитәкли.

Тугры хезмәт өчен һәдия

Хәрби яктан әллә ни уңыш казанмаса да, Данияр рус кенәзләренең юмартлыгыннан читтә калмый. Мәскәү һәм Рязань кенәзләре арасындагы 1483 елгы килешүдә Данияр ханга Рязаньның иң яхшы җирләре бүләк итеп бирелү турында мәгълүмат бар. Данияр анда яшәүче мөселман, мукшы һәм мещеряклардан ясак җыйган. Иван IIIнең энесе Андрейның да Урда, Казан һәм Данияр ханга түләү өчен кенәздән 30 000 сум акча алганлыгы әйтелә. Болар барысы да Даниярның һәм аның әтисе Касыймның Мәскәү кенәзе Иван IIIгә итагатен һәм рус дәүләте алып барган сугышларда катнашканын истә тотып бүләк ителә.

Данияр хан яугирләре белән сугыш алдыннан

Данияр ханның исеме дәүләт ярлыкларында

Ярлыклардагы Данияр хан исеменә тарихчы В.В.Вельяминов-Зернов та игътибар итә. Ул «Исследование о касимовских царях и царевичах» исемле китабында: *«О жизни Данияра и об управлении его Мещерским Городком знаем мы очень мало. За все время от 1472 до 1477 г. упоминается о нем только в договорных грамотах великого князя Ивана Васильевича с братьями его: князьями Борисом Волоцким и Андреем Углицким 13 февраля и 14 сентября 1473 г., да еще в грамоте Крымского царя Менгли-Гирея, писанной им в 1475 г. великому князю Ивану. В договорных грамотах князья Борис и Андрей обязываются содержать в дружбе Данияра и всякого другого царевича, кто будет на его месте или кого великий князь и сын его сочтут за нужное принять в свою землю»,* – дип язып калдыра.

Нәсел киселү: улы Карахуҗаны немец табибы харап итә

Даниярның бердәнбер улы Карахуҗа 1486 елда Антон исемле табибның уңышсыз дәвасыннан вафат була. Шуңа үч итеп, Иван IIIнең фәрманы нигезендә, Антонны Мәскәү елгасында суеп үтерәләр. «Лекарь-немец Антонъ, лекарствами уморив Князя Татарского, сына Даниярова, был зарезан…» – диелә чыганакта. Карахуҗа Европа гадәтләреннән көлгән дә, Антон аны махсус үтергән дигән фикер дә бар. Нәтиҗәдә, нәсел өзелә һәм Касыймда Казаннан килгән ханнарны кырымлылар алмаштыра.

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2022

Таһир Ильяси сәяхәтнамәсе

Гөлназ Хәйретдинова[1]



Таһир Ильяси хатыны Нәгыймә белән

[1] Гөлназ Хәйретдинова – КФУдагы Халыкара мөнәсәбәтләр институтының Тарих фәннәре һәм Бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбе студенты.

1921-1922 нче елларда Идел-Урал төбәген биләп алган ачлык бөтен халык өчен авыр афәт була. Шул чорда ач торган халыкны коткару өчен зур көч куйган шәхесләрнең берсе – Таһир Ильяси.

1921-1922 нче елларда Таһир Ильясиның Төркиягә һәм Мисырга сәфәрендә язган сәяхәтнамә-көндәлеген бүгенге көнгә өч кенә кешенең укып, фәнни эштә файдаланганы мәгълүм. Боларның берсе – Т.Ильясиның кызы Нәҗия, икенчесе – А.Кылынч [2] һәм өченчесе – М.Әхмәтҗанов [3]. Нәҗия ханым әтисенең сәфәр көндәлеген бик пөхтә, матур итеп күчереп ала һәм КФУның Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенә тапшыра. Ә инде көндәлекнең асыл нөсхәсен Нәҗия ханым галим Марсель Әхмәтҗановка тапшырган. Көндәлекнең ксерокүчермәсе хәзерге вакытта Татарстан Республикасының Милли китапханәсендә саклана. Без әлеге хезмәтне шуның нигезендә әзерләдек.

Кем ул Таһир Ильяси?

Таһир Әхмәтҗан улы Ильяси 1881 елда Кузнецк өязенең Сүзүм волостендагы Индеркә авылында гади игенче гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне ул туган авылында ала, аннан соң (1893-1897 нче елларда) Хвалын өязендәге бер мәдрәсәдә укый. Таһир Ильяси гыйлем эстәүне Казанның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә дәвам итә. Биредә Фатыйх Әмирхан белән таныша һәм алар бик дуслашып та китәләр. Моны Ильясиның аңа язган хаты [4] да раслый.

Мөселман уку йортлары арасында иң зурысы һәм күренеклесе булган «Әл-Әзһәр» университетында (Мисыр) укыганда, Ильяси, гарәп теленең тарихын, диалектларын, яңа әдәби телен өйрәнеп, «Әл-Мөфид» сүзлеген [5] (гарәп әдәбияты хрестоматиясе сыйфатында) һәм «Әдәби кагыйдәләр китабы»н яза. Мисырдагы университетны тәмамлап кайту белән, Таһир Ильясины «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә эшләргә чакыралар. Ул монда гарәп телен һәм әдәбиятын гына түгел, математиканы да укыта башлый. Мәдрәсәдә мөгаллим булып йөргәндә Таһир бөтен мөселман дөньясында атаклы булган галимебез Шиһабетдин Мәрҗанинең оныгы Нәгыймә белән никахлаша. Бу вакытта аңа 35 яшь була.

1916-1921 нче елларда Таһир Ильяси Ырынбурдагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә мөгаллим булып эшли. 1921 елда кире Казанга кайткач, гарәп теле буенча профессор булып, Көнчыгыш телләре академиясенә эшкә урнаша.

1921 елда Галимҗан Баруди инициативасы белән Диния нәзарәте каршында Ач торучыларга ярдәм итү өчен махсус комиссия төзелә. Әлеге оешма вәкилләрен, ярдәм сорарга, дип, башка мөселман илләренә командировкага җибәрәләләр. Комиссия вәкиле буларак, Т.Ильяси Төркиягә бара. Төркия, үз дәүләтенең дә авыр хәленә карамастан, Идел буе мөселманнарына ярдәм күрсәтә. Таһир Ильяси бу эштә зур тырышлык куя, авыр чорда халкына ярдәм итәр өчен, хәтта чит илдә ач йөрергә дә әзер була. Кызганыч, хөкүмәт тарафыннан виза бирелмәве сәбәпле, Ильяси Мисырга ярдәм сорарга бара алмый кала. Ләкин аның эчке торышын,

---

[2] İlyasi T. İstanbulhatıratı. 1922 / Neşrehaz. A. Kılınç. – İstanbul: Kırmızıkedi, 2019. – 162 s.
[3] Әхмәтҗанов М. Тәкъдиргә лаек мирас. // Шәһри Казан. – 17 сентябрь, 2005. – Б.2; Әхмәтҗанов М. Таһир Ильяси. // Гасырлар авазы – Эхо веков. – 2010. – №3/4. – Б.167-170.
[4] Галимҗанова Э. Таһир Ильяси хаты. Б.174-175. Рухи мирас: эзләнүләр һәм табышлар: [Җыентык]. – Казан: ТР Фәннәр акад. Г.Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать ин-ты, 2016. – 2 бүлек. – 300 б.
[5] Ильяси Т. Ә. Әл-мөфид. Гарәпчә-татарча мөкәммәл лөгать китабы. 1 бас. – Казан, 1912. – 824 б.

Халыкара ислам конференциясеннән кайтканда (уңнан сулга): Муса Бигиев, Хаҗи Мөслих, Кәшшаф Тәрҗемани, Мәһди Маһкалый һәм Таһир Ильяси. Истанбул, 1926 ел

тәрҗемәи хәлен өйрәнгән кеше: «Шөбһәсез ки, бу галим Мисырга барып та шундый ук зур тырышлык күрсәткән булыр иде», – дип фикер йөртер.

Төркиядәге вазыйфасын намус белән башкарып кайткач, Т.Ильяси 1922-1929 нчы елларда «Мәрҗани» мәчетендә имам булып хезмәт итә. 1929 елда ул кулга алына һәм Себергә җибәрелә, Беломорканал төзелешендә эшли. Таһир Ильяси Вологда өлкәсенә мәңгелек сөргенгә барганда каты авырып китеп вафат була.

***

Т.Ильясиның чит илгә эш сәфәре барышында язган сәяхәтнамә-көндәлегендә Диния нәзарәте эшчәнлеге генә түгел, Русиянең укымышлы мөселманы карашыннан үткәрелеп, шул заманның чынбарлыгы да чагыла. Анда шулай ук авторның беркадәр биографиясе дә, аның дөньяга карашы, холкы, төрле вакыйгакүренешләргә карата уй-фикерләре, хис-кичерешләре дә яктыртыла. Ул гына да түгел, чит илгә чыгып китәр алдыннан да, сәфәрдә вакытта һәм барып җиткәч тә нинди авырлыклар аша үткәне – болар барысы да энәсеннән җебенәчә шушы көндәлектә тасвирлана.

Таһир Ильяси сәяхәтнамә-көндәлегенең Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә сакланган нөсхәсе *(саклану шифры – 4361т)* безнең тарафтан хәзерге татар графикасына күчерелде. Укучыларга әлеге көндәлектән бер өзек тәкъдим итәбез. Тексттагы тыныш билгеләре безнең тарафтан өстәлде.

1922 ел сәфәре

Таһир Ильяси

Без Казанга сентябрь 13ендә ирешеп, 16сында җомга намазыннан игътибарән 17 нче мәсҗиде җамигъда имамлык хезмәтләре кылырга һәм Шәрык телләре академиясендә (шулар арасында мин дә бар) профессорлар рөтбәсендә *(дәрәҗәсендә)* тәсдыйк кылдырып *(раслатып)*, профессорларга хас паек чыгартты, бөтен мөгаллим вә профессорлар шушы паекны ала алсалар, үзләрен бик бәхетле саныйлар иде. Бер айга алган паегыбыз шушыннан гыйбарәт: 1) утыз кадак арыш оны; 2) ун кадак тары ярмасы; 3) биш кадак борчак; 4) бер кадак сабын; 5) сигез кадак селедка балык; 6) әшмүха кадак чәй; 7) ике әшмүха махорка тәмәке; 8) ике тартма шырпы; 9) ике кадак ландрин, бусы шикәр урынына простой мампасье иде; 10) бер кадак сары май. Булды. Бу паекны алган көн зур шатлык булды. Мөгаллимнәр бер-берсенә: «Әле син алдыңмы, теге алдымы?» – дип хәбәр итешәләр, «Әмма шәп булды!» – дип шатланып мактап куялар иде. Шушы паекка камил бер ай хезмәт кылырга тиеш иде. Бу паек ялгыз мөгаллимнең үзенә бирелә, ничә адәм булсалар да, гаиләсен дә шуның белән тәрбия итәргә тугры килә иде. Хариҗдән *(тыштан)* акча вә азык тәдарек итә *(әзерли)* алмаган мөгаллим-профессорларның кыш чыгуы соң дәрәҗә авыр булды, ачлык корбаны булып китүчеләре дә аз булмады. Мәшһүр мөстәшрикъ *(Көнчыгыш илләре һәм телләре белгече)* Катанов шул корбаннардан саналадыр. Шәрык академиясендә гарәп теле мөгаллиме-профессоры уларак Катанов илә икәү тәгаен ителгән идек. Ул рус балаларына, мин татар балаларына дәрес бирүне алып, эшне юлга салган идек. Озак вакытлыча мин истигъфа кылдым *(хезмәттән азат ителдем),* бөтен шәкерт Катановка калды. Ул да озак дәвам итә алмады, фалиҗ *(паралич)* булып, ниһаять, дөньядан китте, фалиҗеннән сәламәтләнергә дә исәбе бар иде, ачлыкка корбан булды.

Егерме беренче ел ачлыгы Казан әтрафында июнь башларыннан ук башланды, көннән-көн үзенең дәһшәтен арттырып, ачлык корбаннарын алырга, тиф, ваба вә башка мөһлик *(үлем китерүче)* авыруларны таратырга башлады. Шәһәр вә авыл кешеләреннән йөз меңләрчә адәмнәр, капчыкларын күтәреп, ашлык булган губерналарга барып, мең төрле мәшәкать белән юлларда йөреп, ике-өч пот азык табып кайталар, үзләрен һәм гаиләләрен ачлык афәтләреннән коткарып калырга тырышалар иде.

Хөкүмәт тарафыннан ачларга ярдәм комитетлары төзелеп, ачларга бик зур күләмдә ярдәм иделергә башлады. Америкалыларның «АРА»лары йөз меңләрчә ашханәләр ачып, ачлык губерналарының һәркайсында миллионларча балаларга аш бирергә тотынды. Болар балаларга ярдәм кеби булса да, күп йирдә «АРА» ашханәләре аркылы миллионларча дәү кешеләр дә туенып чыкты. Немецлар килеп, хастаханәләр ачып, һәртөрле тыйбби ярдәмнәр биреп, йөз меңләрчә иң зәгыйфь балаларга «Нестле» вә әмсале *(шуның кебек)* туклыклы матдәләр таратып торды. Шөбһәсез, боларның ярдәмнәре бик зур иде, шулай да ачлык афәтләре бик киң рәвештә – утыз миллион чамасында адәмне каплап алган хәлдә таралганлыктан, егерме икенче ел июль башларынача *(бер ел артыграк)* миллионларча адәмләр ачлык белән кырылып та бетте.

Югарыда сөйләнгән капчыкчылар үзләреннән арткан азыкларын базарга чыгарып, Казанда кыш буенча сатып тордылар. Акча таба алган адәмләргә азлап

сатып алырга мөмкин булды. Шуның аркасында Казан халкы кырылып бетүдән сакланып калды. Фәкать акча табу соң дәрәҗә авыр иде. Акча табар өчен бөтен мәнкулатын *(күчмә милек)* сатып бетергән йорт хуҗалары йорт-йирләрен сатарга да кереште. Йорт-йир бәһаләре әйбер бәһаләренә караганда да бик күп арзан йөри иде. Хәтта ике-өч катлы мөкәммәл йортлар сатыла, миллион-миллиард исемнәрендә бер кочак акча бирелә: хәлбуки шул кәгазь акчаларны алтын акчага кайтарып караса да, өч йөз-дүрт йөз сум кыйммәтендә генә була иде. Бер кешенең кулында ничек булса, биш йөз сум алтыны булса, бу кеше инде борын заманның 25-30 мең сум торган таш пулатын сатып ала ала иде. Һәм шулай бик күп мөселман сәүдәгәрләре (боларның күбесе азык сатучы капчыкчылар, чөнки алар килтергән азыклар бәрабәренә капчыкларын тултырып кәгазь акчалар һәр йирдә мәкъбүл булып йөри иде, базарда башка акча юк иде) Казанның рус ягыннан рус йортларын сатып алып калдылар. Кабан күленең рус ягында мөселман йортларының күбәюен игътибарга алып, бик әгъля *(яхшы)* бер мәсҗед салырга да шул чакта ук керешелде, бу мәсҗед бик мөкәммәл булып тәмам булды [6]. Дөрест, ялгыз ачлык мәҗбүрияте белән фахиш арзанча сатылган йортларны иске хуҗаларына кире кайтарырга хөкүмәтнең низамы да чыкты. Шулай да бу мөселман сәүдәгәрләренең күбрәге алган йортларында низамән дә урынлашып калды. Чөнки болар, авылларда булган кеби, йортларны ике-өч пот онга гына алмаганнар, бәлки, 20-30 мең сумлык йортларга өч-дүрт йөз сум микъдарында алтын яки шуның кыйммәтендә булган берничә капчык кәгазь акча биргәннәр иде.

Алтын-көмеш акча һәм алтын-көмештән ясалган әйберләрне сатарга низамән ярый идеме яки ярамый идеме – ансын белмим, әмма болар сатылып тора иде. Һәм төрле шәһәрдә бәһаләре төрлечә була иде. Төркестан якларыннан җыеп кайтучылар байтак табыш белән Казанда саталар, Казан кешеләре, байтак табыш алып, Мәскәүдә сата иделәр. Шулай алтын-көмешне кулдан-кулга, шәһәрдән-шәһәргә күчереп, сатып, табыш идеп тора иделәр: шунлыктан даимән боларның бәһаләре үзгәреп, күтәрелеп бара иде. Егерме беренче ел көз көне Казанда ун сумлык алтын тәңкә – ике йөз мең сум, ноябрьдә – биш йөз мең сум, гыйнвар тирәсендә – миллион сум, март тирәсендә – йиде-сигез миллион сум, май тирәсендә унбиш-егерме миллион сумга сатылды. Бу бәһаләр даимән күтәрелеп торган төсле, бәгъзе вакытта төшеп, арзанаеп та китә иде. Озын сүзнең кыскасы: шул ачлык, шул бөлгенлек елында азык бәһаләре күтәрелеп торганы төсле, алтын бәһаләре дә гаять сөргатьле *(тиз)* күтәрелеп торды,

> **«Бер кешенең кулында ничек булса, биш йөз сум алтыны булса, бу кеше инде борын заманның 25-30 мең сум торган таш пулатын сатып ала ала иде. Һәм шулай бик күп мөселман сәүдәгәрләре (боларның күбесе азык сатучы капчыкчылар, чөнки алар килтергән азыклар бәрабәренә капчыкларын тултырып кәгазь акчалар һәр йирдә мәкъбүл булып йөри иде, базарда башка акча юк иде) Казанның рус ягыннан рус йортларын сатып алып калдылар.**

[6] Сүз Кабан арты мәчете турында бара.

азык бәһаләреннән калышмады. Бер данә ун тәңкәлек алтын илә һәрвакыт бер поттан артыграк богдай оны алып булды. Йортында мең сумлык *(алтын белән)* мебеле булган адәмгә караганда, кесәсендә ике-өч данә унарлык алтыны булган адәм бәхетлерәк иде. Тегесе мебеле илә тиз генә бер пот он тәхсыйль итә *(кулга төшерә)* алмый, ә бусы алтыны илә һәрвакыт таба вә ала иде. Фәкать эш шунда: түгәрәк алтын тәңкәләр сәүдәгәрләр кесәсеннән дә тәгәрәп төшкән, меңгә берсендә генә калган иде. Һәм шунсы да бар, халык кулында алтын тәңкә булган булса, алтын бу кадәр бәһале булмаган булыр иде.

Менә, шушындый бер вакытта миңа сәфәр итәргә тугры килде. Мин Мисырга барырга билгеләнгән идем. Мисыргача юл мәсарифе *(чыгымы)* алтын белән өч йөз-өч йөз илле сумнар булганлыктан, бу акчаны Казаннан да, Мәскәүдән дә тәэмин итәргә мөмкин түгел иде. (Югарыда сөйләнгәнчә, ул вакытта бу акча фәүкальгадә *(гадәттән тыш)* зур бер сумма таш пулат бәһасе булырлык микъдар иде.)

Шунлыкдан минем юл мәсарифен фәкать Истанбулгача тәэмин итеп, Истанбулдан соңгы мәсарифне тәэмин итүләрен үтенеп, Истанбулда Һилалы Әхмәр [7] идарәсенә язачак иделәр. Минем Истанбулгача булган мәсарифне Казан мөселманлары өстләренә алдылар. Башка вәкилләрнең мәсарифләре Мәскәү халкыннан җыелган иганәләрдән тәэмин ителде. (Ачларга ярдәм комитеты Кашшаф хәзрәтләр [8] тарафыннан ачылгач та, Мәскәү халкыннан акчалата-әйберләтә байтак иганә җыелган. Бу әйберләргә берничә мәртәбә латарей дә ясадылар. Шул акчалар комитетның эшләрен юлга салырга, вәкилләрне дә, Мәскәүдә торучы ярдәмчеләрне дә тәэмин итәргә тотылды. Бу иганәләр баштан ук шуны күздә тотып җыелган иде. Бу елларда Мәскәү мөселманлары һәр йиргә караганда да баерак иделәр һәм шул байлыклардан аямыйча күп-күп ярдәмдә дә булдылар.)

Казан мөселманлары шул елга күрә бик зур һиммәт *(тырышлык)* күрсәттеләр, миңа Истанбулгача юл мәсарифе уларак бер йөз егерме миллион сум кәгазь акча һәм ун данә унарлык *(бер йөз сум)* алтын бирделәр. Иганә җыю эшләрен Исхак әфәнде Карташов башкарды. Миңа бирергә дип һәрбер унлыкны егерме бер миллион сумга алганлыкны сөйләде.

Үземнән соң гаиләмне тәэмин итүне һәм өстләренә алган иделәр, мин сәфәрдә вакыт байтак җыеп гаиләмә тапшырганнар. Сәфәрем мөнәсәбәте һәм бәйрәм көннәренең гадаты *(гадәте)* уларак, хассәтән *(аеруча)* мәхәллә әһеленнән җыелган акчалардан, гаиләмә бер йөз миллион артыграк биреп киттем.

Югарыда дигәнемчә, июнь 2сендә җомга көн мәхәлләмә дә, гаиләмә дә катгый сәфәремне белдереп, шимбә көн китәчәк поездга билет алу чарасына керештем. Мәскәүгәчә сәфәр юлдашым Салихҗан бине Вилдан әл-мөәззин Әмирханов булачак иде. Билет-урын эшләрен ул башкарды. Мәскәүгәчә тимер юл билеты уналты миллион иде, йөз мең сумга алынды. Юлда җиңел булсын өчен бик аз әйбер, юлда моталәгә *(уку)* өчен берничә генә китап алдым. Нәгыймә бәйрәм ашлары калдыклары һәм бер савыт бал катыш май вә җитәрлек азыклар куйды. Шулай һәр яктан хәзерлек тәмам ителде. ■

---

[7] Һилал Әхмәр (Кызыл Ярымай) – Төркиядә хәйрия җәмгыяте (1868 елда Госманлы империясендә оеша).

[8] Кашшафетдин Кыяметдин улы Тәрҗемани (1877-1943) – 1921 елның азагында Г. Баруди тарафыннан оештырылган Үзәк Диния нәзарәте каршындагы Ачларга ярдәм итү комитетының рәисе.

«Тәндә җан бар әле»

(Буага Беренче бөтендөнья сугышыннан хатлар)

Энҗе Сабирова

Казан федераль университетындагы Фәнни китапханәнең Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлегендә Беренче бөтендөнья сугышында әсирлеккә төшкән Әхмәдтәүфикъ Вахидовның хатлары саклана. Алар Германиядән һәм Австриядән Буа районының Яңа Тинчәле авылында яшәүче әти-әнисенә, туганнарына адресланган. Барлыгы – 18 хат. Шуларның тугызы – рус телендә, калганнары – гарәп графикасында татарча язылган. Хатлар 1914 ел белән башланып, 1918 елның 7 августы белән тәмамлана. Эчтәлегенә килгәндә, аларда сугыш хәлләре, әсирләр тормышы турында әйтелмәсә дә, һәрдаим посылка сорап язуы, хатларда еш очрый торган «тәндә җаным» гыйбарәсен куллануы хәлләренең җиңел булмавы турында сөйли. Хатларда Әхмәдтәүфикънең әти-әнисенә, туганнарына, күрше һәм таныш-беләшләренә ягымлы сүзләре, әдәби һәм матур теле игътибарга лаек.

Әхмәдтәүфикъ Вахидовның язмышы турында бездә мәгълүмат юк диярлек. Шулай да аның әсирлектән авылына исән-сау кайтуы һәм 1969 елда әлеге хатларны үз кулы белән китапханәгә тапшыруы билгеле. Мөгаен, ул мәдрәсә бетергән, рус телен яхшы белгән, үзе дә язу-сызуга оста һәм татар әдәбиятын һәрдаим укып баручы зыялы кеше булгандыр.

Игътибарыгызга әлеге коллекциядән берничә хатны тәкъдим итәбез. Авторның тел-стиль үзенчәлекләре тулысынча саклана.

«Дорогие родителья!

Приехал я в Германию. Я здоров. Дорогая мать, присылаю Вам поклон. Дорогому брату поклон. Ваш сын Тауфик. 1914».

***

«Здравствуй, дорогой мой брат Юнус! Посылаю Вам с супругой вашей братское почтение, с любовью низкий поклон и желаю от господа Бога доброго здоровья, всего хорошего на свете. Затем сообщаю я вам, дорогой мой брат, свое нахождение, я в настоящее время нахожусь в плену у Австрии, жив и здоров, чего и вам желаю от господа Бога, доброго здоровья, всего хорошего на свете. Затем прошу вас что [в] деревню пишите письмо, мать мою не забывайте, жив буду приеду?.. Я вас век не забуду, остаюсь любящий вас твой брат Тауфик Вахитов. Апреля 17 д. 1915 г.»

***

«1915 года июня 28го дня многоуважаемым и дорогие мамаша и всем родным от вашего сына Тауфика. Спешу я Вам послать свою сыновскую глубочайшие почтения и желаю Вам всего хорошего. Затем уведомляю Вас, что мы находимся военном плену Австро-Венгрии. Живы и здоровы, славо Богу, чего и Вам желаю. Затем покорнейше прошу Вас по получению моего письма, пишите ответы, что вас там есть. Затем кланяюсь Хабиру от Шайхутдин, который это письмо писал. Пишите письмо на это открытку, который написано обратный адрес».

***

«Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле улып торгучы әнкәем хозур шәрифләренә сагынып бик күп сәламнәребезне ирсаль вә тәблигъ әйләдем. Вә бәгъдә Хәбир әбзәйгә җәмәгате берлән сагынып, күп-күп сәламнәребезне күндердем. Вә бәгъдә сеңлем Галиягә бик сагынып күп сәлам күндердем. Вә бәгъдә Галия сеңлем берлә Әсма сеңлемә кияве берлән сагынып күп сәламнәр күндердем. Вә бәгъдә энем Хәмидкә сагынып, күп-күп сәлам күндердем. Вә бәгъдә тирә күршеләргә һәм безне сораган дусларга безләрдин сагынып, күп сәламнәр күндердем. Вә бәгъдә үзебезнең әтрафтан сөаль идерсәгез, әлхәмделилла, тәндә җан. Бәгъдә сезләрнең сәламәт булуыгызны бер Алладин сорыйбызлар вә бәгъдә үзегездән майдан бирле хат алганым юк. Салмыйсызмы яки салып җитмәйме, шуны аерып язасызлар. Вә бәгъдә хат язганда Хәбир әбзәйнең кайда икәнлеген мәгълүм итеп язасызлар. Вә бәгъдә үзегезнең җибәрелмеш акчагызны алганым юк. Үзегез почтадан тикшертеп карагыз. Бәгъдә үзегезнең посылкагызны алдым июньдә. Шуннан соң һич хәбәрегез юк вә бәгъдә бу хатны алгачтан, мөмкин булса, тизләп каршы хат язуыгызны үтенәбезләр. Бәгъдә Солтангәрәйгә, Мөәсыйлә абыстайга барча җәмәгатегез берлән сагынып күп сәлам күндердем һәм башка агылдашларга күп сәлам. Бәгъдә аръяк кодаларга барча җәмәгатьләре берлә күп сәлам күндердем. Язылды 1916 ел, 20 октябрь. Хуш, сау булыгыз. Вәссәлам. Тәммәт».





Abender:
Отправитель
Correspondance des prisonniers de guerre
АВСТРО-ВЕНГРІЯ
Carte postale
Adresse
Адресъ
WIEN
Portofrei
Безплатно
Verlag der österr. Ges. vom „Roten Kreuze"
Изданіе Австр. Общ. Краснаго Креста.
Nachdruck verboten
Перепечатка воспрещается
Preis 3 Heller per Stück

Absender
Отправитель
Mittente
CORRESPONDANCE DES PRISONNIERS DE GUERRE
KRIEGSGEFANGENEN-KORRESPONDENZ
CARTE POSTALE
Адресъ
Indirizzo
Naslov
K. u. K. Kgf. Arb. Detachement
in
FELDBACH (Steiermark)
RUSSLAND

***

«1917 ел, 20 гыйнвар.

Әссәламе галәйкем вә галә мин ләдәйкем, сезки гыйззәтле вә хөрмәтле улып торгучы әнкәем хәзрәтләренә безки угылыгыз Әхмәдтәүфикътан бик сагынып вә бик ирегеп бик күп сәламнәребезне ирсаль вә тәблигъ әйләп, хәердогаларыгызны үтендем. Вә кинә Габделхәбир әбзәйгә бик сагынып, бик ирегеп бик күп сәламнәребезне күндердем. Вә кинә җиңгәчигә һәм энем Габделхәмидкә бик сагынып, бик күп сәламнәребезне күндердем. Вә кинә сеңлем Бибиәсмага һәм киявенә бик сагынып, бик күп сәламнәремне күндердем. Вә кинә сеңлем Галиягә бик сагынып, бик күп сәламнәремне күндердем. Вә кинә үзебезне сораган агай-энеләргә һәм дуст-ишләргә бик күп сәлам диясезләр. Вә кинә үзебездән сөаль кылсагыз, әлегә тәндә җан бар әле. Моннан соң, Аллаһ нәкыйдер вә бәгъдә әнкәй сиңа сүзем шулдыр, зинһар, дип, еглап сорыйм, миңа һәр айда ике мәртәбә посылка җибәр. Үдәге кара икмәк сохари ясап һәм тәмәке җибәрегез. Тик, зинһар, ташлый күрмәгез, тәмәке үзем тартмасам, файдасы күптер. Акча җибәрмәгез. Акчаны алуы кыен. Үзегездән майдан салган посылкагыздин башка бернәрсә дә алганым юк. Хат та алганым юк. Хат ешрак салыгыз. Һәм Хәбир әбзәйнең кайда йөргәнен һәм ни хәлдә икәнен языгыз. Үзебезнең авылдан дүртәү торабыз бер лагерьда. Һәм Җинай Ибраһим да минем берлә бергә һәм идә күп сәлам. Сагынып язгучы Әхмәдтәүфикъ дип белерсез».

***

«Сезки гыйззәтле вә хөрмәтле улан әнкәем хозур шәрифләренә безки угылың Әхмәдтәүфикътан бик сагынып, бик күп сәламнәребезне ирсаль вә тәблигъ идәм вә бәгъдә Хәбир әбзәйгә җәмәгате берлән сагынып бик күп сәлам күндердем. Вә бәгъдә сеңлем Галиягә бик сагынып күп сәламнәр күндердем. Вә бәгъдә сеңлем Әсмага киявене берлән сагынып күп сәламнәр диясе. Вә бәгъдә үзебезнең тарафтан сөаль шәрифләрегез улына калса, әлхәмделилла, сау-сәламәт дип беләсезләр. Вә бәгъдә үзегезнең җибәрелмеш хатыгызны һәм посылкагызны алдым. Аллаһы Тәгалә рәхмәт әйләсен безне искә төшергән өчен бала итеп. Бәгъдә акчагызны алганым юк, әле сау булсам алырмын, Алла теләсә. Бәгъдә, әнкәем, бу хатны алгачтан, мөмкин булса, зинһар, янәдән посылка саласызлар, аена ике мәртәбә икмәктән киптереп сохари җибәрегез. Әнкәем, авыр булса да, бер вакытка чыдагыз. Бәгъдә, әнкәй, Хәбир әбзәй хәзерендә кайда йөридер, сау-сәламәтме, аерып языгыз вә бәгъдә җиңгәчигә баласы берлән күп сәлам күндердем. Җиңгәй удә торамы, шуны языгыз, сәлам язмаган. Бәгъде Солтангәрәйдән Мөәсыйлә абыстайга, җәмәгатьләрегез берлән күп сәлам күндердем. Вә бәгъдә бу хатны алгачтан, Мөәсыйлә әби, безнекеләргә әйт, посылка салыгыз икмәктән киптереп, җәлләмәгез. Үзебез сау-сәламәт, сезләр дә сәламәт булгай идегез. 1917 апрель 5ендә вәссәлам».

***

«Дорогая мамаша!

Шлю Вам и родному братцу Хабиру сердечный привет и сообщаю, что я до настоящего время здоров. Нахожусь в настоящее время в Германии в плену. Нас здесь двое: я и Рахимджан. Сын Ваш Тауфик. 7 августа 1918». ■

100 ел элек татар дөньясы

Кәрим Тинчурин хатыны Заһидә ханым белән. 1920 ел, 18 март

Балаларны кире кайтару

Татарстан Мәркәз Башкарма хозурындагы балалар тормышын яхшырту комиссиясе, иптәш Казаковның балаларны кайтару һәм аларны урнаштыру өчен биналар төзәтү хакындагы докладын тыңлаганнан соң, түбәндәге карарны чыгарды: 1) хәзерге вакытта фәкать 5000 кадәр бала гына кайтарырга мөмкин булганга күрә, беренче нәүбәттә крестьяннарга таратылган татар балаларын кайтарырга; 2) балалар йортларын төзәтү өчен материаллар сатып алырга (беренче нәүбәттә Мәгариф һәм Сәламәтлек саклау халык комиссариатлары карамагында булган йортлар һәм элекке Архирей һәм губернатор йортлары төзәтелергә тиеш); 3) балаларны кантоннарга кайтару өчен мәркәздән 25 миллиард акча сорарга*.

«Татарстан». – 1922. – 4 сентябрь.

* Биредә сүз ачлык вакытында Урта Азиягә, Себергә һәм башка төбәкләргә җибәрелгән Татарстан, нигездә, татар балалары хакында бара. – *Ред.*

Шәрык революционеры Мулланур Вахитов исеменә шифаханә

Шәһәрнең татарлар тора торган ягында рәтле бер шифаханә булмавы, шәһәр шифаханәләренең юклыгы, аның өстенә, бик күп авыруларның русча белмәүләре аркасында кирәгенчә тыйбби ярдәм ала алмаулары Иске бистәдә яхшы бер шифаханә ясарга кирәклек фикерен күптән тудырган иде. Башлап бу эшне гамәлгә куюны Казандагы «Татар табиблары түгәрәге» үз өстенә алды. Шул түгәрәк 1920 елдан башлап уңайлы бер йорт эзләргә тотынып, ниһаять, Тукай урамында, Мулланур Вахитов мәйданында 29 нчы йортны (электә Бәдри Апанаев йорты) алды.

Ләкин 1921-1922 нче еллар Татарстан Җөмһүрияте өчен авыр еллар булу, хөкүмәтнең иң күп көче ачлык белән көрәшкә сарыф ителү, шуның өстенә, яңа икътисади сәясәтнең килеп чыгуы шифаханәне торгызу эшен гаять авыр хәлгә куйды. Бөтен эш Татар табиблары түгәрәгенең үз өстенә төште. Шуның өчен спектакль кую юллары белән акча җыярга керешелеп, гыймарәт *(ремонт)* эшләре дәвам иттерелде. Шуның белән бергә Татарстан Җөмһүриятендә Халыкның сәламәтлеген саклау комиссариаты һәм Ачларга ярдәм комитеты кулларыннан килгән кадәр ярдәм иттеләр. Шул шифаханә рәсми рәвештә бүген кич сәгать 5тә ачылачак.

Шифаханә ике бүлектән гыйбарәт: берсе эчке авырулар, икенчесе бала табучы хатыннар өчен. Һәр ике бүлекнең куелышы тыйб галәменең соңгы системасында. Бүлмәләр якты, чисталык һәм уңайлык. Күздә тотылган табиблар һәм авыру караучыларның мөмкин кадәр татарлардан булуына тырышылган.

Кули.
«Татарстан». – 1922. – 6 сентябрь.

Иске Казан дәүләтеннән калган әһәмиятле тарихи язулар табылу

Төрек-татар тарихын өйрәнүче яшь тарихчыларыбыздан Сәет иптәш Вахитов иске Казан дәүләтеннән калган әһәмиятле тарихи язуларны тапкан.

С.Вахиди (сулдан беренче) хезмәттәшләре белән

Сәет иптәш Вахитов, мәзкүр тарихи документларны кулына төшерер өчен, өч еллар чамасы бертуктаусыз чапкан. Төрле кантоннарда булган. Ниһаять, аларны ул, күп читенлекләрдән соң, кулга төшерергә муаффәкъ булган.

Төрек-татар тарихына гаид булган әсәрләребез моңарчы әле гел урыс вә башка милләтләр әдәбиятындагы материаллар ярдәме белән генә язылалар иде. Халык телендәге риваятьләр төрлесе төрле калыпта булганлыктан, алардан да бик аз гына файдаланырга туры килә иде.

Шуның өчен бу яңа табылган тарихи документлар алдагы көннәрдә тарихчыларыбыз өчен зур гына ярдәм итсәләр кирәк. Табучының сөйләвенә күрә, мондый тарихи әһәмиятле документларны Татар Җөмһүриятенең Лаеш, Спас, Чистай, Минзәлә

һәм Мамадыш кантоннарыннан табарга мөмкин булып, тик артыннан йөрүчеләрнең матди җәһәттән беркадәре тәэмин ителүләре генә шарт икән.

Дөрестә Татар Җөмһүриятенең мәгариф органнары кебек оешмалары мондый хезмәтләрне тәкъдир итеп, бу юлда мөкяфәтләр бирсәләр, матди һәм мәгънәви ярдәмнәрдә булсалар, яшьләрдәге фәнни хезмәтләргә булган мәел *(кызыксыну)* көчәеп, аларга шәхси тормыш корбаны булырга туры килмәс иде.

Сәет иптәш Вахитов, мәзкүр тарихи материалларны фәнни җәмәгатьтән тикшереп, карап чыккач мәйданга чыгарачакмын, ди.

С.Хафизов.
«Татарстан». – 1922. – 17 сентябрь.

Америкада татар укучылары йорты

Америка Кушма Җөмһүриятенең Вальпаразу (Вальпараисо) шәһәрендә дарелфөнүндә укучы татар һәм төрек кавемнәре шәкертләре үзләренә махсус укучылар йорты төзегәнлекләрен идарәбезгә язалар.

Бу йортны оештырудан максатлары Америкага килгән татар укучыларына мөмкин булганда матди булышлык итү, шулай ук Шуралар Русиясендәге татар укучы яшьләре белән хәбәрләшү, әхваль белән таныштырудыр.

Хатларында бу укучылар: «Шуралар Русиясенең эчке эшләре белән аз танышабыз, шуның өчен безгә татар әдәбияты җибәреп торсагыз иде», – дип язалар. Һәм киләчәктә андагы татар яшьләре тормышыннан гомумән һәм Америка тормышыннан хәбәрләр язып торырга вәгъдә итәләр.

«Татарстан». – 1922. – 18 сентябрь.

Самара тормышыннан

Самарада санаигы нәфисә эшләре үз нәүбәтендә әкрен генә, талгын гына дәвам итә. Әле менә 10 сентябрьдә Татар эшчеләр клубында сәхнә һәвәскәрләре тарафыннан «Мәхәббәт өчен сугыш» пьесасы куелды. Тамашага җыелган халык шактый гына иде.

Театр башланды. Хадим ролен үтәүче артист Габбастан бигрәк, грим, кыяфәт белән яңа гына мөселман булган бер карт керәшенне хәтерләтте, үзе карт, төсе бик яшь бер хадимне күрү кызганыч та, көлке дә иде.

Арсланбәк ролендәге иптәш фәүкылгадә яхшы үтәп чыкты. Уенның бөтен җитешмәгән җирләрен ул гына каплады. Бу кешенең артта калган сәхнәмезне алга җибәрергә чын күңеле белән эшләвен телибез.

Чулпан.
«Татарстан». – 1922. – 22 сентябрь.

Татар телен гамәлгә кую

Гадлия (Юстиция) комиссариатында татарлар белән аңлашырлык, татар телендә дә эшли белә торган эшчеләр аз иде. Бу хакта төрле чаралар күрелгәннән соң, хәзер комиссариаттагы мәсъулиятле *(җаваплы)* вазыйфаларның өчтән ике өлешенә та-

тарча һәм русча белүче иптәшләр куелды. Шулай ук байтак кына җегетләр эшкә өйрәтү, тәҗрибә өчен алыналар. Бөтен комиссариатта татарча кәгазьләрне кертү-чыгару эшләре юлга куелды.

Татарлардан гадлия эшчеләре җитештерү курслары ачылып, байтак кына эшчеләр чыкты һәм кантоннарда, шәһәрдә төрле урыннарга билгеләнде. Татарлар эшен карый торган халык мәхкәмәсендә бөтен эшне татарча йөртергә карар бирелде. Хәзердә мәхкәмә өчен кирәкле төрле рәсми кәгазьләр татарча эшләнеп ята.

Халык мәхкәмәләрендә һәм Инкыйлаби трибуналда татарлар эшен караганда бөтен хөкем мәҗлесен татарча алып барырга җитәрлек һәйәтләр төзелде.

Инкыйлаби трибунал һәйәтенә шулай ук сәркәтиблеккә татарлар куелып, прокурорлык назарәтенә дә дүрттән өчесе татарча белә торган эшчеләр билгеләнде.

Моннан башка да татар телен киңрәк сурәттә гамәлгә кую өчен Гадлия комиссариаты төрле чаралар хәзерлеген күреп ята.

«Татарстан». – 1922. – 25 сентябрь.

Татар сәхнәсе

22 сентябрьдә Большой театрда яңа ачылган татар больницасы файдасына Казан халкының яраткан артисты Кәрим Тинчурин һәм сабик *(элекке)* «Сәйяр» артисткаларыннан Заһидә ханым Ахмероваларның *(хәзер Тинчурина)* катнашы белән Кәрим Тинчуринның «Соңгы сәлам»е куелды.

Заһидә Шаһбазгәрәй кызы Тинчурина (Әхмәрова)

Вахит ролен уйнаган иптәш Тинчурин, гадәттәгечә, бу юлы да зур муаффәкыять *(уңыш)* казанды. Ул, гомумән, мондый типларны яхшы бирә ала. Хосусан үз әсәрләре каһарманнарыннан уйнауда тиңдәшсез бер артист.

Аның соңгы ике ел эчендә Казан сәхнәсеннән аерылып торуы һәркемне үзен бик дикъкать белән тикшерүне таләп итте. Нәтиҗәдә шуны әйтергә телибез: соңгы еллар аңарда техникасын тәрәкъкый иттерүдә *(яхшыртуда)* күп нәрсә биргән йөреш-торыш, хәрәкәтләр тәнкыйтьне, бәлки, күтәрә алмаслык дәрәҗәдә булып күзгә бәреләләр иде.

Киләчәк сезонның иске артисты Тинчуринның кайтуы белән Казан театры гаммәсе өчен күп нәрсә бирәчәгенә иман итәбез.

«Татарстан». – 1922. – 26 сентябрь.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде* ■

Коръән түгелме икән?

(Бакый Урманче көндәлекләреннән)

1966 ел

17 февраль.

«Муса» бюстын алып киттеләр.

8 март[1], дүшәмбә.

Аяк бик авырта. Урамга чыгарга куркам, йөри алмам диеп.

2 апрель.

Закирә ханым[2] әйтте: Казанда бер картонаж фабрикасында иске татарча китаплардан картон тартмалар ясыйлар икән. Берничә машина китереп ташлаганнар. Бер катын, Коръән түгелме икән, диеп, берничә китапны өенә алып кайткан. Кайсы фабрика икәнне анык белмиләр. Гаҗәп!

Закирә ханымда Гариф[3] хакында сөйләштек.

8 апрель.

Язарлар җәмгыятендә *(Язучылар берлегендә)* «Тукай замандашлары»ның мәҗлесе булды.

«Яшь ленинчы»га мәкалә бирдем. Котебне яздым.

15 апрель, җомга.

Тукайга атаулы клубта Тукай замандашлары белән очрашу кичәсе булды. Мин дә хатирәләр тарзында бер-ике сүз әйттем. Шамил Касыйм, Шиһаб Әхмәрев, «Болгар» мәскәне, Исмәгыйль Рәми[4].

9 май.

Касыйм Субаевта кунакта булдым. Мәгънәле кеше. Нигъмәт Еникиев белән Чанышевның[5] гаскәрдә һаман ызгышып торуларын сөйләде, икесе дә кызу булган.

Шиһаб Әхмәревне җирләгәннәр[6], әткәйнең дустларыннан соңгысы булса кирәк.

18 май.

Кичен Карый Габдуллага[7] багышланган кичә, Академтеатрда. Карыйны һаман кыерсыталар әле. Бу бөек артистыбызны болай кимсетү кайдан килә икән?

Хөкүмәт әгъзаларыннан берәү дә юк.

Дәвамы. Башы журналның 7нче (2022 ел) санында.

---

[1] Көндәлектә ялгыш 7 март диелгән.

[2] *Закирә ханым* – язучы һәм журналист, нашир, җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, репрессия корбаны Фатих Кәриминең (1870-1937) бертуган сеңлесе Закирә Гыйльман кызы Шәрәф. Ире – дин һәм җәмәгать эшлеклесе, язучы, журналист, нашир, репрессия корбаны Борһан Шәрәф (1883-1942).

[3] *Гариф* – Закирә Шәрәф белән Фатих Кәриминең бертуганы, журналист, җәмәгать эшлеклесе Мөхәммәтгариф Гыйльман улы Кәрими (1888-1934).

[4] *Шамил Касыйм* – актёр, режиссер, педагог Касыйм Шамил улы (1892-1981). Шиһаб Әхмәрев – педагог, журналист, нашир Шиһаб (Шиһабетдин) Шәрәфетдин улы Әхмәрев (1882-1966). Репрессияләнгән, соңрак акланган. «Болгар» мәскәне – «Болгар» кунакханәсе. Исмәгыйль Рәми – язучы, библиограф Исмәгыйль Габдулла улы Рәмиев (1895-1969).

[5] *Нигъмәт Еникиев* – хәрби эшлекле Нигъмәтулла Сәлимгәрәй улы Еникиев (1893-1971). Чанышев – хәрби эшлекле, генерал-лейтенант Якуб Җиһангир улы Чанышев (1892-1987).

[6] *Ш.Әхмәрев* 1966 елның 30 апрелендә вафат булган.

[7] *Карый Габдулла* – актер һәм режиссер, татар профессиональ театрына нигез салучыларның берсе Габдулла Хәйрулла улы Кариев (Миңлебай Хәйруллин, 1886-1920).

Май.

Аһ, җәмалеңне күрергә
Җан күрер күзләр кирәк.
Васфыңы тасвиргә
Коръәндин гали сүзләр кирәк.

Мәхәббәтең Коръәнендин
Күп аятьләр ятладым.
Ятладым шундый аятьләр –
Дүрт китаптан тапмадым!
Хәзрәти Коръән, Зәбур, Тәүрат,
Инҗилеңдин тапмадым.

(Исмәгыйль Рәми сөйләде бер шәкертнең язганыннан.)

28 май.

Тукайның кечкенә бюсты тәмамланды. Ләкин тиражлаучы юк. Һаман сүз.

29 май.

Тукай мәүзугларына башланган график эшләр белән һәүвәрә. Тәмамлавы кыен. Менә ике көн инде бер ат аягының дөрест рәвешен табалмастан җөдим.

6 июнь.

Тукайның кечкенә бюстын Худож[ественный] фондның сәнгать киңәшмәсендә карадылар. Янә миңа каршы карар. Иң яман итеп беренче уларак Васил Маликов[8] чыкты. «Мин Б.И.-дән[9] мондый яман эшне көтмәгән идем», – диеп башлады.

Башкаларның сүзләре минем файдага да, минем зарарга да алмаш-тилмәш булды.

Ахырдан Якупов[10] килеп, үзенең эчендә саклаган, тончыган бөтен агуын сипте. Һәртөрле вак-төяк кабаланулар.

«Яңадан күрсәтергә» дигән карар.

12 июнь.

Фарс уйнап кайттык. Нинди трагикомедия! Бюллетеньнәрне алдым, укып ...[11] салдым. Ниндидер Артем Микоян, ниндидер Монахова – кайда кайсысын, белмәдем дә.

Бер карчык әйтә икән: «Бармасак та ярар инде... кызым. Аларны безгә кадәр сайлаганнар бит инде», – диеп (агитатор ханым әйтте).

13 июнь.

Мин янә «Шүрәле» белән һәүвәрә. Урманга кергән саен шүрәлеләр күбәя, төрлетөрле төскә һәм рәвешкә керә баралар. Бу – гаҗәп бер мәүзуг.

Инде «Шүрәле»не театр уены өчен дә язасы, либретто язасы килә башлады. Әлеге куелуы, сәхнәләштерүе «Шүрәле»нең бик шаблон.

19 июнь.

Дөбъяз районының Чыршы авылында Сабан туенда булдык. Хәсән Гобәйдулла[12] алып барды.

---

[8] *Васил Маликов* – скульптор Васил Малик улы Маликов (1924-1992).
[9] *Б.И.* – Бакый Идрисовичның кыскартылмасы, ягъни Б.Урманче күздә тотылган.
[10] *Якупов* – нәгыйшьче, график Харис Габдерахман улы Якупов (1919-2010). 1951-1975 нче елларда Татарстан АССР Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе.
[11] Көндәлекнең бу урынында өч нокта куелган.
[12] *Хәсән Гобәйдулла* – театр белгече Хәсән Хәйрулла улы Гобәйдуллин (1913-1992). 1959-1977 нче елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтында фәнни хезмәткәр.

Бакый Урманче үзенең эш урынында. 1960 нчы еллар башы

Ат чабышы булмады, башка уеннары, көрәшүләр яхшы узды.

21 июнь.

Тукай күргәзмәсенә җыйналалар. Ләкин һаман шул фәкыйрьлек, акчасызлык, тарлык. Хәтта минем «Тукай»ның гипс моделен алып китәргә машина табалмыйлар, акчалары юк. Динә[13] бичара нишләргә белми.

24 июнь.

«Киришская школа №2 им. Мусы Джалиля»гә Мусаның кечкенә бюстын биреп җибәрдем. Алып киттеләр: Смирнова Галина һәм Курпина Валя.

30 июнь.

Хәсән Гобәйдуллин аркылы Финляндиядән килгән Гомәр әфәндегә[14] Тукайның кечкенә бюстын бүләк иттем. Телефон белән сөйләштек. Бик шат булды кебек.

5 июль, сиһшәнбә.

Әбелмәхҗән абыйда[15] булдым. Хатирәләр: Черкен, Казан, Мәкәрҗә. Күп яхшы китаплары бар. Тайярның Истанбулда басылган «Рәһбәре Гөлстан»ын алдым. Шәйхе Сәгъди[нең][16] бу алмас әсәренә җентекләп шәрех язылган. 30 сум.

13 июль, чаршәнбе.

Минем 70 еллыкка карата күргәзмә ясау хакында министр белән очраштым. «Дәрдемәнд»не, агачка күчергәч, 1967 нче елда алам», – диде. Амин.

22 июль.

Әбелмәхҗән абый Шәфигуллин килде. Сами бәкнең[17] «Лөгат»ен 20 сумга алдым.

19 август.

Шәехзадә Бабичның бюстын Башкортстан мәдәният министрлыгына тапшырдым. Гипс.

Инде агачка күчерергә кирәк.

27сендә Өфедән кайттым.

Аягым, уң аягым бик авырта. Һаман хафалый.

Сентябрь *башланды.*

Һавалар да үзгәрде. Көз, көз…

Аяк авырта, эш эшли алмыйм. Остаханәгә газ кертү һаман юк.

7 сентябрьдә, чаршәнбе көн, Мансур Хәсәневтә[18] булып, Рифгать Бигәев һәм Мидхәт Булатов[19] хакында сөйләштем.

10 сентябрь, шинбә көн.

Язар Зиннәтулла Фәтхуллин[20] белән Үзбәкстан Язарлар оешмасына Тукайның кечкенә бюстын бүләк итеп җибәрдем.

15 октябрь.

Янә «Аршин мал алан» эскизларын һәм татар кием-салымын башладым.

---

[13] *Динә* – сәнгать белгече, ул вакытта ТАССРның сынлы сәнгать музее хезмәткәре Динә Кәрим кызы Вәлиева (1936).

[14] *Гомәр әфәнде* – юрист, төрки телләр галиме, җәмәгать эшлеклесе Гомәр Таһир (Үмәр Дәһер, 1910-1992). Һельсинкида Г.Тукай исемендәге мәдәни җәмгыять рәисе.

[15] *Әбелмәхҗән абый* – библиофил Әбелмәхҗән Шәфигуллин (1889-1975).

[16] *Шәйхе Сәгъди* – атаклы Иран шагыйре Сәгъди (1209-1292). «Гөлстан» поэмасының авторы.

[17] *Сами бәк* – күп төрле сүзлекләр һәм белешмәләр төзегән төрек галиме Шәмсетдин Сами. XIX гасырда Истанбулда басылган китаплары Россия империясендәге төрки һәм мөселман халыклары арасында киң файдаланылган.

[18] *Мансур Хәсәнев* – галим, дәүләт эшлеклесе Мансур Хәсән улы Хәсәнов (1930-2010). 1961-1971 нче елларда КПССның Татарстан Өлкә Комитетында Мәдәният, фән һәм уку йортлары бүлеге мөдире. 1971 елдан Татарстан АССР Министрлар Советы рәисе урынбасары.

[19] *Мидхәт Булатов* – архитектор Мидхәт Сәгадәт улы Булатов (1907-?). 1940-1962 нче елларда Ташкент шәһәренең баш архитекторы.

[20] *Зиннәтулла Фәтхуллин* – Үзбәкстан язучысы Зиннәт Равил улы Фәтхуллин (1903-1987).

27сендә «Аршин мал алан» эскизларын һәм киемнәрне – барысы 12 эш илтеп бирдем, Мәскәүгә җибәрү өчен.

24 октябрь, дүшәмбә.

4 көн инде иртән алтыдан төнге 12гә кадәр эшлим. «Театр һәм кием» эскизлары.

28 октябрь, җомга.

Көзге көн. «ОМ»га[21] утырып Чулмантамакка кадәр барып, сабыйлык, үсмерлек чакларымны искә төшерә торган урыннар Каратун, Антон, Салтык кичүләрен күреп кайттым.

5 ноябрь, шинбә.

Хаҗиморад Казаков[22] керде. Зарлана. Ничек итеп бу бичарага ярдәм итәргә?!.

15 ноябрь, сиһшәнбә көн.

Киностудиядән килеп минем эшләрне экранладылар[23]. Ни булып чыгар?..

22 ноябрь.

Бүген композитор Мансур Мозаффарны[24] җирләдек. Иннә лилләһи вә иннә иләйһи раҗигун.

6 декабрь, сиһшәнбә.

«Гарәпләрнең Болгарга килүе» әкрен генә табылып бара. Киемнәр һәм башка йорт-җир әйберләрен табып ясарга кирәк. Мәрҗани[25] ярдәм итә. Төрек-Иран миниатюрлары. Ияр – тогым.

17 декабрь.

Җиһан ханымның туган көн мәҗлесендә булдык. Хәсән Туфан, Җәүдәт Фәйзи, Габдулла Шамуков[26], Бөдәйли һ.б. бар иде. Муса һәйкәле турында сүз чыкты. Кызык карашлар.

24 декабрь.

Ахирел-әмер, Саша килде. «Язгы моңнар»ны калыплый башладык.

Күңел төшенке. Матди як яман. Алга баруы кыен.

Спецполиникага бардым, теркәлдем. Ләкин бу хәерчелек туйдырды инде.

26 декабрь.

Шатлык юк. Хыяллар хыял булып калды.

27 декабрь.

Питрәй белән «Язгы моңнар»ны койдык. Уңышлы кебек.

28 декабрь.

Болгарская Гөлсем[27] ханымның 75 еллыгы. Хәсән Гобәйдуллин доклад ясады.

Текстны басмага ***Раиф Мәрданов*** *әзерләде.* ■

---

[21] *«ОМ»* – ике палубалы елга пассажир теплоходы («Озерный москвич»).
[22] *Хаҗиморад Казаков* – график һәм нәкышьче Хаҗиморат Исхак улы Казаков (1914-1984).
[23] Бакый Урманчега багышланган «Сагыш» фильмын төшерү турында сүз бара.
[24] *Мансур Мозаффар* – композитор, педагог Мансур Әхмәт улы Мозаффаров (1902-1966).
[25] *Мәрҗани* – илаһият галиме, тарихчы Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани (1818-1889).
[26] *Җәүдәт Фәйзи* – композитор, фольклорчы Җәүдәт Харис улы Фәйзи (Фәйзуллин, 1910-1973). *Габдулла Шамуков* – актер, язучы Габдулла Рухулла улы Шамуков (1909-1981), Б.Урманченың якын дусларыннан берсе. Исеме көндәлекләрдә еш кына Шамук рәвешендә телгә алынган.
[27] *Болгарская Гөлсем* – актриса Гөлсем Муса кызы Болгарская (Өммегөлсем Мостафина, 1891-1968).

Мөхәммәдия

Бакый Урманче

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең элекке күренеше

Казан шәһәрендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бар иде. Бинасы әле дә таза. Русиядәге төрек-татар халыкларының XIX гасырның ахырында-XX гасырның башында булган мәдәни хәрәкәтендә «Мөхәммәдия» тоткан урынны Олуг Британиянең Кембриджы белән чагыштырырга мөмкин. Татар культурасы өчен әһәмияте шулкадәр зур иде. Бу мәдрәсә тарихын бик тәфсилле рәвештә язарга кирәк иде. Ләкин кем язар?! Хәзер «Мөхәммәдия» шәкертләреннән берничә кеше генә сау, аларның да саулыгы шундый гына; язарлык хәлдә булганнарын табып булмады. Габделхәй Богдан «Мөхәммәдия»нең бөтен курсын тәмамлады. Хәзер дөм сукыр, чукрак, урында ята. Хәтере яхшы һәм мәдрәсәнең хәлен яхшы белә. «Мөхәммәдия»не ул хәтме көтеб кылды[1] һәм хәлфә (мөгаллим) дә булды. Ләкин үзе яза алмый. Мәхмүт Галиев[2] – Баруди нәселеннән, «Мөхәммәдия»не яхшы белә, ләкин сырхау, яза алмый, күзе күрми диярлек, авыру. Ленинградта Гәбделәхәд Госманов[3] – профессор-геолог. Бик хөрмәтле кеше, аның

[1] Хәтме көтеб кылды – укып бетерде, тәмамлады.
[2] Мәхмүт Галиев – физик, РСФСРның атказанган укытучысы. Яшәгән еллары хакында әлегә мәгълүмат юк.
[3] Габделәхәд Госманов – Габделәхәд Шаһи улы Госманов (1896-1996), Ленинград (Санкт-Петербург) тау эшләре институтында яңа оештырылган геофизика белгечлеге буенча беренче белгечләрнең берсе. Берничә елдан кандидатлык диссертациясе яклый, геологик тикшеренүләр факультетының деканы була. Докторлык диссертациясе яклавы турында

Ахыры. Башы журналның 8 нче (2022) санында.

«Мөхәммәдия»не никадәр белүе чамалы. Абайлый алмыйм. Тагын кемнәр? Юк. Шулай итеп, миңа тотынырга туры килә.

Мәдрәсәи «Мөхәммәдия» хакында язсаң, әлбәттә, аны булдыручы, программын төзүче, нигез салып, биналарын торгызучы Галимҗан Барудины искә алмыйчан булмый.

Биш яшеннән иске ысул (ысулы кадим) белән укудан гаҗиз булган Баруди Бохарада булынган чагында ул ысулның кимчелекләрен ачык сизә һәм Казанга кайтканда инде яңача, үзе тугры диеп төшенгән ысул белән белем өйрәтә башларга бил баглап кайта. Бу ысул соңыннан «ысулы җәдид» диеп шөһрәт алып, төрк-татар халкы культурасында шанлы бер дәвер ясады. Берничә ел «Мөхәммәдия»дә мөгаллимлек кылган мәшһүр Йосыф Акчура угылы «Дамелла Галимҗан әл-Баруди тәрҗемәи хәле»[4] дигән кита-

Бакый Урманче. Автопортрет. 1924 ел

мәгълүмат юк. Б.Урманче «профессор» дигәндә аның факультет деканы булуын искә ала кебек. Ул чынлыкта доцент дәрәҗәсендә кала. Илдәшләр (Гражданнар) һәм Ватан сугышында катнашкан. Б.Урманче белән бер чорда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыган. Урманченың шәхси архивында аның хакында кыска гына истәлек тә сакланган: «Ленинградта яши. Профессор. Хатыны – Зинаида Ивановна. Таулы, Атабай авылы мулласы Шаһиәхмәд хәзрәт угылы». Икенче истәлектә Ә.Госмановның тәрҗемәи хәле шактый тулы ачыла: «1976 [ел], май, 22. Бүген Габделәхәд мелла Шаһиәхмәт улы Госманов килеп утырды. Күп хатирәләр белән бүлештек. Габделәхәд минем якташ. Элекке Казан губернасы, Тәтеш өязе, Атабай авылында туган. Атасы Шаһиәхмәд хәзрәт алдынгы муллалардан. Ахунд һәм мөхтәсиб иде. Туган елы – 1901, 16 май. 1911 елда Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга килеп, ибтидаи бүлекнең дүртенче сыйныфында укый башлый. Мин дә 1907 елда шул ук башлангыч бүлекнең дүртенче сыйныфында укый башлаган идем. 1914 елда рөшдиянең өченче сыйныфыннан мәдрәсәне калдырып китә. Сәбәп: фәкыйрьлек. Атабай авылы күп балалы хәзрәтне тәрбия итә алмый. Балалар укуны бетерер-бетермәс акча эшләргә, көнкүреш чараларын күрергә мәҗбүр була. Габделәхәд Әчтерханга китеп, Таҗетдинов атлы балык сәүдәгәренә эшкә керә. Революциягә кадәр шунда. Революциядә катнашып, 1918 елдан башлап 1922 елга кадәр Кызыл Армиядә сугышта була. 1922-1925 – рабфак, Казан университеты каршында. 1925-1930га кадәр Ленинград тау эшләре институтында укый. Шул ук институтта профессор, кафедра мөдире. Хәзер ул миңа күп кенә этнографик рәсемле карталар китерде. Миннән кайберәүләрнең портретларын алды». Рәхим Теляшевнең «Татары на берегах Невы» исемле китабында Ә.Госманов хакында мондый юллар бар: «...Наш земляк, участник двух войн – Гражданской и Великой Отечественной, доцент Горного института, проживающий сто лет, Усманов Ахат Шагеевич (1896-1996). В годы Великой Отечественной войны ему как опытному горному инженеру-взрывнику было поручено возглавлять на Ленинградском фронте партизанский отряд особого назначения. Он находился в числе руководителей крупных партизанских отрядов в Лужском районе Ленинградской области. Подвиги отрядов, возглавляемых А.Ш.Усмановым были увековечены в послевоенных книгах «Горят костры партизанские» и «Бойцы особого фронта». Китап белән танышырга мөмкинчелек биргәне өчен Марс Тукаевка рәхмәтлемен. Кызганыч, китап Казан китапханәләрендә юк.

[4] Йосыф Акчура угылы «Дамелла Галимҗан әл-Баруди тәрҗемәи хәле» – монда җәмәгать һәм сәясәт эшлеклесе, публицист Йосыф Хәсән улы Акчуринның (1876-1935) «Дамелла Галимҗан әл-Баруди: тәрҗемәи хәле» (1 нче кисәк, Казан, 1907) исемле китабы күздә тотыла. Бу китап

бында мондый сүзләрне яза: «Остаз! Сез ибтидаи, вә гали тәдрисәтендәге бер мәсләк яки бер ысул иҗад итдегез». «Һәр тарафтан юлыңыза санечкеле агачлар ыргыттылар; барча мөҗәррәдләр[5] иза вә җәфадан, табигый, сез дә котыла алмадыгыз». «Хәзрәтнең хәяте исә укып, укытмактан гыйбарәт дияргә мөмкиндер». Шушы өч җөмлә-сүздә дамелла Галимҗан Барудиның гомер кыяфәте бик чичән рәвештә сурәтләнгән.

Ул вакытта Бишенче мәсҗедтә[6] Казанның ахуны Йосыф хәзрәт баш имам. Баруди аның янында икенче имам булып, 1882 елда Казанда урнашкач ук, укыту эшләренә керешеп, мәдрәсә корырга кереште. Мәдрәсәнең урыны бар, ләкин урам буенда ук кечкенә бер катлы йортта Йосыф хәзрәт үзе дәрес бирә. Баруди мәдрәсәне зур итеп берләштерүне һәм фасадын урамга чыгарып салырга тәкъдим итсә дә, Йосыф хәзрәт күнми. Ул вакытта бу мәхәлләдә Садыйк Галикәев[7], Әҗемнәр[8], Сафа Мусиннар[9] кебек, вакытында Мәрҗани дәресләрендә булып, яңа фикерле байлар, мәхәллә байлары Галимҗан Барудиның теләкләрен җөпләп, мәдрәсә салу өчен кырык мең акча туплыйлар. Шул ук вакыт Казанда яшәгән мәшһүр Әхмәд бай Хөсәенов[10] та, бу мәсьәләгә әһәмият биреп, дамелладан: «Мәхәллә байларың күпме сумма тупладылар? – диеп сорады. Дамелла кырык мең туплаганнарын әйткәч: «Алай булгач, мин дә алтмыш мең кушармын, яхшы, зур мәдрәсә салыгыз», – ди. Шул ук 1882дә Галимҗан Мәчкәрәдә зур бай Үтәмешевләрнең[11] Бибимаһруй атлы кызы белән өйләнешәләр. Маһруй ханым[12] атасыннан кырык мең мирасын да шул ук мәдрәсә файдасына багышлый. Маһруй абыстай да дамелланың беренче хатыны, бик яхшы укыган, хәтта фарсыча да укый ала торган булган. «Сөбател-гаҗизин»не бик ярата торган булган. Дамелланың байлыгына катнашмаган, абыстай үз капиталын үз ирке берлән идарә иткән. «Мөхәммәдия» файдасына вакыф итәр өчен өйләр сатып алган. Яхшы укыган «Мөхәммәдия» шәкертләрен башка илләргә җибәреп укытыр өчен фонд ясаган. Мәсәлән, Таһир Ильясны[13] Мисырга җибәрер өчен сигез йөз сум

Г.Тукай төзеп бастырган «Мәктәптә милли әдәбият дәресләре» дәреслек-хрестоматиясенең беренче басмасына «Мелла Галимҗан әл-Баруди хәзрәтләренең сабыйлык вакытындан» исеме белән кертелгән. 1918 һәм 1919 елгы басмаларда төзүчеләр тарафыннан төшереп калдырылган. 1997 елда кирилл хәрефләрендә дә басыла.

[5] Мөҗәррәдләр – ялгызлар, ялгызлыкта калганнар.

[6] Бишенче мәсҗед – монда хәзерге Галиев мәчете күздә тотыла. «Баруди мәчете» дип тә йөртелгән. Элек Печән базары, Муса бай мәчете дип тә аталган. Татар дини архитектурасы истәлеге. 1798-1801 нче елларда Печән базары янында Муса Мәмәш иганәсенә 18 нче йөз ахырындагы классицизм стилендә төзелә.

[7] Садыйк Галикәев – Мөхәммәтсадыйк Мөхәммәтсафа улы Галикәев (1847-1919), 1 нче гильдия Казан сәүдәгәре, җәмәгать эшлеклесе, Ш.Мәрҗанинең шәкерте.

[8] Әҗемнәр – монда нәсел башы Казан сәүдәгәре һәм эшмәкәре, нәселдән күчмә шәрәфле граждан Мортаза Мостафа улы Әҗемов (1819-1887) күздә тотыла.

[9] Сафа Мусин – Казан сәүдәгәре. Б.Урманче С.Мусин хакында кыска гына хатирәсен язып калдырган: «Баруди мәхәлләсенең зур байларыннан. «Мөхәммәдия»не асраучы прогрессив байларның берсе. «Мөхәммәдия»нең парлак яшәве шул байларның кесәсеннән булды. Белемле, мәдрәсәдә укыган кеше иде. Татар мәгариф эшләренә күп хезмәт иткән кешеләрнең берсе. Һаман яхшылык белән искә алырга бурычлыбыз. Бу гаҗәп бер үсеш заманы».

[10] Әхмәд бай Хөсәенов – Әхмәт Гали улы Хөсәенов (1837-1906), татар миллионеры, меценат.

[11] Зур бай Үтәмешевләр – монда Малмыж сәүдәгәрләре һәм кәсәбәчеләре Габдулла Габдессәлам улы (?-1832) һәм Муса Габдулла улы Үтәмешевләр (?-1835) күздә тотыла.

[12] Маһруй ханым – Бибимаһруй Исхак кызы Үтәмешева (1862-1904), Г.Барудиның беренче хатыны.

[13] Таһир Ильяс – Таһир Ильяси (1881-1933), гарәп теле һәм әдәбияты буенча белгеч, лексикограф-галим. Репрессияләр чоры корбаны. «Кояш» газетасының 1916 елгы 1 ноябрь санында (1037 нче сан) Т.Ильяснең Оренбургка «Хөсәения» мәдрәсәсенә укытырга китүе хакында

бирәләр. Шулай ук Борһан Хәбиб[14] Бәйрутта, Хикмәт Биккинә[15] Мисырда шул фондтан стипендия алалар.

Ак мәсҗеднең түбән катында фәкыйрь кыз балалар өчен мәктәп ача, аларны ашата. Шулар арасыннан килеп чыга мәшһүр Ләбибә ханым[16]. Иң әүвәл ул Маһруй абыстайга ярдәмче була.

Маһруй ханым, гомумән, ярлы шәкертләргә ярдәм итеп тора торган булган. Дамелла үзенең хатирәләрендә Маһруй ханымны һаман яхшылык белән сагынып сөйли. Шулай ук мәдрәсәнең шәкертләре вафат абыстайны һаман мактап-мактап искә алалар иде. Мин мәдрәсәгә 1907 елның көзендә килдем. 1882дә Баруди шәкерт тәрбия итүен башласа да, әле мәдрәсә бинасы корылмаган. Әүвәл дәрес мәсҗед эчендә үтәлә торган булган. Ул заман өчен бик зур булган өч катлы таш бина, кура эчендәге ике катлы рөшдия корпусы кайчан корылып беткәндер, ләкин инде 1907 елда мәдрәсәнең бинасы хәзер булып, ибтидаи, рөшди, игътидади, галия бүлекләре – һәммәсе эшли иде. Бер үк сыйныфларның төзелеше, җиһазы төгәлләнгән булса да, ятак-торак бүлмәләре тәмам тәртипкә китерелмәгән иде әле. Аларны төзек хәлгә китерер өчен янә бер-ике ел узды. Дамелла нәкышбәндия тарикатендә иде. Ләкин ишанлык кылмады. Мәсҗедтә

хәбәр басылган. Анда болай язылган: «Кичә, 31 октябрьдә, скорый поезд белән Таһир Ильяс Оренбургка сәфәр итте. Таһир әфәнде мәдрәсәи «Хөсәения»гә мөдир вә мөдәррис булып китте. Мәдрәсәи «Хөсәения» мәхәлләсендә ул рәсми имам вә мөдәррис. Һәр эшендә дикъкатьле, диндар яшь галимебезгә яңа ләвазимендә муаффәкыять телибез (хезмәтендә уңышлар телибез)».

[14] Борһан Хәбиб – Борһан Хәбибнең язмышы хакында мәгълүматны Б.Урманче истәлекләреннән алабыз: «1915 елда Тәтештә таныштык. «Мөхәммәдия» шәкертләреннән. Бәйрутта Америка колледжасын тәмамлаганнан соң Казанга кайтып, «Мөхәммәдия»дә мөгаллим була. Февраль (1917) революциясеннән соң җәмәгать эшләрендә катнаша. Баруди һәйәте белән Төркестан сәфәрендә була һәм Ташкентта «Имперас» мәгариф институтында мөгаллим булып кала. Математика, физика фәннәре [укыта]. 1921 елда шунда, Ташкентта очраштык, кат-кат кунак булып, сохбәттә булдым. Гүзәл илтифатын казандым. Әлбәттә инде, камалды һәм шәһид. Бик өметле, кодрәтле профессор иде». Яшәгән еллары хакында әлегә мәгълүмат юк.

[15] Хикмәт Биккинә – Хикмәт Мифтах улы Биккинин (1888-1929), укытучы, дипломат. 1926-1929 нчы елларда Согуд Гарәпстанында СССР илчелегендә эшли. Х.Биккинин – Б.Урманченың авылдашы. Шәхси архивта аның хакында кыска гына хатирә сакланган: «Хикмәт абый 1907 елны мине «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә Салтыктан алып килеп укырга урнаштырган кеше. Ул вакытта ул үзе дә «Мөхәммәдия»нең игътидади сыйныфларының берсендә укучы шәкерт иде. Мин ибтидаи бүлекнең 4 нче сыйныфына кердем. Бүлекнең һәм безнең сыйныфның баш мөгаллиме хәлфә Хәнәфи иде. Бу кеше әткәйнең дә танышы иде. Аның хакында яхшылыктан башка һичбер сүз әйтеп булмый. Хикмәт абыйның биографиясе бик кызык. Ул XX гасырның беренче һәм икенче декадалары чорында яшәгән прогрессив мәдрәсәләрнең берсендә укыган, сәләтле яшьләрнең гомере өчен үрнәк итеп алырлык бер сима иде. Мифтах абзыйны без, безнең гаилә, Шәкерт бабай диеп атый идек. Аның сәбәбе – Мифтах абзый яшь вакытта Салтык мәктәбендә мөгаллим булып, әткәй аңардан сабак укыган. Салтыкта 90 яшькә ирешеп вафат булган карт мәзин Биккинә Мифтах абзыйны мулла итүне теләп, Казанга «Кызыл мәчет» («Госмания») мәдрәсәсенә җибәреп укыткан булса да, кызу канлы, фәгалиятьле, һич тиктормас Мифтах абзый озак мөгаллим булып калмый, сәүдәгә керешә. Кибет ача, йомырка җыя, тирә-юньдәге урыс авылларыннан да йомырка җыеп, Антонда да (Антоновкада) бер кечкенә кибет тота. Шуның белән бергә, авылның мәчет картларыннан берсе булып, кайвакытларны Коръән дә укып, авылның дин тотарларыннан берсе булып, мәчеттә аның урыны беренче сафта, имамның аркасында иде. Гаедләрдә сәдака җыючыларның берсе иде. Бу аның комсызлыктан түгел, мәктәптә укыган вакытларыннан калган бер гадәт кенә иде юкса. Менә шушы кеше кече угылы Хикмәт(улла)не Казанның иң прогрессив җәдид мәдрәсәсенә илтеп укырга бирә...»

[16] Ләбибә ханым – монда педагог Ләбибә Һади кызы Хөсәенова (1880-1920) күздә тотыла. Ул 1896-1903 нче елларда – Маһруй Барудия мәктәбендә, 1904 елдан Казанда кыз балалар өчен үз мәктәбендә укыта.

мөридләре белән җыелышлары була иде. Борһан Шәрәфкә иҗазәтнамәсен[17] дә күрдем. Шулай ук Шәһер Шәрәф[18] тә андан иҗазәт алган булса кирәк. Болгар илендә, ягъни хәзерге Русиядә, нәкышьбәндиләрнең шәйхе булган Яманкаладагы (Троицк) Зәйнулла[19], нәкышьбәнди мәдрәсәгә нигез салган вакытта Казанга килеп, шул мәракәне куәтләп[20] дога кыла (моны сабикъ[21] Малмыж имамы Мозаффар Камал[22] (?) Уфада күрешкәнемдә әйтте).

Галимҗан Баруди (Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Галиев)

Мин укыган елларны мәдрәсә бик төзек хәлдә иде. Рөшдия корпусында торак-ятак бүлмәләре беренче катта, дәрестханәләр икенче катта иде. Торак-та аерым бүлмәдә мөбассыйр-күзәтүче, борынгыча әйткәндә, казый тора иде. Гадәттә, ул яшь хәлфәләрдән берәү. Мин рөшдия вакытында мөбассыйр шагыйрь Хәбиб Исхак[23] иде, мәдрәсәдә вафат булды. Андан соң Хикмәт Биккинә булды (соңыннан бу кеше Мисырда укып, илгә кайтып, «Шәрекъ» институтыннан диплом алып, партиягә кереп, дипломатик эштә булып, Гарәбстанда Җиддидә вафат). Ул вакыт Казанның күп төшендәгедәй, Болакның көнбатыш ягында канализация юк, шунлыктан тәһарәтханә, ягъни туалет бүлмәләре, махсус салынган һәм җылытылган аерым ике катлы бинада иде. Җылыту үзәкләштерелгән, утын белән ягыла торган. Казаннардан килә торган кайнар бу[24] белән җылытыла иде. Яктылык шәһәрнең электр тармагыннан алына. Шунысы игътибарга лаек: минем җиде ел мәдрәсәдә булынганым чорында бер тапкыр җылыту һәм яктырту системында берәр чатак булганы хәтеремдә юк. Аерым бер бинаычыкта агач һөнәре – столярлык остаханәсе, теләгән шәкерт анда шөгыльләнә ала. Корал-

[17] Иҗазәтнамә – рөхсәт язуы, диплом.
[18] Шәһер Шәрәф – бу урында җәмәгать, дин һәм матбагачылык эшлеклесе Шәһретдин Шәрәфетдин улы Шәрәф истә тотыла. Б.Урманче Ш.Шәрәфнең кешелек сыйфатлары һәм белеме хакында болай ди: «Шәһер Шәрәф «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә мөдәррис иде. Зур ислам тарихын белүче, гарәбияттән тирән белем иясе. Шул ук «Мөхәммәдия»дә хәтме көтеп кылган, соңыннан Галимҗан Баруди урынында имам булган зат. Ислам тарихыннан язган әсәрләре – билгеле, эчтәлеге, теле, иншасы белән бөтен тарафыннан җөпләп кабул ителгән әсәрләр. Мөлаем, тыныч табигатьле, сабыр, җитди фикерле зат иде. Соңгы тапкыр күрешүем Соловкиның Разноволока дигән иң яман лагеренда булды. 30 нчы елларда шәһид. Кабере мәгълүм түгел. Чын иманлы, чын намуслы дин галиме иде».
[19] Зәйнулла – бу урында 1884 елдан Троицк мәчете имамы, аның каршында яңа ысул белән эшләгән «Рәсүлия» мәдрәсәсенә нигез салган, суфыйчылык тарафдары Зәйнулла Рәсүлев (1833-1917) истә тотыла.
[20] Мәракәне куәтләп – кызыксынуны куәтләп.
[21] Сабикъ – элекке.
[22] Мозаффар Камал – монда Малмыж мәчете имам-хатыйбы, «Шура» журналында төрле темаларга шактый мәкаләләр бастырган Мөхәммәдкамал Мозаффаров истә тотыла. Күренекле драматург Мирхәйдәр Фәйзинең җизнәсе.
[23] Хәбиб Исхак – монда шагыйрь Хәбиб Шәрифулла улы Исхакый (1883-1913) күздә тотыла.
[24] Бу – пар.

лары хазир[25], ләкин бу мәҗбүри түгел, мәдрәсәнең программына кертелмәгән.

Авыруларны аерым тотар өчен ятак урыннары белән тәэмин ителгән шифаханә башка корпуслардан изоляцияләнгән махсус аерым бинада. Кечкенә генә булса да амбулатория, табиб атнага өч тапкыр килеп йөри, аның ярдәмчесе, мөгаллимнәрдән берәү һаман мәдрәсәдә, шул амбулатория катындагы бүлмәдә яши иде. Мин укыган заманда ул эшне башкаручы Касыйм хәлфә Биккинә иде. Кухня аерым бер бинада. Анда даим кайнар су хәстәрләп тора торган күп казан һәм көндезләрендә янып торган плитә. Аш әсбапларыннан башка бернәрсә юк, арулык. Зур бәйрәм чакларында үзләре теләгән ашны шунда пешерергә шәкертләргә рөхсәт. Ашханә аерым түбәнге катта. Төшке аш өчен көненә алты тиен бүленә, ул порцияләп түгел, туйганча ашыйсың. Бер генә табактан, гадәтендә, чын татарча хәзерләнгән итле-токмачлы (вермишель) аш була. Тамак туйдыру хафасыз иде. Мәдрәсә корпусының эчендә киң тактадан ясалган бик гади, примитив җиһазланган кибет бар иде. Аның хуҗасы мин укыган чакта (1907-1914) һаман Шәрәфи абзый булды. Беркатлы, намуслы, шәкертләргә хөрмәтле татар сәүдәгәре. Ул кибеттә иң гади ашамлыклар – күмәч, шикәр, чәй, атлам һәм сары май, казы (казы ул вакытта гади, көндәлек әйбер, деликатес түгел иде), хәлвә һаман булып тора иде. Башка нәрсә юк кебек. Еш кына җимеш пастиласы була иде. Бу нәрсәләр һәрвакытта таза, чөнки һәркөн яңа, таза әйберләрне китереп торалар иде. Шул вакытта, яман искергән ашамлык китергән, диеп, Шәрәфи абзыйдан зарланган ишетелмәде.

Бәйрәм көннәрендә үзебез берәр җылы аш хәзерләргә теләсәк, шул ук Шәрәфи абзыйның мәдрәсәдән бер генә өй аша булган кибетенә чыгып, ит, бәрәңге, суган, борыч, вермишель алып керә идек. Тагы бер-ике өй аша янә шундый ук Баһау абзый кибете бар иде.

Минем кебек ярлы шәкертләр һәркөн алты тиен түләп төшлек ашауны авырсына иде. Бу төштә шуны да әйтергә кирәк: өйдән-авыллардан һәрвакыт ашамлык-азык җибәреп торалар иде. Күбрәк ул вак, итле бәлеш була, елкы ите, каз ите, куй ите шикелле нәрсәләр. Ул вак нәрсәләрне кухняда табачыкта җылытып ашый идек. Ул, ахры, алты тиен түләп төшлек ашаудан табышлырак булгандыр. Шулай ук казы, май, хәлвә, күмәч белән чәй эчү дә арзанрак төшкән микәнни? Искә алырга кирәк. Казан мәдрәсәләрендәге шәкертләрнең мәдрәсәдә торып укучылары күбрәк ярлы-фәкыйрь авыл муллаларының угыллары булды. Казанның мещан балалары дүрт ел ибтидаида укыгач, мәдрәсәдән китәләр иде. Һәм алар, әлбәттә, мәдрәсәдә торып укымыйлар иде. Шунлыктан аларның тукланулары өйләрендә.

Безнең мәдрәсәдә торучыларның бердәнбер хафасы шул туклану. Чөнки мәдрәсәгә килеп урнашканнан соң торак-ятак җәфасы безнең өстән төшкән була. Шәкерт мәдрәсәдә торган һәм укыган өчен бер тиен түләми. Борын-борыннан килгән гадәт буенча, сәрап[26] булуын өмид итеп, мәхәллә байлары һәм Әхмәд бай кебек ягадан вакыф итүчеләр[27] дә күп булган. Мәдрәсәнең хуҗалык, матди идарә эше бөтенләй мәхәллә байлары өстендә иде. Һәрвакыт сезонның башында – сентябрьдә без җәй көне яхшы ремонт ясалган, диварлар агартылган, парталар төзәтелеп, яңадан лак белән ялтыратылган, сыйныф кара такталары тазартылган, идәннәр яңартылган, буяуланган, кроватьлар тазартылган

[25] Хазир – шунда.
[26] Сәрап – кадер, хөрмәт.
[27] Ягадан вакыф итүчеләр – читтән мал, акча белән ярдәм итүчеләр.

мәдрәсәгә килеп керә идек. Дөрест, шәкертләр дә үзләрен әдәпле, тәртипле тоталар, сыйныфларда пәке белән бозылган, шәкертләрнең исемнәре язылган, имгәтелгән парталарны очрату минем хәтеремдә юк. Соңыннан Казан һәм зур һәм урта калалардагы уку йортларында булындыгымда мин шундый тәртипне күрмәдем.

Кыш буена җитәрлек утын мәдрәсә курасының бер ягында бөтен кышка җитәрлек хәзерләнгән була иде. Бу эшләрне идарә итеп майтаручы мөтавәлиләр һәйәте, алар арасында югарыда аталган мәхәллә байлары да булгандыр. Ләкин шул хуҗалык эшләренең башында Әҗемгәрәй дигән урта кул сәүдәгәр[28] утыра иде. Үзе дә яхшы мөдәррис күргән кеше.

Хәзерге заман совет уку йортларында буш, бер тиен түләмичә, хәтта стипендия белән тулы тәэмин ителеп, белем ала торган яшьләр өчен гаҗәп бернәрсә юк. Белем алырга теләгән кеше өчен бездән дә артыграк шартлар тудырган бер ил юк. Ул вакытта университетта укыр өчен акча түли алмастан укуын туктаткан яшьләр була иде. Минем хәтеремдә Казан университетында укый торган берике татар студентының файдасына шәкертләрдән акча җыйганыбыз.

Инде «Мөхәммәдия»нең академик тормышына килик. Иртән сәгать җидедә торып, тәһарәт алып, иртәнге намазны үти идек. Бу истә калган, рөшди курс тәмамлап, игъдадиягә күчкәннән соң, рөшдидә намаз бүлмәсе юк иде. Рөшдидә иртәнге намазны җыелып уку булмады микән? Хәтеремдә юк.

Әмма игъдадия корпусына, өч катлы төп бинага күчкәч, иртә намазны зур дәресханәдә (моны актлар залы дисәк тә була) укый идек. Биек тимер баскычның култыгында торып, берәү Вәли карый Мәкай белән азан әйтә иде. Бу эшне үтәргә йә Фәтхи Бурнашка[29], йә миңа туры килде. Без икебез дә Вәли карыйның шәкертләре, аның мәкаме белән Коръән укыйбыз һәм ул өйрәткән җырларны җырлыйбыз. Икебезнең дә җырларлык тавышларыбыз бар иде.

Димәк, игъдадиягә чыккач, дәресләр көне иртән намаз азаныннан һәм ике рәкагать намаз укудан башлана.

Баштан башлыйк: «Мөхәммәдия» – белем алуның бөтен курслары бердәмләнгән бер институт, мәдрәсә. Дүрт бүлек-курска бүленгән:

- ибтидаи мәктәп – башлангыч белем – 4 сыйныф;
- рөшдия – урта мәктәп курсы – 4 сыйныф;

[28] Әҗемгәрәй дигән урта кул сәүдәгәр – Әҗем Исмәгыйль – «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең хуҗалык эшләрен идарә итүче Әҗемов. Исмәгыйль шуның угылы, «Мөхәммәдия»дә укытты. Әтисе «Мөхәммәдия»нең хуҗалык эшләрен бик яхшы идарә итә. Үзе Галимҗан Баруди мәхәлләсенең уртача байларыннан. Кәсебе – сатучы, ләкин нәрсә белән сату-алу иткәнен яхшы белмим. Ике катлы агач өе Баруди мәсҗеденнән ерак түгел иде. Исмәгыйль Казанның укымышлыларыннан булып, җәмәгать эшләренә катнаша, культура даирәсендә иде. Кабан күленең төбен арчу белән кызыксынып, шуңа тәшвикъ (кызыксындыру, өндәү) итеп йөрде. Аның файдалы булуына фәнни-техник, экономик дәлилләр җыйган иде. Әлбәттә, әсассез түгел.

[29] Фәтхи Бурнаш – бу урында прозаик, шагыйрь һәм драматург, әдәби тәнкыйтьче, журналист, җәмәгать эшлеклесе Фәтхи (Фәтхелислам) Закир улы Бурнаш (Бурнашев) (1898 – 1942) күздә тотыла. Б.Урманченең чордашы. Шәхси архивта аның хакында язылa башлаган истәлекнең берничә варианты сакланган. Шуларның берсе: «Шагыйрь, «Мөхәммәдия»дә берзаманда укуда булдык. Дуст идек. Зур талант иясе иде. Яхшы җырлый иде. Элекке Сембер губернасы Буа өязе Бикшит авылыннан. 1917 елда Сембердә, бервакыт солдат идек. Сембердә күп җыелышларда бергә булдык. Ул шунда Октябрь революциясендә катнашып, берничә ел Сембердә калды. Ак чехлар заманында кайда булгандыр, шунысы хәтеремдә калмаган. Бикшиттә булган булуы бик мөмкин. РКПга (КПСС) чехлардан соң кергән булуы мөмкин. 1920 елда инде Казанда иде. Журнал чыгарды».

- игъдадия – Яурупаның колледже кебек – 3 сыйныф;
- галия курсы – гали дини, фәлсәфи мәктәп – 2 сыйныф.

Димәк, «Мөхәммәдия»дә ибтидаи беренче сыйныфтан укый башлаган шәкерт тәмам хәтме көтеб итәр өчен унөч-ундүрт ел шәкертлектә булырга тиеш.

Ибтидаи мәктәптә дәресләр ана телендә – төрек телендә узыла. Борын ана телендә – татар телендә укуны «төрки тану» диләр иде. Төрки тану башлангыч белемнәрне алыр өчен кирәк. Ләкин Коръән дәресләре мәктәпнең икенче сыйныфыннан башлана. Хәрәкә, диакритик билгеләр белән язылган яисә басылган Коръәннең гарәпчә нөсхәсе текстын балалар гарәпләргә генә хас булган «сә», «зә», «са», «за», «тат», «зат», «айн», «гайн», «хә», «ха» авазларын дөрест әйтергә өйрәнүдән башлыйлар.

Ләкин төрки телдә язылган китапларда гарәптән кергән сүзләр гарәп классик орфографиясендә языла торган булса да, аларны гарәпчә кебек әйтү таләп ителми, бары Коръән укыганда гына классик гарәп авазлары белән укырга өйрәтәләр һәм шул ибтидаи курсларда ук Коръәнне дөрест уку кагыйдәләрен, «Тәҗвид»не өйрәтә башлыйлар иде. Коръән дәресләре киләсе курсларда да төрле рәвештә һәм төрле дәрәҗәдә дәвам итәчәк.

Ибтидаинең өченче-дүртенче сыйныфларында төрки телнең (татар теленең) сарфы – грамматикасы өйрәнү башлана. Хисап дәресләре беренче дәрестән башлана. Математика фәне игъдадиянең соңгы курсына кадәр, ягъни ун ел буенча дәвам итәчәк.

Кече атна – пәнҗешәмбе көн дәресләр аз булып, төрле бәетләр, илаһи шигырьләр, касыйдәләр, мәүлед айларында әйтелә торган бәет-мөнәҗәтләр өйрәнә һәм кычкырып төрле көйләргә әйтә идек. Бу вакытта инде хәлфә киткән була. Кайвакытларда «Марсельеза» җырлый башлый идек. Кем аны безгә өйрәткәндер? Белмим. Ләкин ибтидаи мәктәпнең мөдире Рәхим хәлфә Хәнәфи моны ишетүгә дөп-дөп басып (ул каты басып йөрүче иде) килеп җитә һәм безне туктата, ләкин ачуланмый иде. Бу реакция елы диеп аталган 1907 елда. Касыйдәләр өйрәндек. Мин ибтидаи мәктәпнең соңгы дүртенче сыйныфына килеп кергән идем. Мин ибтидаи мәктәп дәресләрен әткәйдән өйрәнеп узган булсам да, әткәй үзе теләп, аның тәртибен дә күрсәтер өчен, шунда укыта башлады. Ләкин анда мин укый башлагач ук рамазан гаеде килеп җитте, бәйрәм, соңгы пароход белән өйгә кайтып киттем. Шул вакыт навигация бетте, Иделдә сил[30] башланды. Авылда Идел туңганны көтеп калдым. Соңгарып барырга туры килде. Тагын бер уңгайсызлык булды. Мин аның мәгънәсен ул вакыт төшенмәдем: безнең авылдаш Хикмәт абый Биккинин, уку бозылганлыктан, авылга кайтып китте. Ул кай якта булгандыр? Аннан башка миңа уңгайсызрак булды. Бер үк бөтен дәресләрдән 9-10 дәрәҗәләр белән имтихан биреп беренче рөшдиягә күчтем.

Игъдадиядә төрек дәресләре бетә. Урыс теле дәресләре дә юк. Рөшдиядә укытылмаган фарсы теле урын ала. Ләкин төп сабак буларак гарәп теле һәм әдәбияты үзенең урынын саклап бара. Хәтта кайбер һуманитар фәннәр дә гарәпчә өйрәнелә. Мәсәлән, ислам тарихы һәм мантыйк-логика. Борынгыдан укылып килгән «Исагуҗи»[31] мантыйк китабы урынын саклый...

[30] Сил – җил.

[31] «Исагуҗи» – «Шәрхе Исагуҗи» – мәдрәсәләрдә укытылган дини китап, 1847 һәм 1849 нчы елларда Мисырда басылган, авторы – Әсиретдин әл-Мөфаддил ибн Гомәр әл-Әхбәри (1200-1264) – гарәп математигы, астроном һәм фәлсәфәче.

Барудиның Мәрҗани юлыннан баруы аның бөтен хезмәтеннән күренә. Мәрҗанинең үзе әйткән [...][32] әсасы иманы Барудиның тәрбия һәм тәгълим эшләрендә ачык бер мәсләк булуы тормышка уздырылып бара. «Мөхәммәдия»дә Бохара мәдрәсәләрендә кебек дини, игътидад[33] вә фикъһ[34] мәсьәләләре [*хакында*] озын-озын бәхәсләр белән чуалтылган төп гыйльми әсәрне бер якка куеп шәрехләр, хашияләр[35] белән баш әйләндерү юк. Рәсүлнең хәдисләре[36] рөшдиядә әүвәл укытула башлап, игъдадиядә төп фән булып уздырыла. Иң ышанычлы булып сайланган хәдис китаплары укытыла. Фикъһ әсәрләреннән чын игътибар казанган («Һидая»[37], «Мохтәсарел вакия»[38]) әсәрләр шәрехләр, хашияләрсез укыла. Иң әһәмият бирелгән нәрсә – шәкертнең гарәпчәне яхшы аңлап, төрле шәригатькә гаид әсәрләрне үзе моталәга итәрлек белем бирү.

Гарәп әдәбиятыннан «Кәлилә вә Димнә»[39], «Мәкамат әл-Харири»[40], Әбүлгалә әл-Мәгарри һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләре укытыла. Гарәп әдәбияты укыту рөшдиянең өченче курсларыннан башлап галия курсларына кадәр бара. Галияне тәмамлап, хәтме көтеб кылган шәкертләр гарәп телен камил рәвештә өйрәнеп, китап гарәпчәсен сөйләшерлек, язарлык хәлдә белеп чыгалар иде.

Шундый бер вакыйганы сөйлиләр. Мәшһүр академик Крачковский[41] Шәһер Шәрәфкә академиядәме, университеттамы эш тәкъдим итә. Шәһер хәлфә дәгъватны кабул итеп, аңлашыр өчен бара. Очрашкач урысча сүзләргә керешәләр, хәлфә куәте бөлгәнлектән, гарәп теленә күчәләр. Соңыннан академик (Ливанда, Бәйрутта байтак торган галим) хәлфәдән: «Сез Гарәпстанда кайда булдыгыз?» – диеп сорый. Шәһер хәлфә: «Юк, Гарәпстанда булганым юк», – дия. «Алай булгач кайда өйрәндегез? – дип сорый. «Казанда, «Мөхәммәдия»дә», – диеп җавап бирә. Шәһер хәлфәнең «Мөхәммәдия»дән башка Төркия һәм Гарәпстан мәдрәсәләрендә укыган булуы мәгълүм түгел. Шәһер хәлфә «Мөхәммәдия»дә ислам тарихы һәм Рәсүлнең гомер хәлләрен[42] гарәпчә укыта иде. Ислам тарихы «Тарихы әнбия» буларак рөшдиядә дә укытыла. Ләкин анда Шәһер хәлфә укытмый иде.

Безнең Казан, Уфа, Оренбург галимнәреннән гарәбияттан, ислам культурасыннан иң югары белемләргә ия булган Бохара, Каһирә, Истанбул һәм башка Көнчыгыш илләрендә булмаган берничә галим бар. Алар барысы бары үзебезнең илдәге мәдрәсәләрдә генә белем алганнар. Аларның иң мәшһүрләре Риза Фәхреддин, Кәшшаф Тәрҗемани[43], Каюм Насыйри, Шәһер Шәрәф.

[32] Бу урында Мәрҗани хезмәтеннән алынган гарәп телендәге текст кушылып китә.
[33] Игътидад – исәпкә алу.
[34] Фикъһ – ислам хокукы, юриспруденция.
[35] Хашияләр – аңлатмалар.
[36] Рәсүлнең хәдисләре – Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) хәдисләре.
[37] «Һидая» – «Һидая шәрхе» (китап исеме).
[38] «Мохтәсарел вакия» – дини мәдрәсәләрдә укытылган китап исеме.
[39] «Кәлилә вә Димнә» – урта гасырлар фарсы һәм гарәп әдәбияты истәлеге. Эчтәлеге борынгы һинд фольклор китабы «Панчантра»га нисбәтле.
[40] Мәкамат әл-Харири – бу урында гарәп әдибе һәм шагыйре, филологы Мөхәммәд әл-Харири (1054-1122) истә тотыла. Мәкамат – урта гасыр әдәбиятында аерым новелла һәм бердәм сюжетка корылган жанр белән язылган әдәби әсәр. Мөхәммәд әл-Харири мәкаматлар иҗат итү буенча урта гасыр гарәп әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән берсе.
[41] Крачковский – Игнатий Юлианович Крачковский (1883-1951), ориенталист галим, гарәп теле белгече.
[42] Рәсүлнең гомер хәлләрен – монда Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.) тәрҗемәи хәле искә алына.
[43] Кәшшаф Тәрҗемани – Кәшшафетдин Кыяметдин улы Тәрҗеманов (1877-1943), дин һәм җәмәгать эшлеклесе.

Югары курсларда хәдис дәресләре һәм мантыйк дәресләрен укытучы Кәшшаф Тәрҗемани иде. Фарсы телен һәм гакыйдәне (дини фәлсәфә) укытучы Әхмәтҗан хәзрәт[44]. Әмма Коръәнне өйрәтүче, тәфсир итеп аңлатучы Барудиның үзе иде. Аның да дәресләренә, билгеле галия сыйныфы шәкертләреннән башка һәркемгә кереп тыңлап утырырга рөхсәт. Хәтта бөтенләй мәдрәсә шәкертләреннән булмаган, ягадан теләгән кешеләрнең дә булынуларына рөхсәт ителә иде. Ләкин дәрес ачык, очраклы лекция рәвешендә түгел, программлы дәрес булып уздырыла иде. Шул дәрес шәкертләреннән дамелланың тәкъдиме белән берәү Коръәннең аятьләрен аваз белән укый, дамелла үзе тәфсир кыла иде. Кайвакыт шәкертләргә сораулар бирә иде. Шәкертләр өчен иң читен төшләре: бу дәресләрдә кайвакыт кулланыла торган тәфсир китабыннан (нинди тәфсир икәне хәтеремдә юк) хәрәкәсез гарәпчә гыйбарәне укырга тугры килә иде. Моның өчен гарәп телен яхшы белү кирәк. Ягъни укыганыңны аңлап укырга. Гарәпчә текстны аңламастан дөрест укып булмый – әгәр дә хәрәкә, диакритик аст-өст куелмаган булса. Бу – үзенә бер имтихан.

Галия курсларына барып җиткәндә шәкертләрнең саны азая. Бигрәк тә бу соңгы елларда шулай булды. Чөнки галия курсларында дин-шәригатькә караган фәннәргә күбрәк әһәмият бирелә, риязият дип атала торган физик-математик фәннәр бөтенләй юк. Гарәбияттән, фарсыдан укытыла, иң төп фәннәр Коръән тәфсире, хәдис иде. Бу белемнәр имам булучылар өчен әһәмиятле. Әмма «Мөхәммәдия»не тәмамлаган шәкертләрдән имам, михраб иясе булганнар соңгы елларда бармак белән санарлык та булмады. Мәсәлән, безнең сыйныфтан һәм янәшә сыйныфларда укыган шәкертләрдән берәүсе дә михрабка бармады. Хәтта галия курс тәмамлап, хәтме көтеб кылган Габделхәй Богдан да әүвәл «Мөхәммәдия»дә, соңыннан Казанның (?) нче мәктәбендә математика мөгаллиме булып, аның шәкертләреннән күп җәмәгать һәм совет хезмәткәрләре чыкты.

«Мөхәммәдия»нең иң кодрәтле курслары – рөшдия бүлеге. Ибтидаи сыйныфларындагы шәкертләрнең күбрәге Казан-мәхәллә балалары. Аларны күбесе башлангыч белем алганнан соң артык мәдрәсәдә укуларын дәвам итдермиләр. Авылдан килгән балаларның күбесе инде башлангыч белемне авылда алып, рөшдиянең беренче сыйныфына килеп керәләр. Болар – иң тырышып укучы төркем. Рөшдия күп фәннәрдән төп белемне бирә. Рөшдия тәмамлаган шәкертләрдән ибтидаи мәктәпләрдә зур уңыш белән эшләрлек мөгаллимнәр җитешә. Шунлыктан күпләр рөшдия курсы узганнан соң төрле өлкәләргә мөгаллим буларак таралалар. Шуннан кайберләре, хөкүмәт мәктәпләренә күчеп, урысча белем алалар…

---

[44] Әхмәтҗан хәзрәт – Б.Урманче хатирәләре арасында «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыткан Әхмәтҗан Мостафин хакында да язма бар. Чыгышы белән Саратов төбәгеннән. Урманче аның хакында болайрак яза: «Мөхәммәдия»нең өлкән хәлфәләреннән берсе, шөбһәсез, Әхмәтҗан хәзрәт Мостафин иде. Әхмәтҗан хәлфә элекке Сарытау ягында имам булып торган. Соңра имамлыгын ташлап Казанга килә һәм күп еллар «Мөхәммәдия»дә мөгаллим булып, Галимҗан Баруди вафат булгач, аның урынында 5 нче мәчетнең имамы була. Фарсыча укытты. Һәрвакыт җәмәгать эшләрендә катнашып килде. Акылы камил кеше иде. Казанның иң хөрмәтле кешеләреннән берсе Әхмәтҗан хәзрәт иде. Угыллары, «Мөхәммәдия»дә укыганнан соң, Казан университетының медицина факультасын тәмамлап, табиб булдылар. Габдеррахман, Латыйф. Кызлары[ның] берсе Рәүф Алмаев никахында иде. Алмаевлар шулай ук Сарытау вилаятеннән, Сайман авылыннан иде. Болар чын кыпчаклар булса кирәк. Шиһаб Мәрҗани заманыннан килгән бу мәгърифәт үсү дәвере дамелла Барудилар, Әхмәтҗан Мостафалар, Таһир Ильяслар чорында Мәрҗани хыял кылган мәдрәсә рәвешенә керә. Урыс теле укытучы Хәсән хәлфә зур дәрт белән эшләде. Бу да дамелланың кеше таный белүенең бер нәтиҗәсе иде. Юкса Хәсән хәлфәдән башка да Казанда урыс теле мөгаллиме табуы кыен булмас иде».

«Мөхәммәдия»не салучы Барудиның теләге дә шул иде. Парижда Сорбонна университетын тәмамлап[45], Казанга кайтып, берничә ел «Мөхәммәдия»дә мөгаллимлек иткән мәшһүр Йосыф Акчура угылы (Акчурин) «Дамелла Галимҗан әл-Баруди» (тәрҗемәи хәле) дигән китабында болай яза: «Остаз, Сез ибтидаи, игъдади вә гали тәдрисәттә яңа бер мәсләк, яңа бер ысул иҗат итдегез. Балаларның гомереләрен газиз рәхәтләрен хыянәт кылачак сәһел бер ысулны[46], хәвалидә[47] тәкъдим кылдыңыз[48]». Бу сүзләрдә җәдидлек педагогия юлы икәнлеге бик ачык. Хакыйкатән, Баруди бер сәяси мәсләк мәүҗәһсе түгел[49], чын мөселман һәм саф мөселманлык рухында яшьләрне тәрбия итү өчен көрәшә иде. Шул ук китапта Й. Акчура: «...дин үгрәтмәктә, мөнабигъ әслиядән истифадә юлыны бөек бер җәсарәтләр күрсәтеңез»,[50] – диеп яза. Тарикате нәкышбәндия мәәзүненнән[51] иде, ләкин ишанлык кылмады.

Гакыллы, фәннәрне укытуда чын Мәрҗани[нең] гая фикерләрен[52] тотты. Дөньяның культурасыннан Көнбатыш илләрендә алга киткән һәрбер белемне алу ягында иде. Хәлфәләр арасында һичбер Бохара мәдрәсәләрендә белем алган мөгаллим булмады. Сорбоннада белем алган Акчура угылы Йосыф, Каһирәдә Әзһария дарелфөнүнендә[53], Бәйрутта, Америкән колледженда белем алган затлар. Шулар арасында урыс гимназиясен һәм учительский институтта укыган урыс теле мөгаллимен алыйк. Менә педагоглар персоналы. Болар да Барудиның мәдрәсәсендә нинди рух хөкем сөргәнен күрсәтә. «Мөхәммәдия»дә белем алган кешеләр арасында түбәндәге галим һәм сәнгать осталарын күрсәтергә мөмкин: Таһир Ильяс, Әхмәд Исхак, шагыйрьләрдән Хәбиб Исхакый, Әхкәм әл-Мостафави, Мәҗид Гафури, Габдулла, Ягъкуп Адутов, Кәшшаф Тәрҗемани (Мәрҗани шәкерте), Садыйк Рахманкулов, Зәкәрия Садретдин – математик, «Кояш» редакторы, Камил Якубов, Касыйм Туйбакин, Хәсән Солтанов (беренче нарком мәгариф), Бурнашлар Фәтхи, Вафа, Йосыф Акчура, Борһан Хәбиб, Нәкый, Әмирхан, Рәхим, Газиз Гобәйдуллин, Шәрәфләр, Борнай, Баязид, Гафури, Галиәсгар Камал, артист ике Камал, Тинчурин, Сәйдәш Салих, Ямаш, Солтан Габәши, һәм, һәм... Әхәд Госманов – профессор-геолог, Хикмәт Биккинин...

Кереш мәкаләне һәм кульязма текстларны басмага
***Зөфәр Мөхәммәтшин** әзерләде.* ■

---

[45] Парижда Сорбонна университетын тәмамлап... – Й.Акчура 1900-1903 елларда Парижда «Сәяси белемнәр» мәктәбендә укый. Б.Урманче азрак ялгышлык җибәргән.

[46] Хыянәт кылачак сәһел бер ысулны – саклаучы җиңел бер ысулны. Б.Урманче төп текстта «хыянәт кылачак»ның тәрҗемәсенә җәя эчендә «коргау, саклау», «сәһел» сүзенә «җиңел» дип мәгънәләрен язып куйган.

[47] Хәвали – тирә-як, регион.

[48] Б.Урманче «кылдыңыз» сүзе белән янәшәдә «таратыңыз»ны да язган.

[49] Мәүҗәһсе түгел – табынучысы түгел.

[50] Мөнабигъ әслиядән истифадә юлыны бөек бер җәсарәтләр күрсәтеңез – чыганак нигезеннән файдалану юлын бөек бер батырлык күрсәттегез.

[51] Тарикате нәкышбәндия мәәзүненнән – нәкышьбәндия (Баһаветдин Нәкышбәнди) юлын тоту хокукына ия.

[52] Гая фикерләр – төп фикерләр.

[53] Каһирәдә Әзһария дарелфөнүне – әл-Әзһар (әл-Җәмигъ әл-Әзһар) – Каһирәдәге дини һәм дөньяви югары уку йорты. X гасырда шул исемдәге мәчет каршында оештырыла.

Безнең мирас №9 сентябрь 2022

Ранис Камартдинов: Булдыклы, фикерле кешеләр кирәк!

(Буа муниципаль районы башлыгы Ранис Рафис улы Камартдинов белән «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон әңгәмәсе)

– Ранис Рафисович, 2020 елның 23 сентябреннән Буа муниципаль районы башлыгы итеп сайландыгыз. Сез – республикабыздагы иң яшь җитәкчеләрнең берсе. Бу вазыйфага кадәр нинди юллар уздыгыз?

– 1981 елда Буа шәһәрендә тудым, әби-бабаларым да шушы яктан. Әни ягыннан Кыям бабам гомере буе районда салым системасында җитәкче булып эшләде. Әбием Сәгадәтбану балалар тәрбияләде. Әлбәттә, җәй көннәрендә колхоз эшендә булды. Әти ягыннан Рәшит бабам сугыштан кайткач ук колхозда эшли башлаган. Ул күп еллар Черкен авылындагы хуҗалыкта баш бухгалтер булып хезмәт итте. Әнием, техникум бетереп, хезмәт юлын Чүпрәле районының май комбинатында башлаган, аннары Буада яшәүче әтиемә кияүгә чыккан. Ул озак еллар дәвамында сөт комбинатында сатучы булып эшләде. Әтием исә су белән тәэмин итү системасында, соңрак «Электросеть»тә машина йөртүче булып хезмәт итте. Үзем, 1998

елда Буа мәктәбен тәмамлаганнан соң, Казан химия-технология университетының механика факультетында белем алдым. «Средневолжскнефтепродукт»та, Кадастр хезмәтендә, Росреестр тармагында эшләп, 2017 елдан Буа муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын башкардым һәм 2020 елда Буа муниципаль районы башлыгы итеп сайландым.

– Буа районы күптәннән данлыклы төбәк. Биредә авыл хуҗалыгы да, сәнәгать тә зур үсешкә ирешкән. Гомумән, төрле яклы үсеш! Нинди кыенлыклар бар?

– Проблемалар бар. Әмма аларны вакытында хәл итеп барырга тырышабыз һәм бу һәрчак шулай иде. Хәзерге вакытта авыл халкын, нигездә, өч проблема борчый: су, ут, юл. Әмма без бу проблемаларны хәл итү белән генә чикләнмибез – авылны үстерү максатында барлык мөмкинлекләрдән файдаланабыз. Юлны үзара салым, федераль программалар нигезендә салабыз, бу эш һәр торак пунктта башкарыла. 33 авылда урам яктырткычлары куйдык, Бөек Ватан сугышында һәлак булганнар истәлегенә салынган һәйкәлләрне яңарттык. Элек аларны буяп-чистартып кына торсак, соңгы ике елда 16 өр-яңаны эшләттек. 4 авылда ял итү зонасы, 5 авылда балалар мәйданчыгы булдырдык. 30 авылда волейбол, футбол, баскетбол мәйданчыклары, 2 торак пунктта авыл халкы өчен кое төзедек, 10 авылда тротуарлар салдык. Кызганыч, райондагы авылларның яртысы үзәкләштерелгән су белән тәэмин итү системасына кертелмәгән. Президентыбыз Рөстәм Нургалиевич Миңнехановка, Авыл хуҗалыгы министрлыгына һәм дәүләт программаларына рәхмәт. Бу юнәлештә дә актив эш бара. Хәзерге көндә авылларны заманча итеп үзгәртеп корырга, яңартырга барлык мөмкинлекләр дә тудырылган. Авыл җыеннары вакытында әлеге эшләребез өчен чын күңелдән рәхмәт әйтүчеләр күп. Россиянең бөтен төбәкләренә дә мондый мөмкинлек бирелми. Райондагы барлык авылларда да хәрәкәт бара, эш кайный.

Дөнья картасыннан юкка чыккан авылларыбызны да онытмыйбыз. 14 шундый торак пункт урыннарында истәлекле стелалар урнаштырдык, аларда Бөек Ватан сугышында катнашкан якташлар исемнәре язылган. Шунда туып-үскән кешеләрне табып, аларны бер-берсе белән очраштырдык, элемтәләр булдырдык. Кайбер авыл нигезләренә 30лап кеше җыелды. Бу эш дәвам итә.

Хуҗалык ягыннан карасак та, вазгыять сөенерлек. Районда 100гә якын фермер бар. Уңдырышлы кара туфракта күп кеше үсемлекчелек белән шөгыльләнә, терлекчелек икенче планда. Кызганыч, халык кооператив белән эшләүгә саклык белән карый. «Мин үз-үземә хуҗа булам! Миңа шулай яхшырак!» – дип ялгыш фикер йөртәләр, кооперативның кулай якларына төшенеп бетә алмыйлар. Мәсәлән, бәрәңге, кишер, суган үстерүче фермерлар бар. Әмма аларның яхшы, заманча складлары юк. Фермерлар аны мең газаплар белән утырта, үстерә, ә көзен арзан бәягә сатып җибәрә. Кооперация программалары нигезендә яшелчә саклагыч базлар ясасак, яшелчәне язга кадәр шунда тотып, яхшы бәягә сатар да идек. Моның өчен кооперативларга берләшү кирәк, ә халык әлегә моңа әзер түгел. Авыл агае шултикле милекчегә әйләнеп бара: бөтен әйберне дә үзем эшләсәм, арзанга төшә дип уйлый башлый. Кукмара һәм Балтач районнары сөтчелек тармагында ни өчен алга китте? Чөнки аларда сыер тотучылар терлек азыгын аерым хуҗалыклардан сатып ала. Ә бездә печәнне сатып алгач, акча бирергә кирәк, шуңа күрә бу эш файдасыз дип уйлыйлар. Ул печәнен үзе үстерә, киптерә, җыя... Шунлыктан терлекләрнең баш санын арттыра алмый. Терлек азыгы үзеге салдык,

Игенче һөнәре хөрмәткә лаек

«Юкка чыккан һәр авыл урынына менә шундый истәлек билгеләре куябыз»

халыкка аның продукциясен таратабыз – терлеккә ашатып карасыннар, аермасын күрсеннәр. Бу юнәлештә эшлисе эшләребез бар әле – терлек санын тагын да арттырасы иде. Шөкер, халыкны чүп ташламаска, урамдагы чәчәкләрне өзмәскә, матурлыкны күрергә өйрәтә алдык. Сабан туйлары уздырабыз – болыннар чиста кала, чүп калдырмыйлар диярлек. Берничә ел дәвамында кешеләрне бу яктан тәртипкә өйрәтә алдык, алга таба хуҗалык эшендә дә яңача караш формалашыр, районга да кооператив мөнәсәбәтләр үтеп керер, терлекчелек, үсемлекчелек һәм яшелчәчелек юнәлеше тагын да табышлырак эшли башлар дип ышанам.

Шөкер, быел, яңгырлар яугач, игеннәр бик яхшы уңды. Ашламасын да вакытында керттек. Моннан тыш, корылык нәтиҗәсендә туфракка сеңми калган узган елгы ашлама да үз эшен башкарды. Уракка республикада иң беренчеләрдән булып чыктык. Шөкер, уңыш сөенерлек: һәр гектардан уртача 40 центнер чамасы чыкты. Авыл хуҗалыгы министрлыгы программалары нигезендә яңа техника алабыз. Узган ел гына да 171 данә техника кайтардык. 2021 елны авыл хуҗалыгы сезонын яхшы күрсәткечләр белән тәмамлаган идек, быел да өметләр зурдан...

– Икмәк булса, җыр да була, диләр...

– Сәнгать һәр авылда, хәзерге вакытта исә һәр кырда, механизаторлар, шоферлар янында актив хезмәттә. Районыбызда агитбригадаларны җанландырып җибәрдек. Артистларыбыз төшке аш вакытларында матур итеп концерт куя. Сабан туйлары белән Россияне гиздек дияргә була: быел гына да Новосибирск, Якутия, Казан мәйданнарын гөрләттек. Новосибирскида концерт вакытында безнең килешенгән вакыт чыкты, ә халык таралмый, парк шыгрым тулы, кешеләрнең саны артканнан-арта гына бара. Ничек инде, программа бетте, дип, халыкны калдырып кайтып китәсең?! Караңгы төшкәнче концерт куйдык. Буа театрының Россия төбәкләреннән, чит илләрдән кайтып кергәне юк. Театрның җитәкчесе Раил Садриевны Беларусь Тышкы эшләр министрының хатыны вокзалга килеп үзе каршы алсын әле! Бу бит безнең сәнгатьнең югарылыгы хакында сөйли. Кая гына бармасыннар, Буа театрын беренче дәрәҗәдәге җитәкчеләр каршы ала, хөрмәтләп озата. Буа шәһәрендә дә Россиякүләм фестивальләр узып тора. Сергей Безруковның Буага килеп спектакль куюы үзе генә дә ни тора! 2019 елда театраль фестивальгә Россиянең 20гә якын төбәгеннән иҗат төркемнәре килгән иде. Һәрнәрсәне матур итеп, тиешле дәрәҗәдә үткәрер өчен, бу эшкә җанын-тәнен биргән кешеләр кирәк. Әгәр дә кешеләр көн узсынга гына утырса, берни дә барып чыкмый. Буа театры белән эшли торган планнар зурдан, хәтта кайберләрен фантастик дип тә әйтер идем. Әмма Раил Садриев кебек егетләр белән зур хыялларны да гамәлгә ашырып була.

«Буа якташлыгы» җәмгыяте, нигездә, олы кешеләрдән торса да, бер дә тик тормый. 1 сентябрьгә, картлар көненә, Яңа елга булсынмы – районга ярдәм итәргә кайтып җитәләр. Берзаман авыллардагы иске, перспективасыз социаль объектларны аукционга куеп сата башлаган идек. Сатып алучы бинаны сүтәргә, кирпечләрен сатарга, урынын чистартырга тиеш. Бу эшкә чарасызлык – берничә ел элек килеп чыккан фаҗига сәбәп булды...

«Буа якташлыгы» җәмгыяте президенты Ирек Закиров туган авылындагы перспективасыз мәктәп бинасын алды да: «Моны сүтсәм, минем йөрәк күтәрә алмаячак. Без монда үстек. Мин берәр нәрсә уйлыйм әле», – ди. Ул шул объектта яңа җитештерү ачып җибәрде, авылның 12 кешесен эш белән тәэмин итте. Хәзер

«Бу балалар – районыбызның киләчәге»

анда капчыклар тегәләр. Ирек Мөнирович әле: «Биредә кунакханә дә ясыйм», – ди. Менә шундый кешеләр авылларда күбрәк булса, туган җиребез тагын да җанланыр. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты Ринат Рәүф улы Гайзатуллин, Республикабызның финанс министры Радик Рәүф улы Гайзатуллин, «Серго исемендәге завод» җитештерү берләшмәсе – POZISның генераль директоры Радик Шәүкәт улы Хәсәнов туган авыллары Яңа Тинчәлене онытмыйлар, кайгыртып торалар. Алар ел саен матур Сабан туе уздыралар, чишмәләрне, зиратларны төзекләндерделәр, күл ясадылар, мәчет, асфальт салдылар. Радик Шәүкәт улы: «Туган нигездә нәрсәдер эшлисем килә», – дип хыялланып йөргән иде. Озак та үтмәде, истәлекле объект – ял паркы ясады, анда истәлек ташы куелды. Рашат Кәлимуллович та Килдураз авылында «Гыймран» мәчетен салдырды. Эшмәкәр Рөстәм Нургасыйм улы Сүлтиев пандемия вакытында хастаханәгә 10 миллионлык иганә кертте, җиһазлар алырга булышты. Төзелеш министры Марат Мансур улы Айзатуллин ярдәме белән дә районда бик зур төзелеш эшләре башкарыла.

Районда идеяле кешеләр дә бик күп. Әйткәнемчә, Раил Илдар улы Садриев гел йөреп тора, һәр җирдә күргән яхшы үзгәрешләрне миңа да хәбәр итә. Аның шундый ук абыйсы Фоат Садриев та бар. Мин аны район киңәшмәләренә дә чакырам. Безгә акыллы, булдыклы һәм тәҗрибәле кешеләрнең фикерләре дә кирәк.

Шөкер, зарланырга урын юк, эшлисе эшләр күп.

– Кайда яхшы нәрсә булса, буалылар шуны күреп, үзләренә өлге итеп, әйбәт итеп башкарып чыгу ягында. Уңышлар юлдаш булсын Сезгә! ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – галимнәр, язучылар, журналистлар һәм сәнгать әһелләре сентябрь аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә.

7 сентябрь – сәнгать белгече, сәнгать фәннәре кандидаты **Фирдәүс Гомәр кызы Вәһапова**га 60 яшь (1962);

15 сентябрь – журналист, шагыйрә, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре (1993), Татарстан журналистларының Х.Ямашев исемендәге премиясе лауреаты (1994), «Бәллүр каләм-2002» иясе, С.Сөләйманова исемендәге премия лауреаты (2008) **Асия Шәйхразый кызы Юнысова**га 75 яшь (1947);

18 сентябрь – җырчы, конферансье, режиссер, язучы-сатирик, җырлар авторы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2008), 2008 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы **Алмаз Наил улы Хәмзин**га 75 яшь (1947);



18 сентябрь – шагыйрә һәм прозаик, филология фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклсе (2017), ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең Ф.Хөсни исемендәге әдәби премиясе лауреаты, С.Сөләйманова исемендәге премия лауреаты (2008), 1996 елдан ТР Язучылар берлеге әгъзасы **Рифә Фәтхрахман кызы Рахман**га (Харрасовага) 60 яшь (1962);

20 сентябрь – актер, режиссер, ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты **Камил Шакир улы Вәлиев**кә 80 яшь (1942);

29 сентябрь – тел галиме, текстолог, филология фәннәре кандидаты, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Әнисә Хәниф кызы Алиева**га 70 яшь (1952).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2022

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов

Кантон (Гуанчжоу) порты. XIX гасыр

Тагын миссионерлар

Мин Кантон һәм аның әйләнә-тирәсендәге берничә монастырьны да барып карадым. Харбинда яшәгәндә, мәшһүр сәяхәтче Ладыгин җәнапларыннан алган киңәш буенча, үземне Кытайның Алтышәһәр дигән җиреннән килгән, дөнья белән алыш-бирешен өзгән бер дәрвиш сыйфатында таныттым. Киемнәрем дә кытай киеме, кашгар сөйләшендә сөйләшәм, тәрҗемәче дә алар кешесе иде. Мине тәмам Кашгарлы итеп кабул итеп, Кытай Төркестаны мөселманнарының кайбер гадәтләрен шәригатькә сылтап, тел озайтып маташканнар иде, җавап кайтармадым, башымны дәрвишлеккә салдым. Шулай да, Алтышәһәр тирәсендә һәм Тарбагатайдагы миссионерларның мәҗүсиләр арасында азмы-күпме уңышлары булса да, мөселманнарга бернинди дә йогынтылары юклыгын әйтми калмадым.

Болар миңа хөрмәт күрсәтергә уйладылар, монастырьларының бөтен җирен күрсәттеләр. Бик матур бүлмәләр күрсәтеп, әгәр атна-ун көн кунак булып калырга теләсәм, шуннан бер бүлмә бирәчәкләрен дә әйттеләр. Йөзләренә елмаю чыгарып, бер яшь хезмәтчем булачагына да ишарә итеп, бик кунакчыллык күрсәттеләр. Бу кунакчыллыкның христианлыкның изге сыйфатларыннан берсе икәнен әйтергә дә онытмадылар.

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Мин исә гел дөнья белән бәйләнешен өзгән дәрвишлек турында сөйләдем, дүрт-биш көннән килеп кунак булырмын, дип кабатлап тордым. Утырып гыйбадәт кылу өчен бүлмәнең күңел рәхәтлеге бирә торган булуын әйтеп, ничек тә бераз-га читкәрәк тайпылу, аннары китеп бару ягын уйлый идем. Мине бик тә кунак итәселәре килде, тик, Аллаһка хәмд булсын, караңгы төшкәнче ычкына алдым. Ул көнне бу тирәләрдә калмыйча, шунда ук соңгы пароход белән Ханканга кире кайтып киттем.

Әлеге котылып булмый торган корткычларның тырышлыгын игътибарга алып, тирәннән уйлансаң, боларның үз вазыйфаларын башкарудагы ныклыгын күреп гаҗәпләнмәү мөмкин түгел. Бичара кешеләр, диннәренең хак дин түгеллеген сизеп белсәләр дә, милләтләренең киләчәге хакына шул динне корал итеп, хөкүмәтләренең бөтен сәяси фикеренә үзләрен корбан итәләр, һәртөрле авырлыкка, мәшәкатькә түзәләр; ватаннарына, милләтләренә хезмәт итү өчен, туган җирләрен, кардәшләрен, якыннарын калдырып, чит җирләргә китәләр.

Кайбер җаһилләре исә бу фидакярлекне дин өчен эшләнә дип кабул итәләр. Боларның күбесе чакыру, өндәү юлы белән эш итә, кайберләре боларның чыгымын күтәрү өчен теләнчелекне сайлый. Шул рәвешле, бүгенге көндә йөз меңнәрчә, бәлки, миллионнарча кеше, диннәре хакына яки диннәрен корал итеп, милләтләре хакына фидакярлек күрсәтә. Икенче яктан, байлар, акча хуҗалары, шул гамәлләр өчен миллионнар тотып, ярдәмгә ташланалар.

Бүгенге көндә боларның «явы» Хиҗаз якларында гына юк, дип әйтә алабыз. Көнчыгышның башка бөтен җирендә дә болар бар. Дөресен генә әйткәндә, христианнарның өндәү юлында күрсәткән фидакярлекләре игътибарны да җәлеп итә, гаҗәпләндерә дә.

Инде безнең голамәбез турында

Пәйгамбәрләр варисы сыйфатын алырга теләсәк тә, үзебезне баштанаяк бер тикшереп карасак, ни өчен һәм ник варис булуыбызны тәгаен генә әйтә алмыйча, бөлгенлегебезне игълан итәчәгебез көн кебек ачык.

Дөньяда безнең мондый вазыйфабыз бармы-юкмы – бу хакта голамәбезнең дә, әмирләребезнең дә, хәлифәләребезнең дә, мал ияләренең дә – берсенең дә хәбәре юк. Бик кызганыч, йөз кат, мең кат кызганыч: без менә нинди хәлләргә төштек. Мөселман булмаганнарны өндәү кулыбыздан килми дә килми инде, ә менә ата-бабадан мөселман булган кардәшләребезне кәферлектә гаепләргә җөрьәт итәбез. Бер-берсен кәферлектә гаепләү осталыгы безнең голамәбездә арткан-нан-арта бара. Инде безнең бөтен эшләребез баштүбән килде. Милләтебезне җаһиллек басты, исламның кодрәтен аңлау кимегәннән-кими бара, бүгенге көндә кайбер голамәбезнең дине динар[1] булды. Хак дин хакына үзен фида итү юк та юк инде, әле саф һәм пакь шәригатьне үз кәеф-сафалары өчен чара да иттеләр.

Инде безгә җитәкче булырга тиешле голамәбезнең хәлен инсаф белән үлчәп, вөҗданыбызга мөрәҗәгать итеп хөкем йөртсәк, голамәбезнең безне һәлакәт чоңгылына өстерәвен күрмичә-танымыйча булдыра алмыйбыз.

Белмим, бу гафләт бездә кайчанга кадәр дәвам итәр, кайчанга кадәр голамәбез бу юл белән барыр, кайчан без хак дин исламның хакыйкатьләрен, һич булмаса, бу өммәткә аңлата алырбыз. Боларны уйлап, тирән өметсезлеккә батасың, алда

[1] Динар – латин теленнән гарәп теленә кергән һәм акча берәмлеген белдергән сүз. Исламга кадәрге чорда гарәпләр Римның алтын акчасын таныганнар, кулланганнар *(тәрҗ.иск.)*.

өметләнерлек берни күрмисең. Чарасыз калганыңны аңлап, иреннәреңне генә кыймылдатып: «Мәүләм хәлебезне төзәтә күрсен», – дияргә мәҗбүр буласың.

Һай, кайда соң безнең мөселманнарда намус һәм иман гайрәтенә ия кешеләр, вөҗдан ияләре кайда?! Һичьюгы шул голамә булып йөргән кайбер җаһилләрнең кем икәнен милләткә ачсыннар иде, һичьюгы безгә юл күрсәтсеннәр иде!..

Дөресе генә: хәлебезне уйлап, аптырау белән чарасызлык арасында килеп-китеп йөрисең дә йөрисең.

Мин биредә Һиндстан мөселманнарының байтагы белән таныштым, Абдуллаһ Факир һәм Абдулкадыйр Иса Баһаи җәнаплары белән кабат-кабат күрешеп сөйләштем. Ислам диненең бүгенге хәле турында сөйләшкәндә, берничә тапкыр сүз Госманлы идарәсенә барып тоташты. Шулвакыт Абдуллаһ Факир: «Дәүләте Галиянең[2] күтәрелүе бөтен мөселманнарның яшәеше дигән сүз, – дип, берничә тапкыр кабатлады. – Бу җәһәттә бөтен мөселманнар да бер-берләренә таяныч була алалар», – дип тә өстәп куйды.

Беркөнне әлеге шәхеснең өендә мәмләкәтнең алдынгыларыннан берничә кеше җыелган иде. Мин дә килгән идем. Сүз җае чыккач, мин Госманлы Диңгез көчләре җәмгыятенең[3] ватан һәм милләт өчен күрсәткән дини гайрәте турында сөйләдем. Чыгышымның ахырында бөтен мөселманнарның бу изге эшкә катнашуларының кирәклеген дә аңлатып киттем. Шулвакыт, Абдуллаһ Факир җәнаплары, мондый мөкатдәс вазыйфага катнашу өчен бернинди дә киртә юклыгын, ләкин милләтләр арасында якынлык булмау һәм бер-берсен танымаулары мөселман дөньясының артталыгына сәбәп булып торуын әйтеп, күз яшьләрен сөртте.

Әгәр мин анда тагын да бераз кыюлык күрсәткән булсам, шунда ук әлеге җәмгыятькә ярдәм исемлеге төзелгән булыр, шуңа хәзер кешеләр бар иде. Ләкин бу эшләр вазыйфама керми иде шул, шуңа җөрьәт итә алмадым. Югыйсә андагы мөселманнарның калебләре кесәләрен бушатырлык булып тулган иде.

Мин мондый хәлләргә әле тагын бик күп җирдә шаһит булдым. Бөтен мөселманнарның калебләре гел бер үк мәркәзгә юнәлгән булуын күреп аңладым. Бичара мөселманнарга голамәбез, җирле голамәбез, җитәкче булып юл күрсәтсә, ярдәм итүнең, бер-беренә таяныч булуның, ярдәмләшүнең мәгънәләрен тиешенчә аңлатса, һичшиксез, бөтен мөселманнарның бу юлда гайрәт итеп, көчләрен кызганмыйча сарыф итәчәкләре көн кебек ачык.

Мин Ханканда яшәгән көннәрдә мөбарәк Рамазан ае килде. Җомга көн, милади 17 сентябрь иде. Аллаһының рәхмәте булган Рамазан көннәрендә һаваның эсселеге 33-35 дәрәҗәгә кадәр күтәрелә иде. Мөселманнарның шундый вакытта да дини бурычларын зур сөенеч белән үтәүләрен күреп, шатланып хуплыйм, шөкерләр итә идем. Бөек Мәүләм бу мөбарәк көннәрне хозур эчендә үткәрүне насыйп әйләсен.

Беркөнне очраклы рәвештә бер кеше белән таныштым. Сүз арасында үземнең Кантон шәһәрендә булганымны әйттем. Сәйидина Саад бин (Эби) Ваккасныкы дип саналган мәчетнең төзелү вакыты турында сүз башладым. Бу кеше миңа болай диде: «Мин биредә туып-үстем. Моннан бер илле еллар элек, Кантон шәһәренә баргач, ул мәчетнең диварына чокып язылган язуны, төзелгән елын бик ачык укы-

[2] Госманлы дәүләтенең бер атамасы *(тәрҗ.иск.)*.

[3] Госманлы дәүләтендә 1909 елда флотның башка илләрнекеннән артта калмавын, алга китүен тәэмин итү өчен корылган җәмгыять, 1919 елга кадәр эшчәнлек күрсәткән. Халыкның хәлле өлешенең ярдәме белән тупланган хәзинә флот өчен генә тотылмаган, дәүләтне көчәйтү өчен, җәмгыять башка өлкәләрдә дә эшчәнлек алып барган *(тәрҗ.иск.)*.

Кантон (Гуанчжоу) портындагы Хайчжу күпере. XIX гасыр

ган идем». Бу кеше нәсел-нәсәбе белән Бонибар кешесе, хәзерге көндә Ханканда яши, исеме – Нуман (Ногман) Сахиб.

Мин Кытай ярларындагы соңгы көннәремне үткәрәм. Көнчыгышның ерак җирләрендә шактый кеше белән таныштым. Аллаһы Тәгаләгә хәмд һәм шөкерләр булсын, мөселманнарның хәле һәм бигрәк тә Кытай мөселманнарының бүгенге яшәеше турында билгеле бер дәрәҗәдә мәгълүматлы булуга ирештем. Мөселманнарның, гомумән алганда, артта калуга дучар булуы күпләргә мәгълүм һәм кабул ителгән хәл иде. Тик болар арасында Кытай мөселманнарының хәле бөтенләй башкача. Болар турында: «Бөтен яктан беткән, харап булган, хәтта исламиятнең боларда бары исеме генә калган», – дисәм дә, һич кенә дә арттыру булмас. Мин бөтен вөҗданым белән мөселманнарның күтәрелүен телим, тик ни чара, үземне юатыр өчен генә булса да яхшыны уйлый алмыйм. Бүгенге көнгә кадәр бөтен мөселманнарның артта калганлыгына, бәлки, ялагайлык һәм чир яшерү гадәте сәбәп булгандыр?!.

Ханканнан китәргә җыенам, тик: «Кая китим, ничек китим икән?» – дип уйланам. Кесәмдә җилләр уйный. Пароход белән Сингапурга китәргә уйласам, күп акча кирәк. Коры җир буйлап Тонкинга китсәм, берничә айлык юл үтәргә кирәк. Хәлемне берәүгә дә белдерәсем килми. Чыгар юлны үземнең табасым килә, ләкин бер чара да таба алмыйм. Чара була алыр кеше дә очрамый. Кытай илендә өч айга якын йөрдем, булган бөтен акчамны тотып бетердем. Аптырашта калган көннәрем. Шулай беркөнне гарәп милләтеннән ике яшь кеше белән таныштым. Берсенең исеме – Әхмәт, икенчесенеке – Мөхеддин. Болар бирегә инде бик күптәннән, аталарына ияреп килгән булганнар. Яши-яши баеганнар, өйләнгәннәр. Кытайлар белән дә бәйләнешләре нygыган. Бу кешеләр миңа олы ихтирам күрсәттеләр. Зур булмаган хосусый кораблары да бар икән. Шуңа утырып, Ханкан тирәли берничә тапкыр сәяхәт иттек. Якын-тирәдәге авылларны да карап йөрдек. Ханкан тирәсендә авыллар бик күп. Берничә мөселман авылы да бар. Бу яшь кешеләр ярдәмендә шактый кеше белән таныштым. Лиан-Фу дигән авылда бер мөселман сәүдәгәрнең

өендә кунак булдык. Аһ, исламият! Бу җирләрдә ул бик тә сәер, бик тә! Боларны күреп, кайгыга батасың, күзләрдәге яшьне тыеп торып булмый. Як-яктан теге котылып булмый торган корткычлар сырып, бар яктан җаһиллек басып алган. Бары тик рухи ярдәмгә генә таянып торган хәлләр бу. Нишләмәк кирәк, мин – чарасыз, чит-ят җирдә. Теләсәм-теләмәсәм дә, *исламны читләр башлаган кебек, ахыры да читләргә калачак,* дигән хәдисне кабатлыйм, соңгы җөмләсен генә хәтерли алмыйм. Югыйсә хәдиснең дәвамы да бар. *Бу читләргә сөенечле хәбәр булсын. Болар кешеләр бозганны төзәтерләр* яки шуңа якын мәгънә[4].

Сәбәбе ни генә булса да, берәр нәрсәнең гел өметсез ягы хәтердә яхшы кала. Хәдиснең аннан соңгы җөмләсен искә төшереп сөйләүче бер генә мөселман кешесе дә табылмады.

Бичара кытай мөселманнары... 100 йортлы авылларында ник бер мәктәп, ник бер мөгаллим, укыту-өйрәтү булсын! Без кунак булып төшкән өйнең хуҗасы, авыл халкы турында сөйләгәндә, үз матди көче белән мәктәп ачарга теләгәнен, ләкин укытучы таба алмавын еларлык булып аңлатып бирде. Мин дә кайгырдым, сызландым. Тик мин нишли алам соң, кулымнан нәрсә килсен?! Миссионерлар җитештерә алмадык, мөгаллимнәр җитештерә алмадык, шулай булгач, чарасыз, кайгырудан башка берни эшли алмыйбыз.

Мин, шулай булса да, Җәнабы Хакка шөкер итәм, йөз мең телдә шөкер итсәм дә аз. Һичьюгы бу кадәр булса да мәгълүмат җыярга ярдәм иткән кардәшләрем Мөхеддин һәм Әхмәт белән танышуыма сәбәп тагын да шул ук кыйммәтен тәкъдир итеп бетерә алмаслык исламият иде. Йөз мең җаным булса, йөз меңе дә фида булсын, беребезнең сырхавын барчабызга бер сүз белән хис иттерә ала.

Кытай яр буйларында мөселман сәүдәгәрләр

Кытай ярларында урнашкан һәр шәһәрдә мөселманнардан зур сәүдәгәрләр бар. Ханканда да алар бик күп. Болардан иң мәшһүрләре һәм танылганнары – Иса Баһаи, Әмин Баһш, Али Рыза, Балич Вала, Немази, Меһдийоф һәм башкалар. Яр буйларында боларның сәүдә йортлары урнашкан. Япониядән алып Ак диңгезгә кадәр һәр сәүдә портында аларның исемнәрен укырга мөмкин.

Алар арасында дини ныклыклары белән билгеле кешеләр дә аз түгел. Мөселманлыклары белән горурланучы кешеләр булганга, мондый шәхесләрнең бу җирләрдә яшәве, эшчәнлек алып баруы, дөресен генә әйтик, безнең өчен, исламият өчен зур дәрәҗә.

Мин боларның күбесе белән күрештем. Мөхәммәд Хәсән Немази җәнаплары белән хәтта Ханканнан Сингапурга кадәр юлдаш та булдык. Якынча 45 яшендәге бу саф мөселман кешесе инглиз телендә мөкәммәл дәрәҗәдә сөйләшә, зур капитал хуҗасы булуы йөзеннән үк аңлашылып тора иде. Ул Һиндстан, Кытай, Иран белән сәүдә итүе, тиздән Америкада һәм Япониядә сәүдә бүлекләре ачачагы турында сөйләде.

[4] Исламны читләр башлады, ахыры да читләргә калачак, дип тәрҗемә ителсә дә, бу хәдиснең мәгънәсе гаҗәеп тирән. Хәдисләрнең мәгънәләре хакындагы әдәбиятка нигезләнеп, шуны әйтергә мөмкин: «читләр» сүзе күпчелек тарафыннан аңлап кабул ителә алмаган кешеләр төркемен, сәхабәләрне күз алдында тота. Динне алар җәелдерде. Димәк, ниндидер сәбәпләр аркасында, динне ахырда да азчылыкны тәшкил итүче «читләр» яшәтәчәк. Хәдиснең дәвамында: «Бу «читләр»гә сөенечле хәбәр булсын. Болар Хәзрәте Пәйгамбәрнең кешеләр бозган сөннәтен төзәтерләр», – дип әйтелгән *(тәрж.иск.)*.

Бу яшь кеше, шундый зур капитал хуҗасы булса да, юмарт, бик тыйнак һәм сабыр холыклы иде. Мондый кеше белән танышу минем өчен, чынлап та, сирәк очрый торган язмыш бүләге булды.

Безнең Русия мөселман сәүдәгәрләре арасында чәй белән сәүдә итүчеләр бик күп, болар кебек дәрәҗәле шәхесләр белән танышсалар һәм сәүдә алып барсалар, никадәр зур уңышка ирешерләр иде. Матди мәнфәгатьтән бигрәк, рухи мәнфәгать тәэмин ителер иде. Ләкин нишләмәк кирәк, гомуми җансызлык безнең гәүдәләребезне оеткан, бер-беребездән хәбәребез юк, тере мәет хәлендә без. Мин бу хөрмәтле шәхесләр белән күп тапкырлар фикер алыштым, алардан бик күп нәрсә өйрәндем. Аеруча Кытайдагы сәүдәнең кайбер үзенчәлекләре турында кабат-кабат сораштым, фикерләре гел бер-беренә бик якын була иде.

Алар: «Кытайда сәүдә әле яңа гына башланган, әлегә тиешенчә ачыкланып бетмәгән, киләчәге бик якты, табышы мул», – диләр иде. Бүгенге көндә Кытайда сәүдәнең бөтенләй чит ил кешеләре кулында булуы, бигрәк тә инглизләрнең бик зур файда күрүләре, Англиянең мал көченең зур өлеше Кытайдан тәэмин ителүе турында сөйләделәр. Бу хакта кайда гына, кем белән генә сөйләшсәм дә, гел шушы фикерләрне ишетә идем. Шул ук вакытта мөселманнарның, бигрәк тә Госманлы мөселманнарының сәүдә сәнгатеннән мәхрүм калган булуларын күреп кайгыруларын белдерәләр иде. Чынлап та, милләт бу җәһәттән борчуга сала, күңелне төшерә.

Үзем үткән юлларда мин бик күп мәмләкәтләрдә булдым. Кайда гына булсам да, дәрәҗәле мөселман сәүдәгәрләре иран, һинд, кытай, хәтта гарәп кешеләре булып чыга, тик бер генә госманлы сәүдәгәре дә очрамый иде.

Шунысы сәер: кайда гына булсалар да, нинди генә милләттән булсалар да, мөселманнар госманлыларга хөрмәт белән карыйлар, аларны дус күрәләр, үз араларында берничә генә булса да госманлы сәүдәгәрен күрергә телиләр иде. Мин бу якын итүне бары тик мөселманнар арасында гына түгел, бөтен Көнчыгыш халыклары арасында да тоя идем. Пекинда яшәгәндә, Һиндстаннан килгән бер мәҗүсинең чыгышын тыңлаган идем. Тыңлаучылар бер 500ләп кеше булгандыр. Чыгышы вакытында, сүз иярә сүз чыгып, сөйләүче Госманлы инкыйлабына да кагылып үтте. Менә шундый фикерләр әйтте: «Госманлы хөкүмәтенең тәрәккъыяте бөтен Көнчыгыш халкы өчен дәрәҗә булып тора. Госманлы халкының яшәеше – бөтен Көнчыгышның яшәеше. Госманлының җимерелүе бөтен Көнчыгыш милләтләре өчен үлем белән бер булачак. Шул сәбәпле, госманлыларның якын киләчәктә көрәш мәйданында үз барлыкларын күрсәтүләрен самими рәвештә өмет итәбез».

Бу сүзләрне әйткәннән соң, мәҗлестә мөселман кешеләре аз булуга да карамастан, сөйләүче бик көчле алкышларга күмелгән иде. Моннан тыш, японнарның да госманлыларга булган ихтирамы турында алда күп тапкырлар язып үттем.

Инде минем уем болай: яңа Госманлы хөкүмәте, алда бу җәһәтләрне игътибарга алып, Көнчыгыш милләтләре арасында икътисади мөнәсәбәтләр, һич булмаса, танышып белешерлек бер юл ачса, һичшиксез, матди һәм рухи гомуми мәнфәгать өчен бик зур файда килер иде. Мин һәр җирдә, бигрәк тә Кытай илендә әлеге хакта бик күп чыгышлар ясадым, кулымнан килгән кадәр, мөнәсәбәтләрне яңарту турында сөйләдем. Болар турында кайда гына чыгыш ясасам да, гел хуплау күрдем, әледән-әле алкышларга күмелә идем.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2022

Морад Рәмзи хакында фикер-күзәтүләр

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

Морад Рәмзи

Туган төбәгендә дистә еллап белем алганнан соң, 17-18 яшьләрендәге үсмер егет үзенең остазы, кардәше Хөснеддин хәзрәт юлламасы белән, Казанга – Мәрҗани мәдрәсәсенә килә. Ни сәбәптәндер, биредә ул озак укымый: ел ярымлап вакыттан соң Урта Азия тарафларына юнәлә. Әмма юлда барышлый Троицк каласында туктап кала. Биредә Шәрәфеддин һәм Мөхәммәдҗан хәзрәтләрдән сабак алуы, шулай ук бераз вакыт казакъ балаларын укытуы билгеле. Морад Рәмзи, Троицкида ел ярымлап яшәгәннән соң, якынча 1876 елда Ташкент-Бохара тарафларына килеп җитә. Бу калаларда аның Габдулла әс-Сарытауи, әл-Казани, әт-Төрекмәни кебек остазлардан сабак алуы, Нәкышбәнди тарикате тарафдарлары белән аралашуы, күпсанлы дини-суфыйчыл китаплар белән танышуы мәгълүм…

«Сәфәргә күнеккән кеше юлны сагыныр»,– дип юкка гына әйтмиләрдер. Бохара һәм Ташкент шәһәрләрендә ике еллап яшәгәч, Морад Рәмзи, белем алу һәм дөньяны күрү нияте белән, Гарәбстан якларына барырга карар кыла. 1878 елның урталарында ул бер иптәше («Казанлы») белән юлга чыга. Самәрканд, Кабул, Пиша-

Ахыры. Башы журналның 8 нче (2022) санында.

вар, Хайдарабад аша Бомбейга килеп җитәләр. Биредә аның өч айлап торуы билгеле. Аннан пароход белән Хиҗазга юнәлә.

Морад Рәмзи 1878 елның ахырларында Гарәбстан туфрагына аяк баса, Җиддә шәһәреннән Мәдинәгә килә. Бераздан инде ул янә Мәккәдә: биредә хаҗ кыла, бу шәһәрне үзенең төп һәм дәвамлы яшәү урыны итеп сайлый. Әмма вакыты-вакыты белән Мәдинәдә дә укып, яшәп ала. Морад Рәмзинең Мәккә-Мәдинә чоры 40 елга якын, ягъни 1914 елга кадәр сузыла. Гарәбстанда яшәүнең тәүге чорында ул берничә урында төрле остазлардан белем ала. Болар арасында шул чор ислам дөньясының Шәйх Мазһар, Абделхәмид Дагыстани, Салих Завави, Дамелла Наманган, Абдерахман Сараҗ кебек билгеле шәхесләр бар [4: 26-27]. Морад Рәмзи тиз арада үзе дә Мәккә-Мәдинәнең абруйлы, укымышлы заты буларак таныла. Аның вәгазь-чыгышларын яратып тыңлыйлар, киңәш-тәләкләренә колак салалар. Морад Рәмзине аеруча суфыйчылыкның Нәкышбәнди тарикате тарафдарлары хөрмәт итә. Аларның теләк-ихтыяҗларын исәпкә алып, ул Кәшифинең (1463-1531) «Рашахат...», Имам Раббанинның (1564-1624) «Мактубат...» кебек атаклы әсәрләрен фарсычадан гарәпчәгә тәрҗемә итә. Шунысын да искәртик: Морад Рәмзи, туган теле – татар теленнән тыш, гарәп, фарсы, урыс, госманлы һәм кайбер башка телләрне яхшы белә, аларның берничәсендә укый, яза, сөйләшә.

Гарәбстанның Мәккә, Мәдинә, Җиддә кебек калалары элек-электән татар-төркиләрнең дә үзенә күрә бер туплану, мәркәзи үзәге булган. Аларда белем алучы, гомер кичерүче милләттәшләребезнең саны да, мөгаен, меңнән артып киткәндер. Татар мәчетләре булуы да билгеле. Килеп-китүче, хаҗ сәфәре кылучы милләттәшләребез аеруча күп була. М.Рәмзи – шундыйларны туплаучы, рухландыручы шәхесләрнең иң күренеклеләреннән берсе. Аның Тукай тарафыннан бераз хаксызгарак бәдәлчелектә (ягъни башкалар өчен ялланып хаҗ кылуда) тәнкыйтьләнүе дә [2: 467-469], мөгаен, шуның белән бәйледер. Морад Рәмзинең шактый зур гаилә башлыгы булуын да онытырга ярамый. Балаларны туклындырырга, киендерергә, укытырга һәм тәрбияләргә дә кирәк бит.

Мәгълүм ки, Морад Рәмзи 1895 елда Тәтеш өязеннән («из деревни Шеп Башы») Мәккәгә килгән Әсма исемле кызга өйләнә [4: 27]. Тугыз балалары була. Шуларның дүртесе яшьли үлә. Исәннәреннән аеруча Фәһми (Фәһим) Морад исемле улы (1899-1965тән соң) билгеле. Ул Истанбулда мөгаллимнәр әзерләүче уку йортында һәм Берлин университетының медицина факультетында белем ала.

Дөнья матбугаты, аеруча Рәсәйдән килеп-китүчеләр аркылы Морад Рәмзи ил, үз кавеме хәлләреннән шактый хәбәрдар була. Хәтерем ялгышмаса, Якын Көнчыгышның дистәләгән илләре, калалары, кавемнәре кебек, Гарәбстан, шул исәптән Мәккә-Мәдинәләр дә Төркия Җөмһүрияте төзелгәнчегә, ягъни узган гасырның башларына, төгәлрәге, 1918 елга кадәр Госманлы империясе составында була. Шуңа мөнәсәбәттә Морад Рәмзинең дә бу ил гражданы хисаплануы табигый һәм мантыйкый. Татар галименең Истанбулга күчү теләге дә була, әмма ул, аерым сәбәпләр аркасында, гамәлгә ашмый кала. Шулай да Морад Рәмзи бу калада берничә мәртәбә була. Морад Рәмзинең 1923 ел башында улы Фәһми белән Истанбулга күзенә катарактадан операция ясатырга баруы билгеле. 1926 елда килүендә ул бу калада төрек галимнәре, шул исәптән мәшһүр Фуат Күпрелезадә белән дә очраша.

Морад Рәмзи Мәккә-Мәдинәдә яшәү чорында үзе генә дә, гаиләсе белән дә берничә мәртәбә Рәсәйгә кайтып килә. Әмма 1914 елгы кайтуында ул, Беренче бөтендөнья сугышы тудырган сәбәп-киртәләр аркасында, биредә тоткарланып

кала. Бераз Казанда яшәп алганнан соң, Морад Рәмзи, гаиләсен хатынының Тәтеш өязендәге туган авылында калдырып, улы Фәһми белән 1915 елда Урта Азиягә барып чыга, андагы Ташкент, Бохара, Куканд, Әндиҗан һәм Наманган шәһәрләрендә була, элекке таныш-белешләре белән очраша, яңаларын да булдыра. Идел-йортка әйләнеп кайткач, бераз вакыт Оренбург тирәсендәге Тоз-Түбәдә (хәзерге вакытта күпләрнең ял итә торган урыны) яшәп ала. Дөньялар тагын да тынычсызлануын күреп, Морад Рәмзи янә улы белән бергә Төркия сәфәренә чыгып китә. Әмма төрекмәннәр күтәрелеше аркасында юлда тоткарлана. Урыс хакимияте аны кулга алып, Уфа төрмәсенә утырта. Өч айдан артык зиндан газапларын чиккәч, дуслары, танышлары аны бу бәладән коткаралар. Биредә, әлбәттә, төп һәм хәлиткеч рольне күренекле милләттәшебез Хәсән Акчура уйный. Аның Петроградта Рәсәйнең эчке эшләр министры белән очрашуы мәсьәләне уңай якка хәл итә. Нәтиҗәдә, Морад Рәмзи Оренбургка гаиләсе янына әйләнеп кайта, биредәге иҗтимагый милли-дини тормышта актив катнаша. Аның 1917 елның июлендә Казанда үткән Мөселман руханилары корылтаена Оренбург вәкиле итеп сайлануы да күп нәрсә хакында сөйли. Биредә аның доклад-чыгышлар ясавы да мәгълүм.

«Морад Рәмзи Кытайда яшәү чорында да иҗтимагый, дини, рухи тормышның үзәгендә кайный, үзенең саллы, абруйлы киңәшләре белән төрле каршылыкларны хәл итүдә дә катнаша. Мөселман кавемнәренең мәнфәгатьләрен яклап, ул хәтта рәсми хакимият белән дә каршылыкка керә. Халык аны дәррәү яклый. Аның вәгазьчыгышларын ерак тарафлардан да килеп тыңлыйлар.

***

Әйткәнебезчә, Морад Рәмзи Гарәбстан якларында дүрт дистә елга якын вакытын уздыра. Әмма еракта яшәсә дә, ул Идел-йорт белән тыгыз бәйләнештә тора. Бу аеруча 20 нче йөз башларында көчле була. Аның төрле темаларга язылган күпләгән мәкаләләре «Дин вә мәгыйшәт», «Шура» кебек мәгълүм журналларда нәшер ителә. Басылган китаплары да бар. Боларда авторның киң карашлы, төпле фикерле галим, дин әһеле, журналист-публицист булуы ачык күренә. Морад Рәмзи бу елларда бигрәк тә үзенең «Тәлфикел-әхбар вә тәлкихес-асарь фи вакаиги Казан вә Болгар вә мөлүкет-татар» [«Казан вә Болгарда булган вакыйгалар һәм татар ханнары (мәликләре) турында хәбәрләр вә әсәрләр тупланмасы»] китабы белән танылa. Гарәп телендә язылган шактый күләмле әлеге хезмәт 1908 елда Оренбургта Хөсәенов-Кәримовлар нәшриятында ике томда дөнья күрә [6]. Аны чыгаруда Зәйнулла Рәсүлев (1833-1917) матди ярдәм күрсәтә. Шунысын да искә төшерик: Троицкида яшәгән бу мәшһүр зат белән Морад Рәмзи бик тә дустанә мөнәсәбәтләрдә тора. Ул вафат булгач, аның рухына багышлап махсус мәрсия дә яза.

«Тәлфикел-әхбар...» чыгу белән үк җәмәгатьчелектә хуплау тапты. Ризаэддин Фәхреддин аны «Шура» журналында басылган язмасында (1908, №6, 145 б.) болай дип бәяләде: «Ниһаять, безнең милләт тә бу асарь йөзендә үз тарихының лаеклы чагылышын тапты». Профессор Н.Катанов үзенең цензорлык бәяләмәсендә, бер

яктан, Морад Рәмзи хезмәтен уңай бәяли, икенче яктан, анда патша хакимиятенә, урысларга тискәре карашлар булуын да искәртә [1]. Шуның нәтиҗәсе буларак, «Тәлфикел-әхбар...» басмасы конфискацияләнә, авторына карата суд тикшерүләре башлана. Бу эш берничә ел дәвам итә. Морад Рәмзине кулга алынудан бары тик чит илдә яшәве генә коткарып кала. Китапның бер өлеше инде таралып өлгергән була. Чит мәмләкәтләрдә, аеруча ислам дөньясында, Төркиядә ул халкыбызны дөньяга танытуда мөһим роль уйный. Аны хәзер дә укыйлар, фәнни хезмәтләрдә файдаланалар.

«Тәлфикел-әхбар...» һәм исеме, һәм эчтәлек-рухы белән Шиһабетдин Мәрҗани традицияләрен дәвам иттерә, бөек шәхесебезнең халкыбыз тарихы турындагы карашларын тагын да тулыландыра, бөтәйтә. Билгеле булганча, Морад Рәмзи бу хезмәтенә әзерлек эшләрен 19 нчы йөзнең 80 нче елларында ук башлый. Моңа кадәр безгә билгеле һәм билгесез күпсанлы чыганакларны өйрәнә. Алар арасында, әлбәттә, төп урынны гарәп, фарсы, төрек телләрендәге шәркый хезмәтләр алып тора. Үзебезнең җирле тарихи, әдәби, фольклор материаллары да файдаланыла. Автор урыс телле хезмәтләргә, чыганакларга, рәсми документларга да еш мөрәҗәгать итә. Кыскасы, «Тәлфикел-әхбар...» ныклы фәнни нигезгә, бай чыганакларга корылган. Автор эзлекле рәвештә халкыбызның дәүләтчелек һәм этник тарихын күрше мәмләкәтләр һәм кавемнәр яшәеше белән бәйләнештә яктырта. Китапта татарның күпгасырлык үткән юлы, андагы мөһим һәм гыйбрәтле вакыйга-хәлләр, халкыбызның табу-югалтулары, кайгы-шатлыклары күзаллана. Дәүләтчелеген югалткан, колониаль изелү гасырларында кавемебез күргән җәфалар шактый объектив, реаль чынбарлыкка туры килешле итеп сурәтләнгән. Хезмәтнең тел-стиле, төзелеш-композициясе шактый үтемле. Кыскасы, «Тәлфикел-әхбар...» милли тарихыбызны өйрәнүдә мөһим бер хезмәт булып тора. Кызганыч ки, ул әле соңгы чор тарих китапларында, фәнни хезмәтләрдә юньләп файдаланылмый. Аның татар һәм урыс телләрендәге фәнни басмаларын нәшер итү дә – күптән өлгергән мәсьәлә.

***

Морад Рәмзи 80 еллык гомеренең тәүге ике дистәгә якынын туган төбәгендә уздыра. Аннан берничә елы – Казанда һәм Троицкида, Ташкент һәм Бохарада. 19 нчы йөзнең соңгы чиреген, XX гасырның 14 елын Мәккә-Мәдинә якларында яши. Аннан – янә Рәсәйдә. Әмма Идел-йортта яшәвенең икенче дәвере озакка бармый. 1917 елгы инкыйлаблар, Бөтендөнья сугышының һаман дәвам итүе, илдәшләр, кавемнәр арасындагы каршылыкларның көчәюе болай да тынгысыз Рәсәй тормышын тагын да катлауландыра-кыенлаштыра. Бу хәлне аңлаган Морад Рәмзи, шактый өлкән яшьтә булуына да карамастан, Идел-йорттан элек яшәгән урынына – Гарәбстанга кабат әйләнеп кайтырга карар кыла. Башта Оренбургтан Казанга юнәлә, әмма, шәһәрне ак чехлар алу сәбәпле, кире борыла. Бәйрәкә авылында бераз вакыт мәдрәсәдә укытып та ала. Аннан Тоз-Түбәгә әйләнеп кайта. 1919 елның язында Уфа, Кызылъяр (Петропавловск), Семей (Семипалатинск) аша ул Шәркый Төркестанга юнәлә. Максаты – Кытай аша Мәккә-Мәдинәгә кайту. Озын, гаять мәшәкатьле юллар үтеп, нигездә, уйгырлар һәм кайбер башка төрки кавемнәр, шул исәптән татарлар да яшәгән Чүгүчак шәһәренә җитә. Каланың мөселман халкы бу олуг, абруйлы затны үзләрендә имам-мөдәррис итеп калырга күндерә, аңа йорт та салып бирәләр. Шулай итеп Морад Рәмзи Чүгүчакта төпләнеп кала.

Галимнең Кытайдагы тормышы, эшчәнлеге Мөнир Ерзинның «Бөек галим хакында сүз» мәкаләсендә (2005) [3: 143-147] һәм Н.Гәрәеваның югарыда телгә алын-

ган язмасында [1] шактый тулы яктыртыла. Шуңа күрә биредә тик берничә факт-мәгълүматны гына искәртеп китәбез.

Морад Рәмзи Кытайда яшәү чорында да иҗтимагый, дини, рухи тормышның үзәгендә кайный, үзенең саллы, абруйлы киңәшләре белән төрле каршылыкларны хәл итүдә дә катнаша. Мөселман кавемнәренең мәнфәгатьләрен яклап, ул хәтта рәсми хакимият белән дә каршылыкка керә. Халык аны дәррәү яклый. Аның вәгазь-чыгышларын ерак тарафлардан да килеп тыңлыйлар. Җирле мөселманнарның ихтыяҗ-теләкләрен исәпкә алып, Морад Рәмзи 1927-1931 нче еллар аралыгында Коръәнне татарчага тәрҗемә итә. Аның бу хезмәте белгечләр һәм халык тарафыннан уңай бәяләнә. (Бу Изге китапны хәзер Казанда бастыруга да хәзерлек бара. Шулай ук «Тәлфикел-әхбар...»ның да татарчага тәрҗемәсе нәшер итүгә әзерләнә.) Морад Рәмзи Чүгүчакта яшәү елларында Шәркый Төркестанның электән үк мөһим милли мәдәни үзәкләре булган Турфан, Өремче төбәкләрендә дә була, алардагы тарихи, язма ядкярләр белән таныша, гыйлем әһелләре белән очраша. Вафатына бер ел кала ул хәтта төркиләрнең асыл Ватаны – Алтайга да сәфәргә чыгып китә. Әмма «Доңгән сугышы» башланып китү сәбәпле, Чүгүчакка кире әйләнеп кайтырга мәҗбүр була.

Кытайда яшәү чорында аның күптөрле хезмәтләр язуы, бай тарихи, мәдәни материаллар туплавы мәгълүм. Әмма Мөнир ага Ерзин язуынча, аларның һәм шулай ук шәхси китапханәсенең күпчелеге Кытайда «культурная революция» елларында «утта яндырыла» [3: 146].

***

Чын татар төбәгендә – Сарман якларында туып-үскән, Идел-йортта белем алган милләттәшебез үзенең 80 еллык гомерендә дөньяның күп төбәкләрендә булган, яшәгән, армый-талмый хезмәт иткән, төрле кыенлыкларны кичергән, төрле тармакларда үзенең игелекле «эз»ен калдырган. Аның Чүгүчактагы кабере – күпләгән мөселманнарның үзенә күрә бер зиярәт кылу урыны да. Ул – күпкырлы шәхес: дин әһеле, тарихчы, журналист-публицист, остаз-мөгаллим, тәрҗемәче. Морад Рәмзи – халыклар, диннәр, илләр арасындагы бәйләныш-хезмәттәшлекне ныгытуга да зур өлеш керткән олуг зат. Аның тәрҗемәи хәлен, хезмәтләрен, күпкырлы эшгамәлләрен өйрәнү безнең күңел офыкларын киңәйтә, рух-зиһенебезне тагын да баета.

Әдәбият

1. Нурия Гәрәева. Кем ул Морад Рәмзи?// Казан утлары. – 1990. – №2. – 171-175 б.

2. Дамир Гарифуллин. Сарман районы энциклопедиясе. 2 нче китап. – Чаллы, 2008. – 510 б.

3. Мөнир Ерзин. Гасырлар сере. Тайны веков. – Алматы: Мир, 2012. – 315 б.

4. С.З.Ахмадуллин. Мурад Рамзи как историк тюркских народов России. – М.: Институт российской истории РАН., 2022. – 220 с.

5. Фоат Уразай. Морад Рәмзине зурлау//Мәдәни җомга. – 13.05.2022.

6. [Рәмзи М.] «Тәлфикел-әхбар вә тәлкихес-асарь фи вакаиги Казан вә Болгар вә мөлүкет-татар» . Ике томда. – Оренбург, 1908. – I том. – 736 б.; II том. – 540 б. Гарәп телендә. ■

Буа ягы – дини төбәк

Рифат Каюмов

Хәтерне юып ташлау мөмкин эш түгел. Гасырлар аша халык күңелендә Әюп мулла, Сәгъди мулла, Таҗи мәзин, Низаметдин хәзрәтнең, Имай һәм Әпәт хаҗиларның исемнәре дә, халык күңеленә сеңеп калган гамәлләре дә онытылмый. Бигрәк тә Әхмәр хәзрәт исеме. Ул бу олуг шәхес туып-үскән Адав-Толымбай авылы кешеләренең генә түгел, ә элеккеге Буа өязендә яшәүче берничә буын халык хәтеренә уелып калган.

Ике гасырлап вакыт узса да, зинданнарга олактырсалар да, башлары Себер китсә дә, авыл халкына шәригать кануннары буенча яшәргә өйрәткән, аң-белем, мәгърифәт нуры тараткан дин әһелләребезнең исемнәрен халык онытмый, аларны әледән-әле искә ала.

«Әхмәр хәзрәт, Имай хаҗи, Әпәт хаҗилар рухына Буа мәчетләрендә сугышчан алласызлар чорында да дога кылалар иде», – дип сөйләп калдырды Адав-Толымбайның күренекле педагогы Җәүдәт ага Рәхмәтуллин.

Әхмәр бине Юныс әл-Толымбаи (1763-1819).
Вәкил Шәйхетдинов рәсеме

Кем ул Әхмәр хәзрәт? Ни сәбәпле, вафатына ике гасыр узса да, дин әһеленең исеме авылдашларыбыз күңеленнән китми? Гомумән, Буа районының Адав-Толымбай авылында гасырлар дәвамында ислам дине торышы нинди булган? Әхмәр бине Юныс әл-Толымбаи хакындагы бу хезмәтнең (Рифат Каюмов. «Әхмәр бине Юныс әл-Толымбаи». Документаль басма. – Казан: «Бриг» нәшрияты, 2020 ел. – 80 б.) максаты – нәкъ шушы сорауга җавап табарга тырышу иде.

Толымбай авылында дин торышы мәсьәләләренә караган чыганаклар, кызганыч ки, юк дәрәҗәсендә. Чөнки китаплар, кульязмалар яндырылган, югалган, дин әһелләренең оныклары «чәчелгән-сибелгән»...

Әмма хәтер бар. Юк, дисәк тә, кайбер язма чыганаклар, шөкер, сакланып калган булып чыкты. Бу хезмәтне язу эшендә күренекле авылдашыбыз – педагог, мәгърифәтче Йосыф ага Рыбаковның (1905-1995) «Толымбай тарихы буенча кайбер материаллар» дигән кульязмасы ярдәм итте. Кульязма 1974 елда, атеистик чорда язылган, шуңа күрә авторның дин мәсьәләләренә карашы да нәкъ шул замандагыча. Әмма бу кыйммәтле чыганак Толымбай авылының үткәненә кагылышлы, шул исәптән дин әһелләре турында да мәгълүматларның күплеге белән аерыла.

Филология фәннәре кандидаты Шәрәфулла Әхмәдуллин мәкаләләре дә, шулай ук «Буинск: страницы истории» китабында Әхмәр хәзрәт, Әюп һәм Сәгъди муллалар хакында, мәдрәсәләрдә укыту турындагы язмалары да игътибарга лаек.

Авылдашларыбыз – филология фәннәре кандидаты Энҗе Җаббарова һәм ветеран журналист Мөнир Борһановларның «Толымбай – Сөештә дин юлы» китабы безнең те-

мага кагылышлы мәсьәләләрне яктыртуда кыйммәтле чыганак булып тора. Бу хезмәт XIX гасыр ахыры-XX гасыр башында авылда яшәүче чуашларның ислам диненә күчү процессларын яктыртуы белән аерыла.

Тарихчы галим, дин белгече Рәшит Маликовның өяз мәчет-мәдрәсәләренә багышланган «Буа шәһәренең мөселман гыйбадәтханәләре тарихы» исемле уникаль хезмәте үзенең архив документларына таянып язылуы белән кыйммәтле. Китапта XX гасыр башында булган дин торышы турында тулы мәгълүмат бирелгән. Шулай ук авторның башка әсәрләре дә бу хезмәттә чагылыш тапты, киңәшләре искә алынды.

Адав-Толымбай авылында дин торышы мәсьәләләрен, дин әһелләренең туу-үлү елларын, аларның эшчәнлегенә кагылышлы «ак тап»ларны ачыклау юнәлешендә Казан, Ульяновск, Мәскәү архивлары мәгълүматлары ярдәмгә килде. Әлбәттә, шул чордагы дини вазгыятьне ачыклауда кайбер башка авторлар хезмәтләренә дә, авыл халкына да мөрәҗәгать иттек.

Толымбай һәм Сөеш авыллары элек мөстәкыйль саналса да, янәшә урнашу һәм 1920 нче елларда кушылуы сәбәпле, бу хезмәттә ике авыл бербөтен итеп карала.

Әлеге китапта беренче мәртәбә Әхмәр хәзрәтнең портреты да бирелә. Ул – гади портрет кына түгел, Башкортстан Республикасының атказанган рәссамы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Вәкил Шәйхетдиновның (Уфа) безнең тарафтан җыелган архив документларына таянып һәм дин әһеле туганнарының фоторәсемнәренә охшатырга торышып эшләнгән тарихи реконструкция дип аталырлык иҗади эше. (Портрет китапның тышлыгында бирелә.)

XVIII-XIX гасырларда Иделнең Тау ягында Әхмәр хәзрәт (1763-1819) масштабындагы дин әһелләренең бармак белән генә санарлык булуын истә тотып һәм аннары Буа өязе тарихында мәңгеләштереп калдыру йөзеннән, без күренекле авылдашыбызны шул чорга хас исем астында бирергә булдык – Әхмәр бине Юныс әл-Толымбаи.

Әхмәр хәзрәтнең вафатына төгәл ике йөз ел үтсә дә, атеистлар чорында мулла-ишаннар исемнәрен төрлечә пычратырга омтылсалар да, алар халык хәтерендә сакланып калганнар. 2018 елда Әхмәр хәзрәт нәселеннән чыккан медицина фәннәре кандидаты Гүзәлия Равис кызы Халикова-Закированың үз баласына Әхмәр исеме кушуы нәкъ шул турыда сөйли: хәтерне юк итеп булмый.

Әхмәр хәзрәтнең, шулай ук авылыбызның башка дин әһелләренең язмышын ачыклауда бу хезмәт – зур эшнең башы гына. Безгә эзләнүләрне дәвам иттерергә кирәк булачак.

XVI-XVIII гасырларда Тау ягы

Татарстанның Буа районына караган, XVII гасырның беренче яртысында нигез салынган Адав-Толымбай авылы тарихын өйрәнү Алтын Урда таркалгач оешкан Казан ханлыгы (1438-1552), Нугай Урдасы (1419-1650 нче еллар) тарихларыннан аерып карау мөмкин түгел икәнен күрсәтә.

Тау ягында «нугай эзләре» бихисап. Хәтта Адав-Толымбай, Кыят җирләрендәге аерым урыннар – «Олы чирәм», «Крымов җирләре», «Валлар буе», «Кыят» атамалары урта гасыр тарихын чагылдыралар.

Казан ханлыгы егылганчы ук – 1551 елда Иделнең Тау ягы Мәскәү хөкүмәте кул астына керә.

Чыгышы белән Буа өязенең Яңа Тинчәле авылыннан булган дин әһеле, тарихчы, язучы Касыйм Бикколов (1868-1937) «Яңа Тинчәле авылы тарихы» дигән кульязмасында болай дип яза: *«Казан ханлыгын юк иткәннән сон, рус хөкүмәте мәчетләрне, мәктәпләрне тар-мар итте, мулла һәм мөгаллимнәрне үтерделәр, күбесен көчләп чукындырдылар, төрле*

ысуллар белән дөньядан юк итәргә тырыштылар. Рус хөкүмәте тарафыннан аларга укыту һәм мәгърифәт таралу мөмкинлеге бирелмәде. Ислам тәгълиматларын качып, урманнарда өйрәнделәр».

Дини изү белән бергә, социаль яктан һөҗүм итүләр дә алып барыла. Рус өлкәләреннән миграция башланып, элеккеге татар җирләре басып алына. Асылда терлекчелек белән шөгыльләнгән ярым күчмә татар-төрки кавемнәре, җирләре басып алучылар тарафыннан чикләнү сәбәпле, утрак тормышка күчәргә мәҗбүр булалар. Гасырлар буена шәкелләнгән тормыш рәвеше бозыла. Татарлар яңа хуҗаларына – рус алпавытларына, поп һәм монастырьларга ясак түләргә мәҗбүр ителәләр.

Нәтиҗәдә, татар, чуаш, чирмеш һәм мордва кавемнәре, Казан ханлыгының басып алынуы белән килешмичә, дини, социаль изүгә каршы күпсанлы баш күтәрүләрдә катнашалар.

Казан ханлыгы яулап алынгач та, 1560 нчы елларга кадәр баш күтәрүләр була. 1580 нче елларда чирмешләр сәнәккә ябыша. XVII гасыр «смутасы» вакыйгаларында Ялган Дмитрий ягында Идел буе халкы катнаша.

1613 елда Романовлар династиясе тәхеткә утыргач, гади халыкның тормышы тагын да мөшкелләнә: ясак күләме дә, рус миграциясе дә арта. 1615 елда Тау ягында «Җан Гали явы»нда, 1670 нче еллардагы Степан Разин восстаниесендә Идел буе халыклары күпләп катнаша. Әмма бу күтәрелешләр дә бастырыла. Сүз уңаеннан, восстание канга батырылгач, «разинчы чуашлар» күпләп Толымбайның күршесе Сөеш дигән татар авылына килеп сыеналар.

Петр I реформалары гади халыкка иң зур михнәт китергән чор була. Рус мигрантлары һәм чукынган, шул рәвешле хәлләләр рәтенә кергән татарлар, төрле сәбәпләр белән, гади халык җирләренә кул сузалар. Адав-Толымбай һәм Сөеш авыллары крестьяннарының хөкүмәткә бу турыда язылган күпләгән шикаятьләре билгеле. Рус Кырлангысы, Никольские Выселки (Затон), Ивашевка, Бәйбулат (Карлы) авыллары алпавытлары яисә йомышлы татарлары безнең авыл җирләренә керәләр, иген чәчәләр, печәнен чабып алалар.

Петр I заманында йомышлы татарлардан торган ярым профессиональ гаскәрләр урынына рекрутлар алу системасы кертелә. Йомышлы татарлар, би, морзалар бөлгенлеккә төшәләр. Аларны «чабаталы морзалар» дип атый башлыйлар. Рекрут язмышы – ачы язмыш. Солдатка алынган егетләр йә сугыш кырында ятып калалар, йә, картаеп, инвалид хәлендә туган авылларына кайтып егылалар. Хәтта 10-12 яшьлек балаларны да денщиклыкка, матрос ясарга ала торган булалар. Күбесен армиядә чукынырга мәҗбүр итәләр.

Иң авыры – имана җиреннән салым түләү урынына кеше башыннан түләтү системасын кертү була. Бу яңалык салым күләменең биш мәртәбә артуына китерә. Шулай итеп, арыш оның поты 15 тиен булганда, гади халык елына бер сум җитмеш тиен салым түләргә тиеш булып чыга.

1719-1723 нче елларда беренче мәртәбә халык санын алганда, чукындырудан өркеп һәм, беренче чиратта, салым түләмәс өчен, ир-атлар урманга качалар. Толымбайда да андый хәл була. 109 ир-атның 25есе качып-посып ята, аларны мәҗбүриләп авылга кайтаралар.

1738-1755 нче елларда Казан һәм Зөя архиепископы Лука Канашевич (Аксак Каратун) Казан губернасындагы – 418, Сембер төбәгендәге – 98, Әстерхан якларындагы 29 мәчетне җир белән тигезли. Бу вакытларда Толымбай авылында да мәчет булгандыр, ул да юк ителгән дип уйлыйбыз. Чөнки мөселманнардан торган авыл шактый зур була: 135 ир-ат һәм шул кадәр үк хатын-кыз исәпләнә.

Россия хөкүмәтенең Казан ханлыгы алынганнан бирле көчләп чукындыру сәясәтен Адав-Толымбай, Сөеш авылларының төрле чор тарихында күрергә була. Россия дәүләт

борынгы актлар архивы мәгълүматларыннан күренгәнчә, 1745-1763 нче еллар арасында мәҗүси чуашлар һәм татарларның бер төркеме чукынырга мәҗбүр ителәләр. Татар хатыннарын да православиягә мәҗбүрилиләр. Мәсәлән, Ибрай Морзакай – Абрам Ивановка, Савка Тойдерячкин Савелий Ефимовка әйләнә. Татар Мәкъсүт Бикколкин Максим Максимов булып куя һәм Оренбург якларына җибәрелә. Толымбайга килен булып төшкән татар кызлары Марина Абрамовага (Карлы), Катерина Абрамовага (Кошки – Шемякин), Аксинья Семеновага (Боерган), Анна Гавриловага (Түбән Наратбаш), Федосья Алексеевага (Бикмораз) әйләнәләр. Шулай итеп, мәҗүси чуашлар һәм мөселман татарлар яшәгән Толымбайда 1763 елда барлыгы 179 кешенең 62се (31 ир-ат, 31 хатын-кыз) «яңа керәшеннәр» булып теркәлгәннәр. Дөрес, тагын унтугыз елдан 1782 елгы документта бу кешеләр яисә аларның балалары мөселман исемнәре белән теркәлгәннәр.

Көчләп чукындыру, салым түләү, лашманчылык, мәчет-мәдрәсәләрне юк итү – болар барысы да крестьяннарның түземлеге бетүенә китерә. Урал якларында 1755-1756 нчы елларда мулла Батырша восстаниесе күтәрелә, 1773 елда Россиядә моңа кадәр күрелмәгән Пугачев явы башлана.

Шулай итеп, Казан ханлыгы Мәскәү хөкүмәте тарафыннан яулап алынгач, Идел буенда яшәүче татар, чуаш, чирмеш, мордва халыклары дини, милли, социаль изү астында калалар. Мәчет-мәдрәсәләрне туздыралар. Күпсанлы милли азатлык хәрәкәтләре канга батырылалар.

Әхмәр хәзрәт Юныс әл-Толымбаи эшчәнлеге

XVII-XVIII гасырлардагы милли азатлык хәрәкәте, баш күтәрүләр, восстаниеләр, патшага шикаять-петицияләр язу эзсез узмый. Патша хөкүмәте милли, дини, социаль изү эшен «йомшарта» башлый. «Чыбыркы һәм перәннек» ысулын кулланып, Петр Iнең кызы патшабикә Елизавета Петровна (1709-1761/1762) бер кулы белән 1756 елда мөселманнарга мәчетләр төзергә рөхсәт бирсә, икенче кулы белән көчләп чукындыруны дәвам иттерә. Шулай да монархия элекке сәясәт алып бара алмый, дөресрәге, ул сәясәт Россиянең Урта Азия, Төркия, Иран илләренә экспедициясе планнарына каршы килә. Татар-мөселманнар Урта Азияне яулап алу эшендә кирәк булу ихтималын да истә тотып, патша хөкүмәте дини, социаль-икътисади изүне киметә.

1773 елда, Екатерина II указы нигезендә, ислам диненә ирек бирелә, мәчет-мәдрәсәләр төзергә рөхсәт ителә, 1788 елда Оренбург Мөселманнар диния нәзарәте төзелә.

Акрынлап, төрле киртәләрне узып, Идел-Урал буйларында яңабаштан мәчет-мәдрәсәләр салына башлый. Шул вакытта дини кадрлар – укымышлы муллалар, мәдрәсәләрдә мөгаллимнәр кытлыгы сизелә.

Адав-Толымбай авылында туып-үскән Әхмәр Юныс улының яшәгән еллары нәкъ шушы тарихи чорга туры килә. «Әхмәр бабай акыллы, тәртипле, киң холыклы, ярдәмчел кеше булган булса кирәк, чөнки картлар әле бүгенге көндә дә аны «Әхмәр хәзрәт» дип хөрмәт белән искә алалар, – дип яза Шәрәф ага Әхмәдуллин.

Ул Әхмәр хәзрәтнең эшчәнлеге архив документлары аша 1725-1768 нче елларга туры килә, дип язса да, күренекле дин әһеленең 1763-1819 нчы елларда яшәгәнлеген ачыкладык. Хатыны – Гамбәр, 1771 елгы, Толымбай авылы кешесе була.

Үзеннән-үзе Әхмәр хәзрәткә кагылышлы бер сорау туа: ике гасыр узса да, аның исеме авыл халкы хәтерендә ни сәбәпле яхшы саклана? Хөрмәт йөзеннән, авылның Иске зиратында, бер генә истәлек ташы калмаган килеш (ул зиратка мәетләрне күптән җирләмиләр), язулы таш һәм чардуган куйганнар! Ничәмә-ничә буын алышынса да,

Буа мәчетләрендә аның рухына, нәселендәге Имай хаҗи – Гыймадетдин Сәйфетдинов (1849-1917?) рухына әле дә булса дога кылалар? Каян килә бу хөрмәт?

Әлеге сорауга җавап эзләп карыйк.

Адав-Толымбай авылының гомер-гомергә Сембер ягында үзенә күрә бер татар мәркәзе булган Зөябаш (хәзерге Ульяновск өлкәсендәге Иске Тимошкино авылы) саласының байлары, мәгърифәтчеләре белән элемтәләре була. Бу авылда элек-электән мануфактура эшләп килгән, хуҗалары – атаклы Акчуриннар нәселе.

Акчуриннар нәселе хәйриячелек белән шөгыльләнә, Сембер губернасында мәчет-мәдрәсәләр төзетә, сәләтле яшьләрне укытып кайтара. Әхмәр шәкерт тә, Акчуриннар ярдәме белән, Бохарада мәдрәсә тәмамлый, камиллеккә ирешә. Ул заманына күрә төпле дини белем ала, тормыш итәр өчен авыл халкын үз артыннын ияртеп барырдай әйдаман, төпле шәхес була. Әхмәрнең атасы Юныс Рыс (Рысмөхәммәт) улы 1715 елгы, йомышлы татар, хәлле кеше санала. Аның ике хатыны, 6 улы, 4 кызы булуы, кызларының да тирә-юнь авыллары йомышлы татарларына кияүгә чыгулары, Буа, Тәтеш һәм Сембер өязләре сәүдәгәрләре, муллалары белән элемтәдә торуы – болар барысы да Юнысның сүзе үтә торган, бай кеше икәнлеге хакында сөйли. Юныс һәм аның 1723 елгы бертуган энесе Йосыф авылда мулла вазыйфаларын үтиләр.

Бер истәлекне искәртеп үтик. ...1782 ел. Яз ае. Толымбай атавына, әйтерсең лә, Сембер җир кендеге, халык агыла да агыла. Күл буе тирә-юнь салаларның абыз-муллалары, түшләренә калай аскан (старосталык билгесе) старосталар, крестьян агай-энеләр белән тулган. Барысы да, борын төрткән чирәмдә намаз укып, Рысмөхәммәт баба нигезеннән Юныс ата, аның сайланган Әхмәр углы чыкканын көтәләр. Ниһаять, Юныс карт, аның белән Әхмәр шәкерт күренде.

Күл буен тутырган халык, аяк өсте басып, мөхтәрәм Юныс абыз-картны төрле авазлар салып сәламләде. Хасил булган мәйдан уртасына чыгып, Юныс Рысмөхәммәт углы, тирә-юньне олуг вәкарь белән кичереп, сүзен әйтте:

– Мөэмин-мөселманнар! Ходай Тәгалә шаһит: ата-бабаларыбыз әмереннән тайпылмадык, хак динебез кушканча гомер итәбез. Әлһәмдүлилләһ, киләчәктә дә шулай булыр.

Күл буе бертавыштан: «Амин!» – диган кайтаваз белән тулды.

– Бердәнбер Рәсүлуллабыз өмете илә, әлһәмдүлилләһ, Сембер диндарлары – мөхтәрәм Акчура меллалар ярдәменә таянып, өметебез булган Әхмәр углыбызны бөек Шәрифел Ислам-Бохарага әмер итәбез. Шуңа җыелдык, Гыйлем нурына озатабыз. Кил әле, улым, менә сиңа әманәт – гыйззәтле бабаң Рысмөхәммәт төсе.

Юныс карт, башындагы чалмасын салып, улының башына чорнады. Шуннан соң болай дип өстәде:

– Нугай, татар-төрки илен гизгән, хак динебезгә тап төшермәгән Ишмөхәммәт ыруыннан Рысмөхәммәт бабаң чалмасын ура. Бабаң чалмасы башың белән бергә кайтсын, Ярабби! Бер Ходаем, әгәр ерак сәфәрләрдә җан тәслим кылырга язса, бабаң чалмасы сиңа ак кәфенлек булсын, – дип, 67 яшьлек Юныс абыз, күз яшьләренә буылып, читкә борылды.

Толымбай атавы, яше-карты иңрәп алды:

– Амин! Бер Ходаем! Ярабби! Исән-аман әйләнеп кайтырга язсын!

Әхмәр шәкерт, бабасы чалмасын урап, атасы Юныс һәм анасы Уразия фатихасын алып, төп нигезеннән кузгалып, олы юлга – Бохараи-Шәрифкә юл тотты.

Бу Әхмәр шәкертнең газиз атасын соңгы мәртәбә күрүе иде...

Әхмәр 19 яшендә, документларда күренгәнчә, «холост», диелгән, – димәк, әле өйләнмәгән була. Аннан соң документларда «югалып» тора. Ниһаять, 1794 елда – Әюп, 1800 елда – Мөхәммәт, 1809 елда Әхмәт исемле балалары туа. Моннан Әхмәр Юныс

улының 1782-1792 нче елларда Бохара мәдрәсәләрендә гыйлем алуын чамалыйбыз.

Бохара мәдрәсәләре, турында андагы уку-укыту системасын, яшәү рәвешен үзләре дә шунда яшәгән, белем алган Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889) һәм Габдерәшит Ибраһимов (1857-1944) язмаларын укып белергә була.

Бохарага кәрван юлы, мең еллар элек салынганча, Казан-Каргалы бистәсе-Оренбург-Орск аша узган.

Мәрҗани, мәсәлән, 20 яшендә Бохарага жиде ай буена бара, Бохара һәм Сәмәркандта 10 ел укып, Казанга әйләнеп кайта. Безнең Әхмәр дә аннан шул ук елларда үтә. Кайбер мосафирлар кебек, Әхмәрнең дә Оренбург янәшәсендә урнашкан Каргалы бистәсендә берничә ел туктап, шундагы мәшһүр мәдрәсәләрдә аң-белем туплаган булуы бик мөмкин. Чөнки Буа, Сембер якларыннан килгән шәкертләр, дини белемнәре сай булганлыктан, Бохарага барганчы, Каргалы мәдрәсәсендә белемен ныгытканнар. Һәрхәлдә, безнең якның Шәйморза, Норлат, Кайбыч һәм башка авылларыннан монда килеп укучылар була. Җиде мәдрәсәнең икесен Кайбыч һәм Шәйморзадан булган дин әһелләре тоткан. Моннан тыш, Толымбай авылы сәүдәгәре Әбдерәшит Давыдов (1719) бу бистәгә күченеп киткән була. Әхмәр шәкерткә аларның ярдәме тигән булса кирәк. Шушы сәбәпләргә таянып, Әхмәр Каргалы бистәсендә берничә ел тукталып, белем алган дип фараз кылабыз.

1750 нче елларда ук Каргалының икенче мәхәллә мәдрәсәсенә җитәкче булып Буа тарафыннан Вәлид бине Мөхәммәт әл-Әмин килә. Урта гасыр шагыйре дә булган Вәлид мулла янына сабак алырга Идел-Урал төбәкләреннән, шул исәптән Буа, Тәтеш һәм Сембер якларыннан да шәкертләр җыела. Вәлид мулланың шәкертләре арасыннан мәшһүр шагыйрь Габдерәхим Утыз Имәни (1754-1834), юлбашчы Салават Юлаев (1752-1800) булуы, Кайбыч авылы мулласының Каргалы бистәсендә генә түгел, Урта Идел-Урал мөселман дөньясында шөһрәтле даны турында сөйли.

Әхмәр Юныс улының күренекле дин әһеле, шагыйрь, хикмәтле сүз остасы Вәлид бине Мөхәммәт әл-Әминнән сабак алуы, шул вакытта беренче мәдрәсә башлыгы Ишнияз бине Ширнияз сабакларын тыңлавы, аннан соң Бохарага барып белем эстәве – болар барысы да Әхмәр Юныс улының зур гыйлем иясе булып формалашуына зур этәргеч булалар.

Әхмәр укыган елларда Бохара әмирлеге мөстәкыйль дәүләт була. Бохараның үзендә йөзләгән мәдрәсә һәм ике дистә мең тирәсе шәкерт булуы билгеле. Ул гыйлем үзәге булган, «шәриф», ягъни «изге» дигән данлыклы исем йөрткән – Бохараи Шәриф, Ислам солтанаты. Бохарада белем алганнар хакында Ш.Мәрҗани болай дип яза: *«Бохарада укып кайттым» дигән мелланы кешедән өстен зат дип хисаплаганнар, хәтта фәрештәдәй күргәннәр. Икенче бер җирдә «Бохарадан укып кайткан кеше бик аз булган, ә булганнары киемнәре, сүзләре һәм хәрәкәтләре белән үк аерылып торган, сөйләмнәре ярым-йорты һәм бозык булса да, фарсы һәм гарәп сүзләре катыштырып, халыкның исен китәргәннәр. Шуның өстенә, дәрәҗәләре, абруйлары һәм сүзләре үтүе үзләреннән күп югары булганлыктан, белмәгәне – белмичә, белгәне – белеп, куркудан аларны таныганнар һәм ышанып, буйсынып яшәгәннәр».*

Шиһабетдин Мәрҗани үзенең китабында берничә дистә мулланың Бохарада укып кайтуы, шуларның бөтенесе дә диярлек ишан дәрәҗәсен алуы турында яза. Әхмәр хәзрәт тә искәрмә булмый, ул да үзенең остазыннан изаҗәт, ягъни башкаларны да суфилыкка өйрәтеп, ишан дәрәҗәсе бирү хокукына ия булып кайта. Әхмәр хәзрәтнең ишан булуы хакында Йосыф Рыбаков болай дип яза: *«Әхмәр хәзрәт – суфи мулла. Ул Зөябаш шәһәр купецлары тарафыннан Бохарада муллалыкка, суфи ишанлыкка укытылган, имеш».* Идел-Урал буе татар авылларыннан килгән шәкертләр бөтенесе диярлек «Ишан хәлиф Ниязколый» мәдрәсәсендә дәрәҗәле галим, дин эшлеклесе, ишан Ниязколый ибн Шаһнияз ибн Балта әт Төрекмәни кул астында гыйлем алалар. Ишан дин өлкәсендә зур дәрәҗәле,

дин тәгълиматы белгече, дин әһелләре башлыгы, ягъни остазларның остазы була. Әхмәр хәзрәтнең эшчәнлеге Толымбай авылы белән генә чикләнми, Буа өязенең бик күп авылларының булачак муллалары Әхмәр хәзрәттән белем-сабак ала.

Шулай итеп, Әхмәр Юныс улы Бохарада олы гыйлем туплап, гарәп һәм фарсы телләрен өйрәнеп, ишан дәрәҗәсендә, үзе белән бик күп китаплар алып, туган авылы Адав-Толымбайга кайтып төшә. Уфадагы Диния нәзарәтендә имтихан тапшырып, указ ала. Әхмәр Юныс улы, 1819 елда вафат булганчы, армый-талмый аң-белем тарата.

Бу уңайдан галим Рафаэль Шәйхиевнең дин әһелләренең XVIII-XIX гасырларда тоткан урыны турындагы фикерен җиткерәм. *«...в его среде (духовенства Р.Каюмов) были служители низшего порядка, как муэдзины (азанчи) и муллы малых приходов, которые в экономическом отношении не отличались от большинства крестьян, и таким образом, стояли близко к народным массам. Имамы и ахунды составляли среднее звено и, наконец, муфтий, казый и ишаны, относились к высшему звену. Именно последние являлись основными крепостниками общества».*

Әхмәр ишан, Тау ягындагы санаулы ишаннар белән бергә, дини тормышның, димәк, төрки-татар яшәешнең рухи тоткасы, рухи остазы була. Ул, ишаннарга хас булганча, Буа өязе чикләрен узып, тулаем Тау ягындагы авылларга чыгып, халык, дин әһелләре белән очрашуларда катнаша. Халыкка вәгазьләр сөйли, төрле бәхәсле мәсьәләләргә нокта куя, чирлеләрне дәвалый, үзенә мөридләр туплый.

Тарихчы галим һәм дин белгече Рәшит Маликов Буа ишаннарының исемнәрен атап китә. Менә алар: Габделвахид Габдерахман, Габденнасыйр Мөхәммәтәмин, Нургали Хәсән, Габдулла Гобәйдуллин, Норлаттан Фәхретдин Мостаев, Үгез Куагыннан Мөхәммәд Габделкасыйм, Суыксудан Шәрәфетдин әл-Суксуви, Карлыдан Гобәйдулла Рәхмәтуллин, Толымбайдан Әхмәр Юнысов һ.б.

Әдәбият белгече, филология фәннәре докторы Мәсгут Гайнетдинов суфыйчылык турында менә ниләр яза: *«Дәүләтчелеген югалткан халкыбыз тормышында, үткәндә, оешма, тотрыклы бер юнәлеш булуы белән, суфыйчылык хәрәкәте аеруча тирән тамырланган, киң җәелгән. Халык буларак яшәештә ил тормышында актив роль уйнаган. Башлыча территориаль принципта оя-оя булып оешкан суфи оешмалары җитәкчеләрен бездә ... «ишан» дип атаганнар. Алар тирәсендәге берләшмәдә әгъза булган кешеләр «мөридләр» дип йөртелгән, һәр күренекле мәдрәсә башлыгы (мөдәррисе) һәм иң күренекле авыл муллалары «тарикатькә» кергән – ишан булган. Алар шәкертләре арасында гына түгел, авылларга чыгып, «мажик»лар арасыннан да үзләренә мөридләр ишәйткәннәр».*

Кызганыч ки, революциягә кадәр дә, аннан соңгы атеистик чорда да ишаннар һәм суфыйчылык хәрәкәте тарихын өйрәнү түгел, тыеп, эзәрлекләп килделәр. Шуңа күрә Әхмәр хәзрәт эшчәнлегенә кагылышлы, Буа өязендә булган башка ишаннар турындагы документлар, кульязмалар юк ителгән. Аларның исемнәре фәкать кәһәрләнеп килде, туганнары исә сәяси репрессия корбаннарының иң тәүгеләре рәтендә булдылар.

Җыеп әйткәндә, Әхмәр хәзрәтнең дан-шөһрәте, ике гасыр узгач та исеме, халык теленнән төшмәвен, каберен торгызып, карап-чистартып торуны, аның рухына авылыбыз һәм Буа мәчетләрендә намаз вакытларында дога кылуны, ниһаять, күренекле дин әһелебез турындагы менә бу хезмәтне дә, гаҗәп хәл булудан бигрәк, аны чиксез хөрмәт итү билгесе дип карарга кирәк. ■

Тәрбия вә тәгълим

Фәйз Фәхри*

Гаилә вә мәктәбнең бер-берсенә ярдәмләшүләре ляземдер. Ибтидаи мәктәбләрнең вазыйфалары яшь балаларга ялгыз гыйлем бирү, дин белдерү, дөньяга карашларын алыштыру гына түгел. Бәлки, әдәб исламиягә күндерү, гүзәл әхлакка гадәтләндерү вә, хәзерге ихласча әйткәндә, тәрбия кылу тәгълимдән алда тотарга тиешле булган мәктәбләрнең иң беренче вазыйфаларыдыр. Мәктәбтән әдәб алуб чыкмаган бала кемнән вә кайдан әдәб алур?

«Әд-Дин вә әл-Әдәб» журналының тышлыгы. 1908 ел

Кайсыбер хакимнәрнең әдәбне әдәбсезләрдән өйрәндем дигән сүзләре балалык заманына караб әйтелгән сүз түгел. Бәлки, гакылга утыруб, уңны-сулны аера башлагач кына булуы мөмкин булган эш. Бу да бик аз кешеләргә генә насыйб буладыр. Күбрәкемебездә әдәбсезләрдән әдәбсезлек өйрәнү һәр көн, һәр сәгать диярлек булыб торадыр.

Безнең ибтидаи мәктәпләремез, бигрәк дә әүвәлдәгеләре, бу әһәмиятле вазыйфаны үти алмыйлар. Чөнки буның өчен мөгаллимләре үзләре әдәбле, тормыш йөреш вә башкача әгмальләре белән үрнәк булуб, балаларга күркәм тәэсир идерлек икътидәрле *(сәләтле)* булулары ляземдер. Авыл йирендә бундай мөгаллим кайдан табасың?

Бәхеткә каршы, бу рәвешдә яхшы мөгаллим тугры килә калса да, балалар мөгаллим янында үктәбердән майга кадәр йиде ай, бер айны җомга вә башка биремләргә чигергәч, бары алты ай, көненә 5-6 сәгать генә варалыр. Башка вакытларда уйларын ата-аналар янында, урамда, ибдәшләре арасында уздыралар. Өйгә кайткач, мәктәбтән алган өстенә, берәр нәрсә кушуламы? Иәкә мәктәбтән алынган әдәб бөтен килеш сакланамы? Йәисә, өйгә кайтуб керү белән, балалар күңелендән бөтенләй җуеб-кырыб ташланамы? Әүвәл мөгаллимләренең һәркайсы: «Балаларның мәктәбдән алган әдәбләре өйләренә кайту илә югала», – диләр. Тормышына карагандa, бу сүзгә ышанмаенча да булмый. Чункә *(чөнки)* мөгаллимләр мәктәбдә кирәк – сүз белән булсун, кирәк – үрнәк булуб булсун, оршышмаска, начар сүзләр әйтмәскә, үзара тату торырга, олугларга, рәгаиә көчекләргә шәфкатьле булырга балаларга өйрәтәләр, күңеленә салалар. Шуның өчен дә балалар мөгаллим алдында оршышмый-талаш-

---

*Фәйзрахман Фәхретдин (1877-1951), Буа өязенең Сарсаз авылында туа. Тархан ягындагы күренекле Чирүче нәселеннән. Адав-Толымбай (Сөеш) авылы имамы.

мый, бик тату торалар, аның алдында аныңча булырга тырышалар.

Ләкин өйгә кайтуб керү белән мәктәбтән алган әдәбләренә бөтенләй хилаф нәрсәләр күрәләр. Ата булган йорт башлыгы һәркемне орыша, әдәбсез сүзләр белән аналарын вә башка өй җәмәгатьләрен шелтәли, тугры килгәндә сугуб да йибәрә. Башкалары да аңа буйсыныб тормыйлар, каршы әйтәләр, кычкырыш-талаш кузгала, зуррак кардәшләре үзара да кычкырышалар, талашалар, сугышалар. Зуррак гаилә – кечкенәгә шәфкать юк. Мәктәбдән кайткан бала, буларны күреб, китабдан алган әдәбен бөтенләй оныта, оршыш-талаш, кычкырыш мәктәбдә генә ярамый, башка йирдә ярый торган нәрсә икән, диб, күңеленә утырта. Бөтен дөнья педагоглары балаларның тәртибе башында мәктәб илә гаиләнең бер-берсенә ярдәмләшүе лязим улганын сөйләгәннәр, һаман сөйлиләр. Бу ярдәмләшү ауыл йирләрендә бигрәк лязем. Чөнки хәзер дә аулларда көндән-көн әдәбсезлек, әхлаксызлык артыб тора. Ауыл халкы, балаларын нигәдер әдәбле-инсафлы итәселәре килсә дә, үзләренең тәҗрибәсезлегендән, балаларының табигатьләрен белә алмауларындан балага тәэсир итә алмый. Баланың табигате беленмәгәч, юлынча әдәб бер дә мөмкин булмый.

Гаилә белән мәктәбнең бер-беренә ярдәмләшүе ничек була? Мәктәбкә биргәндә мөгаллим – балага, бала – мөгаллимгә бөтенләй ят булалар, бер-берсенең табигать вә әхлакларын белешмиләр. Балалар, мөгаллимләрнең әхлакларын белмәсәләр дә, күп зарар юк. Әмма мөгаллимләргә балаларның табигатьләрен, әхлакларын белмәк гаять зарур вә әһәмиятледер. Шуның өчен дә, баланы мәктәбкә алганда, ата-анасындан: бала ауырганы юкмы? Хәзер дә ауыру түгелме? Шукмы? Җуашмы? Юк нәрсә өчен күңелсезләнмиме? Яки шадланмыймы? Җәзадән, мекафетдән әсерләнүе ничек? Йортда вакыты нинди мөгаләмәгә гадәтләнгән? Уйнаганда ибдәшләре белән нинди хәлдә булган? Буларның барын да яхшылаб сорашырга, ата-аналары да дөрест итеп җавап бирергә тиеш. Чөнки, бер хәлләр беленмәгәндә, баланы тиешенчә тәрбия кылыб булмыйдыр.

Уку вакытында мөгаллимдән баланың укуы, әдәбе ничек барганын җыш-җыш сорашырга, тәртиб эшендә мөгаллимнең күб карашын кабул итүб, мөмкин кадәр аңа ярдәмгә булырга тиеш.

Бала үзен-үзе белә башлагач, бигрәк тә мәктәбкә барган вакытында, аның алдында начар сүләүдән, оршышу-кычкырышудан вә башкача әдәбкә хилаф, ярамый торган эшләрдән, мөгаллимне балалар алдында яманлаудан мөмкин кадәр сакланырга ляземдер. Чөнки баланың яхшы иманны кабул итәрдәй саф күңелендә бундый эшләр начар эз калдыралар. Һәм мөгаллимләр үзләренә тапшырылган балаларны яхшы тәрбия кыла алмаудан мәгъзүр булалар.

Ата-ана һәрвакыт балалардың шикләрен, укутуб, аңламаганнарын тикшереб, аңламаган урынларын йомшаклык илә аңлатуб торулары файдалыдыр. Балага да аңламаган урынын шул көйчә калдырырга ярамаганын, бәлки, мөгаллимдән кайтадан сораб, аңларга кирәклеген төшендерергә тиеш.

Менә шулай итеп, гаилә белән мәктәб бер-берсе илә берләшеб, ярдәмләшеб торсалар, балаларны яхшы тәрбияләб булур иде. Бу гаять мөһим эшне имамлардың ауыл халкына җомгаларда, башка вакыт вә көннәрендә иң ачык итеб аңлата торулары ляземдер. Бу, әлбәттә, имамлар вазыйфасыдыр. Фигыль берлә әдәб бирү сүз илә әдәб бирүдән, әлбәттә, әҗерледер.

«Дин вә әдәб» журналы. – 1913 ел, 6 октябрь.

Иске татар имлясыннан хәзерге имляга ***Рифат Каюмов*** *тарафыннан күчерелде.* ■

Дин галиме Нургали Хәсәнов

Рәшит Амишов

Күренекле дин эшлеклесе, галим, мәгърифәтче, мөгаллим Нургали Хәсәнов (1852-1919)

Татар халкы талантларга бай: танылган галимнәр, күренекле җитәкчеләр, дин әһелләре, җәмәгать эшлеклеләре, иганәче сәүдәгәрләр илебез, милләтебез үсешенә бәяләп бетергесез өлеш керткәннәр. Гыйлем таратуда, рухи тәрбия бирүдә һәм милли гореф-гадәтләребезне саклап калуда дин галимнәре, ишан һәм имамнарның хезмәтләре гомер-гомергә зур булган. Алар арасында танылган дин эшлеклесе, галим, мәгърифәтче Нургали Хәсән улы Хәсәнов (1852-1919) – Урта Идел буенда XIX гасырның икенче яртысы -XX гасыр башында яшәгән иң күренекле шәхесләрнең берсе. Аның киңкырлы тормышын, иҗади мирасын өйрәнү – милләтебез тарихы, илебездә ислам диненең үсеше хакына фидакяр хезмәт куйган күркәм олуг затларны ачыклау юлындагы мөһим адым.

Нургали Хәсәнов хакында үз хезмәтләрендә күренекле шәхесләрдән Ризаэддин Фәхреддин, Морад Рәмзи, Галимҗан Баруди, Миркасыйм Госманов, Рамил Хәйретдинов, Радик Салихов, Габделхак Саматов, Александр Кобзев, Ибраһим Мараш, Рифат Каюмов һ.б. өлешчә язганнар. Аның эшчәнлеге тирәнрәк рәвештә

Омар Хакан Озал (Төркия) тарафыннан өйрәнелеп, галимнең ике хезмәте төрек теленә тәрҗемә ителеп басылган. Нургали Хәсәновның тормыш юлы турындагы тулы мәгълүмат Ульяновск өлкәсе дәүләт архивында, Татарстан Республикасы Милли архивында, Россия Федерациясе Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе архивында, Башкортстан Республикасының Тарихи үзәк дәүләт архивында һәм Казан федераль университетының Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлегендә документлар, язмалар, газеталарда басылган мәкаләләр буларак сакланган. Ул үз тормышы хакында «58 ел гасырда җәүәлән» һәм «Әл-гауатыф әл-хамидия фиссаяхати нурия» («Якты сәяхәтнең игелекле хисләре») дигән автобиографик әсәрләрдә кыскача язып калдырган.

Нургали Хәсән улы Хәсәнов 1852 елның 8 ноябрендә Казан губернасының Тәтеш өязендәге Морзалар авылында (хәзерге Апас районында) затлы дин әһелләре гаиләсендә дөньяга килә. Ул борынгы татар морзалары нәселеннән була. Аның шәҗәрәсе болай күрсәтелгән: «Идегәй морза (Алтын Урда чоры) → Морадин → Оказ → Муса → Исмәгыйль → Ырыс → Иши → Гали → Ибраһим → Әсән → Мөслим → Дауд → Мөэмин → Исмәгыйль → Хәсән → Нургали».

Нургалиның әтисе Хәсән Исмәгыйль улы (1820-1882) күренекле дин әһеле, ишан булган һәм 40 ел дәвамында Морзалар авылында мулла булып хезмәт иткән. Әнисе дә Югары Балтай авылындагы затлы морзалар нәселеннән булган. Нургали дөньяга килгәнче үк, әти-әнисе ниндидер җитди сәбәпләр аркасында аерылышкан. Ул, әтисе йортында туып, әнисе һәм әбибабасында тәрбияләнгән. Алты яшендә аны, әнисенең Казандагы абыйсы чакыруы белән, Дүртенче җамигъ мәчетенең (хәзерге Зәңгәр мәчет) мәдрәсәсенә галим, шагыйрь Гаясетдин бине Хәбибуллага (1830-1870) укырга бирәләр. Күп тә үтми, Нургалинең әнисе, кияүгә чыгып, Казанга күчә. Ләкин аңа озак яшәргә насыйп булмый – вафат була. Нургали әнисе ягыннан әбибабасы тәрбиясендә кала. Алар аның әхлаклы, белемле булуына зур игътибар биргәннәр. Әмма, озак та үтми, бер-бер артлы дөньядан киткәннәр. Кечкенә Нургали бик кыен хәлдә кала. Мохтаҗлыкка, кыенлыкларга карамастан, ул мәдрәсәдәге укуын тагын да зуррак тырышлык белән дәвам итә. Уку китапларын һәм аларга аңлатмаларны өйрәнеп кенә калмыйча, аларны хәтта ятлап ук бара. Мәсәлән, шулар арасында ислам хокукы нигезләре буенча «Ән-Нукая мухтасар әл-Викая» («Әл-Викая китабының кы-

Нургали Хәсәновның кайбер китаплары

скача аңлатмасы») дигән зур күләмле китап та була. Нургали укыган мәдрәсәнең җитәкчесе, яраткан остазы Гаясетдин хәзрәт вафат булгач, аны әнисенең Оренбургтагы туганы Госман хәзрәт мәдрәсәсенә җибәрәләр, анда ул Галиәсгар бине Габдуллаһ остазда ике ел укый. Ахырда, әтисе ярдәме белән, укуын Казандагы атаклы һәм борынгы Апанай мәдрәсәсендә дәвам итә (башка исемнәре – Күл буе, Касыймия). Ул вакытта мәдрәсәнең җитәкчесе Сәлахеддин бине Исхак (1820-1875) булган.

Нургали Хәсәнов йөзегенең рәсеме. Анда: «Мулла Нургали мударрис», – дип язылган.

XIX гасыр ахырына кадәр татарлар арасында Урта Азиянең Бохара, Сәмәрканд һәм Хива шәһәрләрендәге дини үзәкләрендә белем алу бик дәрәҗәле саналган. Анда күп кенә дини уку йортлары, китапханәләр урнашкан булган, дин галимнәре яшәгән. Бохарадагы гыйлем туплаган 7 дин әһеле халык арасында зур хөрмәткә ия булганнар, аларны «дамелла» дип йөрткәннәр. Нургали дә, әтисе Хәсән хәзрәтнең, остазларының рөхсәт һәм хәер-догаларын алып, 1876 елны 26 яшендә Бохараның танылган «Мир-Гарәб» мәдрәсәсенә укырга китә. Камал ишан, Хәким мәхдүм, Әгъләм хәзрәт, Садыр казый, мөфти Әбү Насыр, мөфти Борһан, мөфти Габделхәким хәзрәт, Күкелташ ахуны Ихтыяр хәзрәтләрдән ул тирән дини гыйлем ала.

Туган ягына кайтканнан соң, 1893-1896 нчы елларда Нургали Хәсәнов, эшләрен калдырып, үзен тулысынча тарикать юлында суфыйчылыкны җентекләп өйрәнүгә һәм рухи яктан камилләшүгә багышлый. Ул янәдән Бохара шәһәренә укырга китә.

1886 елда Нургали Хәсәновның Бохарадан кире туган ягына кайтуының сәбәбе танылган дин эшлеклесе, галим, Буа мәдрәсәсе җитәкчесе һәм Буа шәһәре җамигъ мәчете имамы Габденнасыйр Мөхәммәдәминовның үлеме (1806-1886) була. Аны җирләгәннән соң, Буа байлары шундый ук гыйлем иясе булган җитәкчене эзли башлыйлар. Бу мөһим эш белән II гильдия сәүдәгәре, танылган хәйрияче Шәриф (Мөхәммәтшәриф) Муллин (1821-1905) шөгыльләнә. Аның чакыруы буенча, Нургали Хәсәнов, тәвәккәлләп, гаиләсе белән 34 яшендә Буа шәһәренә әйләнеп кайта. Халык, шатланып, аны бертавыштан имам һәм мәдрәсә җитәкчесе итеп сайлый. 1886 елның 12 декабрендә рәсми документлар алып, ул шул җирлектә гомеренең 30 елдан артык өлешен әлеге хезмәткә багышлый.

Нургали хәзрәт Хәсәнов үзенең киңкырлы эшчәнлеге дәвамында күп эшләр башкара. Ул, мәчет имамы буларак, җәмәгать намазларын җитәкли, гыйлем бирә, суфыйчылык юлында мөридләр тәрбияли, ислам динен таратуда зур тырышлык куя, авыру кешеләрне догалар укып өшкерә, халык чакыруы буенча өйләрдә никах, исем кушу, мәрхүмнәрне озату кебек төрле дини йолаларны үти. Нургали хәзрәт метрика көндәлекләрендә мәхәлләдә яшәүчеләрнең гражданлык актларын да теркәп бара, туу, үлү, гаилә хәле хакында белешмәләр бирә, бәхәсле мәсьәләләрне чишә, мирас малын дин буенча гадел итеп бүлүдә ярдәм итә, төшләр юрый. Әлеге чорның кануннары буенча, дин әһеле буларак, ул вазыйфалы затлардан, судта гаепләнүчеләрдән, шаһитлардан Коръәнгә кул куйдырып антлар ала, хәрби хезмәткә чакырылучыларны озата. Мәхәллә кешеләре аңа үзләрен борчыган сораулар буенча еш мөрәҗәгать иткәннәр, аның белән киңәшләшкәннәр, хәер-фатихасын, догаларын алырга ты-

рышканнар. Уңышлы хезмәте өчен, Нургали хәзрәт 1902 елны Буа шәһәре ахуны итеп билгеләнә.

Нургали Хәсәнов иң күп вакытын Буа мәдрәсәсе шәкертләрен укыту һәм тәрбияләү эшенә багышлый. Өлкән сыйныфларда ул тәфсир, фикъһ, хәдис һәм башка фәннәрдән дәресләр алып бара. Аның тырышлыгы һәм максатчанлыгы нәтиҗәсендә, Буа мәдрәсәсенең элеккеге даны сакланып кала һәм ул әлеге чорда Урта Идел буеның алдынгы мөселман уку йортларының берсе булып санала. Мәдрәсәдә Буа өязендәге булачак дин әһелләренең күпчелеге укыган. Анда Казан, Сембер, Әстерхан, Саратов губерналарыннан килгән шәкертләр шактый була. 1905 елда мәдрәсәдә 500гә якын шәкерт белем алган. Укучыларның күплеге «укыту программасының киң булуы, шулай ук мөселман халкы үзәгендә урнашкан мәдрәсәнең борынгы даны» белән дә аңлатылган. 1911 елга кадәр укыту классик дини китаплар нигезендә кадимичә алып барылган. 1913 елда мәдрәсәдә 12 мөгаллим эшләгән. Мәдрәсә комплексы беренче җамигъ мәчете ишек алдындагы 2 таш һәм 3 агачтан төзелгән иркен биналарга, хуҗалык корылмаларына урнашкан була.

Нургали Хәсәновның имзасы һәм мөһерләре. Мөһердәге язуның тәрҗемәсе: «Аллаһның рәхмәтенә мохтаҗ булган Аның колы Нургали мулла Хәсән улы»

Дин галиме Нургали Хәсәнов татар милләтенең, мөселман өммәтенең хәлен күреп, аларның проблемаларыннан читтә кала алмаган. Мөмкинлеге булган кадәр ул, үз халкын яклап чыгып, иҗтимагый тормышта актив катнашкан. Мәсәлән, 1905 елның 17 мартында, Буа өязе ахуны Габделсамад Шаһидуллин белән бергә, үз мәчетендә Буа өязенең һәр мәхәллә мулласын һәм икешәр вәкил чакырып – 250 кеше җыеп, корылтай уздырган. Катнашучылар Россия императоры исеменә төрле сәяси таләпләр һәм үтенечләр кергән петиция язганнар. Андагы таләпләр арасында: «Барча мәдрәсәләр, мәктәпләр һәм вакыфлар ОМДН (мөфтият) карамагында булуы; керәшен татарларына христиан диненнән ирекле рәвештә исламга күчүне закон белән рөхсәт итү; мөселманнар тәрбияләгән ташланган балаларның закон буенча мөселман була алулары; мөселман дин әһелләренең хокукларын православие руханилары белән тигезләү; муллалар өчен рус телен мәҗбүри рәвештә уку чикләүләрен бетерү; татарларга газета-журналларны бастырырга рөхсәт бирү; татарларга дәүләт хезмәтенә эшкә керә алу мөмкинлеге бирү; татар телендә профессиональ уку йортларын ача алу…» һ.б. бар. Шуңа охшаган язмалар татарлар яшәгән башка төбәкләрдән дә җибәрелгән. Ул елны революция булу нәтиҗәсендә, император Николай II хөкүмәте югарыда әйтелгәннәрнең кайберләрен гамәлгә кертергә мәҗбүр булган.

Ул 1910 елда, Буа өязенең ахуны Габделсамад Шаһидуллин белән, «Буа өязе мөселманнары хәйрия җәмгыяте»н оештырган. Анда катнашкан 75 әгъзаның 55е имам булган. Алар җыелган акчаларны һәм байларның ярдәм малларын өяздә яшәгән мохтаҗ мөселманнарга бирү белән актив шөгыльләнгәннәр. Беренче бөтендөнья сугышы башлангач та, Нургали Хәсәнов дәүләткә дә хәйрия ярдәме күрсәткән. 1914 елда, Буа өязе муллалары белән, өяз казнасына саллы гына акчалар җыеп биргән. Яраланган солдатларны дәвалаган Буа земство хастаханәсенә дә ул халыктан җыелган матди ярдәмнәрне, сөлгеләрне, мендәрләрне, кием-салымнарны һ.б. кирәк-яракларны алып килә торган булган.

1906 елның җәендә галим Нургали Хәсәнов хаҗ сәфәренә чыгып китә. Аның бу дәвамлы сәфәре ул чорның күренекле дин галимнәре, суфи ишаннары, сәясәтчеләр белән очрашуларга, аралашуларга бай була. Нургали Хәсәнов, Мәскәү, Петербург, Бакчасарай, Одесса, Истанбул, Бурса, Родос, Дәмәшекъ, Бәйрут, Мәдинә, Мәккә, Җиддә һ.б. шәһәрләрдә булып, күп тарихи урыннарны күрә, гыйбадәт кыла. Истанбулда ул Госманлы империясенең җитәкчесе, мөселманнарның танылган хәлифе, солтан Габделхәмид II белән очрашуга лаек була. Нәтиҗәдә, алар арасында бик җылы мөнәсәбәтләр урнаша. Хәлиф аңа, зур галим, мөхтәрәм кунак буларак, иң югары хөрмәтен күрсәтә. Аның чакыруы буенча, Нургали хәзрәт Рамазан аен солтан сараенда үткәрә. Аңа пәйгамбәрләрнең (г.с.) борынгы заманнардан сакланган шәхси әйберләрен, тарихи урыннарны, мөһим уку йортларын, китапханәләрне күрсәтәләр. Моның өстенә, солтан Нургали хәзрәткә, ислам дине үсешенә керткән зур өлеше өчен, иң югары дәрәҗәдәге дәүләт ордены бирә һәм хөкүмәт делегациясе составында олы хаҗ сәфәренә юллама белән бүләкли. Мәдинәдә аны, солтанның мөхтәрәм кунагы буларак, Мөхәммәд пәйгамбәрнең (с.г.в.), Әбү Бәкер һәм Гомәрнең төрбәләренә, ә Мәккәдә изге Кәгъбәтуллаһ эченә кертәләр. Бу сәфәреннән Нургали хәзрәт бик күп гыйбрәт, файда алып кайта һәм күргәннәрен, сәяхәтнамә буларак, 1907 елны китап итеп бастыра.

Нургали Хәсәнов үз гомерендә бик күп шәкертләр укыта һәм тәрбияли. Алар арсыннан 200гә якыны имам, 10 ахун, 8 зур мәдрәсә җитәкчесе һәм күпсанлы мәзин һәм мөгаллимнәр Идел буеның төрле мәчет һәм мәхәлләләрендә хезмәт иткәннәр. Укучылары арасында татар халкының абруйлы шәхесләре дә бар. Мәсәлән: тарихчы, күренекле җәмәгать һәм дин эшлеклесе, II чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты Һади Атласи (1876-1938), күренекле дин эшлеклесе, II чакырылыш Дәүләт Думасы депутаты Габдулла Нәҗметдинов (1869-1915), язучы Зариф Бәшири (1888-1962), дин галиме, шагыйрь Мөхәммәд Садыйк Иманколый (1870-1932), күренекле дин эшлеклесе Камәретдин Салихов (1890-1962), язучы Гомәр Толымбай (Г.Ш.Шаһиәхмәтов, 1900-1938), педагог, тел белгече һәм тәрҗемәче Бакый Халидов (1905-1968), журналист, күренекле җәмәгать һәм дин эшлеклесе Фатих (Мөхәммәдфатих) Мортазин (1875-1937), педагог, журналист, нәшир Шиһабетдин Әхмәров (1882-1966), тюрколог, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе Кәрим Сәгыйди (1888-1939), прозаик, драматург Ярулла Вәли (1879-1937), танылган җәмәгать эшлеклесе, педагог, публицист Ибраһим Бикколов (1884-1938), күренекле педагог Фатих Садыйков (Капал Садики, Фатих Капал), мәшһүр каллиграф Гарифҗан Вәлиди (Гарифҗан Буави, 1879-1946), Самара шәһәре ахуны, Самараның 1 нче җамигъ мәчете һәм мәдрәсәсенең җитәкчесе Шиһабетдин Минюшев (1855-1930), күренекле дин эшлеклесе, Буа өязе ахуны Габделсамад Шаһидуллин (1866-1928), журналист, язучы Рәүф (Габдерәүф) Шаһидуллин (1889-1942), партия, идарә хезмәткәре Нури Алиев (1898-1961), Миасс шәһәрендәге танылган дин әһеле, нәшир Сәлахетдин Бәширов (1862-193?),

танылган дин әһеле, Касыйм, соңрак Петроград ахуны Фәттахетдин Давлеткамов (Давлекамов, 1875-193?) һәм башкалар.

Нургали хәзрәт Буа өязенең Күл Черкене авылы имамы Идрис Урманче (танылган татар рәссамы һәм сынчы Бакый Урманченың (1897-1990) әтисе) белән якын дуслар булганнар. Бакый Урманченың хатирәләре сакланып калган. Ул анда болай дип язган: *«Нургали дамелла Буа мәдрәсәсенең җитәкчесе булганда мин кечкенә идем. Аны үзсүзле кеше дип санаганнар, әмма ул бик зур белемгә ия булган. Галимнең сәләте төрле юллар белән аның укучыларына да күчеп барган. Минем танышларым, [татар] интеллигенция арасында, Буа мәдрәсәсен тәмамлаучылар бар: Һади Атласи, Шакир Мөхәммәдов, Капал Фатыйх, Шиһаб Әхмәров, Нури Галиев, Ибраһим Бикколов, Самад ахун Шаһидуллин. Алар барысы да Нургали дамелла укучылары».*

Тарихчы Рәшит Амишов (Маликов) һәм аның дин әһеле, мәгърифәтче Нургали Хәсәновка нисбәтле китабының тышлыгы

Танылган татар дин галиме, мөфти **Ризаэддин Фәхреддин** (1859-1936) Нургали Хәсәнов хакында, зур галим, ачык һәм мөлаем кеше, дип искәртә. *«Бер тапкыр Оренбургта яшәгән вакытта, аның Оренбургка килүе турында белдем. Озак вакыт ул миндә кунак булды»,* – ди. Мәшһүр галим суфи Ибн Гарәбига багышланган китабында Нургали хәзрәтнең хаҗ сәфәре вакытында күргән рәсем тасвирламасын китерә.

Дин галиме Нургали Хәсәнов иҗади эшчәнлеккә дә вакыт тапкан. Ул үз гомерендә егермедән артык китап язып, 1910 елга кадәр аларның унысын бастырыга да өлгергән.

Нургали Хәсәнов, гомеренең соңгы ике елында еш кына авырса да, мәдрәсәдә белем бирүен туктатмый һәм җәмәгать тормышында да актив катнаша. Ул еллар илдә зур үзгәрешләр, тетрәнүләр чорына туры килә: Беренче бөтендөнья сугышы, 1917 елда патша хакимиятенең бәреп төшерелүе һәм хакимияткә Вакытлы хөкүмәт килү, шул ук елны большевиклар власте урнашу, канкойгыч Гражданнар сугышы – Буа шәһәренең йә аклар, йә кызыллар кулына күчүе, халыкны тентүләр, талаулар һәм ачлык афәте... Нургали хәзрәт Хәсәнов бу хәлләрнең барысын да үз йөрәге аша кичерә. Кызганыч ки, әлеге чорга караган тарихи чыганаклар аз сакланган. Илебез тарихының шушы фетнәле чорында Нургали Хәсәновның нинди сынаулар кичерүен күз алдына китерүе дә авыр. Каты авырудан соң, 1919 елның 19 маенда 67 нче яшендә аның гомере өзелә.

(Язма Рәшит Амишовның «Дин галиме Нургали Хәсәнов: тәрҗемәи хәле» диган монографик хезмәтеннән (Казан, 2022) алынды.) ■

Ислам. Дини сүзлек

Ислам әхлагы

Ислам дине әхлагының барлыкка килүе Аллаһы Тәгалә исеменнән халыкка вәгазьләр сөйләүче Мөхәммәд пәйгамбәр (с.г.в.) эшчәнлеге белән тыгыз бәйләнгән. Ислам өйрәтүенчә, Алла Коръәнне кешеләргә яхшылык белән явызлыкны аеруда кулланма булсын өчен иңдергән.

Ислам әхлагы нигезендә тәкъдиргә ышану ята. Ислам дине, бер генә җан иясе дә иртәгә үзенә ни буласын, кайда, ничек үләсен белми, дип раслый. Шәригать мөселманга хәтта иртәгә нәрсә эшләячәген әйткәндә дә «Аллаһ теләсә», «Аллаһ боерса» яки «Аллаһ бирсә» дигән сүзләрне өстәргә куша. Аллага ышану ул ислам диненең барлык таләпләрен дә үтәүне күздә тота. Алар шәригатьтә теркәлгән һәм канун көченә ия. Дин әһелләре хәзер бу таләпләрне мөселманнарның әхлак нормалары итеп карый. Ислам өйрәтүенчә, кешеләрнең мөселманнарга һәм кяферләргә бүленүе – Аллаһ ихтыяры. Аллаһ мөселманнарны башка халыклардан сөеклерәк итеп яралткан, шунлыктан мөселманнарга башка диндәгеләр белән туганлык мөнәсәбәтләренә керү дә тыела. Чын мөселман бары тик бер Аллаһны гына таный.

Ислам динен тотучылар өчен кеше үтерү, фәхешлек, эчүчелек, караклык һәм башка гөнаһлы гамәлләр тыела. Аллаһ гөнаһлардан арынган мөселманнарга, фани дөньядан киткәч, оҗмах вәгъдә итә.

Язма «Ислам. Белешмә сүзлек» (төзүчесе – Заһид Шәфигый, фәнни редакторы – Равил Үтәбәй-Кәрими) китабын (1993) файдаланып әзерләнде. ■

Пәйгамбәребез Мөхәммәднең (с.г.в.) хәдисләре*

Әхмәдвәли Рәхими

55 Әбү һөрәйра разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Адәм углы сәҗдә аятен укып сәҗдә кылса, шайтан читкә аерылып китеп елар һәм әйтер: «Нинди зур нәдамәт *(үкенеч)*, Адәм углы сәҗдә белән боерылды, сәҗдә дә кылды, аңарга җәннәт булды. Мин дә сәҗдә белән боерылдым, тыңламадым. Миңа тәмуг булды», – дияр».

Укы һәм исеңдә калдыр!

56 Таләкъ бине Гали әл-Хәнәфи разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Рөкүгъ һәм сәҗдә дөрес итеп кылынмаган һәм хошуг *(түбәнчелек)* белән укылмаган намазга Аллаһ карамас».

Укы һәм исеңдә калдыр!

57 Әнәс бине Мәлик разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Берәү намазын онытса яки йокыда калдырса, кәффарәт кылсын, хәтеренә килгәч, намазын укысын».

Укы һәм исеңдә калдыр!

58 Рафигъ бине Хадиҗ разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Сабәх намазын *(иртәнге намаз)* кичектермичә, яктыргач укыгыз. Кичектермәүнең савабы олугтыр».

Укы һәм исеңдә калдыр!

59 Гомәр бине Руәйбә разыйаллаһу ганһү риваять итә. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Кояш чыкканчы *(иртәнге)* һәм кояш батудан элек *(икенде)* намаз укыган адәм утка керәчәк түгел».

Укы һәм исеңдә калдыр!

60 Ибне Мәсгуд һәм Сәмир бине Җүндәб разыйаллаһу ганһүмә риваять итәләр. Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вәсәллам әйткән: «Коръәндә: «Хәфизу галәссаләүәти үәс-саләтил вуста» *(«Намазларны вә урта намазны калдырмыйча дәвам итегез»)*, – дигән аятьтә «саләтүл вуста» *(урта намаз)* ул — икенде намазы» («Бәкара» сүрәсе, 238 аять.)

Текстны басмага ***Айсылу Вәлиева*** *әзерләде.* ■

Дәвамы. Башы журналның 12 нче (2021) санында.

* Хәдисләр Шәех әл-Камил Вәли әд-Динмөхәммәд бине Габделхатыйб әт-Тәбризинең «Мишкәтүль мәсабих» китабы буенча әзерләнгән һәм 1913 елда 3 китапта басылып чыккан.

Безнең мирас №9 сентябрь 2022

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Унбишенче дәрес

Мәдинәгә һиҗрәт. Сәур тавында өч көн. Суракның пәйгамбәр (с.г.в.) артыннан төшүе.

Мөгаллим: Мәккәдәге Кәгъбәтуллаһка Гарәбстанның бөтен тарафларыннан елга бер мәртәбә гарәпләр килеп хаҗ кыла торган булганнар, дигән идек. Шулвакыт Мөхәммәднең (с.г.в.) боларны дингә өндәгәнен сөйләгән идек. Шулайдыр бит?

Шәкерт: Шулай, хәлфә, сөйләгән идегез.

Мөгаллим: Бервакыт Мәдинә дигән бер шәһәрдән унике кеше хаҗга килә. Пәйгамбәр (с.г.в.), боларны очратып, дингә өнди. Алар бик яхшы, саф күңелле кешеләр икән: пәйгамбәрнең (с.г.в.) сүзләреннән бик тәэсирләнеп, аңа иман китерәләр. Мәдинәгә кайткач, болар, өндәп, байтак кешеләрне дингә кертәләр. Шулай итеп, Мәдинәдә пәйгамбәргә (с.г.в.) иман китергән кешеләр шактый ук күбәеп китә. Икенче елны болар хаҗга сиксәнләп* кеше белән киләләр. Пәйгамбәр (с.г.в.) бер төнне тау арасында болар белән күрешә. Шулвакыт пәйгамбәр (с.г.в.) боларга үзенең Мәдинәгә барып, алар арасында торырга теләгәнлеген аңлата. Алар моны бик хуш кабул итәләр, аны дошманнардан сакларга, кулдан килгәнчә ярдәм итәргә вәгъдә бирәләр. Шуннан соң пәйгамбәр (с.г.в.) сәхабәләргә дә Мәдинәгә күчәргә куша. Шулай итеп, сәхабәләр, гаиләләрен алып, ватаннарын, мал-туарларын, йортларын ташлап, Мәдинәгә күчәләр. Бу бит бик авыр булгандыр, шулаймы?

Шәкерт: Әлбәттә, авыр булган инде.

Мөгаллим: Ләкин алар шул авырлыкларны сабырлык белән күтәргәннәр. Үз диннәрен саклау өчен, бөтен нәрсәләрен корбан иткәннәр. Сәхабәләр, ач вә ялангач хәлдә, Мәдинәгә барып төшкәннәр. Мәдинәдәге пәйгамбәргә (с.г.в.) иман китергән кешеләр боларны бик яхшы каршы алганнар. Аларны өйләренә керткәннәр, ашатканнар-эчерткәннәр, малларын биргәннәр. Шулай итеп, сәхабәләр барсы да Мәдинәгә күчеп беткәннәр. Бары пәйгамбәр (с.г.в.) белән Әбү Бәкернең гаиләсе һәм пәйгамбәрнең (с.г.в.) кияве Гали генә Мәккәдә калган.

Сәхабәләрнең бөтенесе дә Мәдинәгә күчеп беткәч, гаять дәрәҗәдә эссе бер көнне пәйгамбәргә Җәбраил фәрештә килә дә: «Сине мөшрикләр бүген кич белән үтерергә җыеналар. Син тизрәк Мәдинәгә кит!» – ди. Алар пәйгамбәрнең (с.г.в.) сәхабәләре артыннан Мәдинәгә күчеп китеп, анда ныгуыннан курыкканнар. Ләкин Аллаһы Тәгаләгә бернәрсә дә яшерен түгел шул. Ул моны пәйгамбәренә (с.г.в.) белдергән. Шуннан соң пәйгамбәр (с.г.в.) яшеренеп кенә Әбү Бәкернең өенә барган да: «Хәзер үк тор! Бүген төнлә Мәккәдән китәчәкбез», – дигән. Әбү

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

* Дөресе – болар җитмеш биш кешедер.

Бәкер әүвәлдән үк юл өчен ике дөя симертеп тора икән. Ул дөяләрне иярләткән, хәзерләткән. Юл күрсәтеп бару өчен, оста бер гарәпне яллаганнар. Аңа дөяләрне биреп, өч көннән соң Мәккәгә якын гына булган Сәур дигән тауга килергә кушканнар. Шуннан Мәдинәгә китәргә ниятләгәннәр. Караңгы төшү белән, уникe таза мөшрик пәйгамбәрнең (с.г.в.) өен камап алган. Пәйгамбәр (с.г.в.) өендә кияве Гали берлә булган. Пәйгамбәр (с.г.в.) Галигә эшне аңлаткан һәм аны үз урынында калдырачагын сөйләгән. Гали, пәйгамбәрнең (с.г.в.) ризалыгы өчен: «Баш өсте», – дип, моны кабул иткән. Шуннан соң пәйгамбәр (с.г.в.) үзе йоклый торган урынга Галине яткырып, үз юрганы белән япкан да өеннән чыгып киткән. Теге егетләр Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән барысы да йоклап киткәннәр: аның чыкканлыгын сизмәгәннәр. Пәйгамбәр (с.г.в.) тиз генә Әбү Бәкергә кереп, аның белән Мәккәдән яшеренеп чыгып, Сәур тавына барган һәм шундагы мәгарәгә кереп яшеренгәннәр.

Теге егетләр бервакыт, таң атып килгәндә: «Ник бу бер дә өеннән чыкмады икән?» – дип, өйгә кергәннәр. Керсәләр, ни күзләре белән күрсеннәр, түшәктә пәйгамбәр (с.г.в.) түгел, Гали ята.

Аңардан пәйгамбәрнең (с.г.в.) кайдалыгын сораганнар. Ул әйтмәгән, шунлыктан аны тукмап ташлаганнар. Шуннан соң, вакыт үткәрмичә, пәйгамбәрне (с.г.в.) эзләргә керешкәннәр. Әбү Бәкернең өенә дә кереп чыкканнар. Мәккәдә һичбер өйне тентемичә калдырмаганнар. Шуннан соң, атка атланып, тирә-яклардан эзли башлаганнар. Эзләү өч көн дәвам итсә дә, һичбер нәтиҗәсе булмаган. Пәйгамбәр (с.г.в.) вә иптәшен таба алмаганнар. Ошбу өч көн эчендә төннәрен Әбү Бәкернең бер улы боларның хәлләрен белеп, азык илтеп торган. Әбү Бәкернең бер хезмәтчесе, теге килеп киткәч, шунда көтеп йөргән куйларын китереп, аяк эзләрен юк итә торган булган. Өч көн эзләп тә таба алмагач, мөшрикләр, бөтенләй өмет өзеп, эзләүдән туктаганнар. Шуннан соң әлеге гарәп Сәур тавына дөяләрне алып барган да, пәйгамбәр (с.г.в.) вә Әбү Бәкер, дөяләргә атланып, юлга чыкканнар.

Мосафирлар Сәур тавыннан беркадәр ераклашкач, ничектер, бу хакта Сурака дигән бер гарәпкә ишетелгән. Мәккә гарәпләре пәйгамбәрне (с.г.в.) үтергән яисә тотып китергән кешегә зур бүләкләр бирергә вәгъдә иткәннәр икән. Сурака, әлеге хәбәрне ишетү белән, беркемгә дә әйтмәстән, коралларын тагып, йөгерек атка атланып, тегеләрнең артларыннан куа киткән һәм бик тиз арада аларга якынлаша да башлаган. Әбү Бәкер куркуыннан гел артка әйләнеп карый икән. Ә пәйгамбәр (с.г.в.), бернәрсә дә булмаган төсле, кычкырып Коръән укып бара икән. Әбү Бәкер, Сураканы күрү белән, пәйгамбәргә (с.г.в.): «Харап булдык, әнә арттан бер атлы кеше җитеп килә!» – дигән. Пәйгамбәр (с.г.в.) моңа: «Тыныч бул, курыкма!» – дигән. Сурака боларга якынлашканда, Аллаһының кодрәте белән, аты абына-сөртенә һәм аяклары җиргә бата башлаган. Сурака атны камчылап та караган, ләкин ат һаман сөртенә, бата икән. Шуннан соң бу мөшрик: «Ахыры миңа Мөхәммәднең бәддогасы төшә, эш харап. Тизрәк моңардан гафу үтенергә кирәк», – дигән уйга килгән һәм шунда ук пәйгамбәргә (с.г.в.): «Тукта, мин сиңа тимәячәкмен. Тыныч бул!» – дип кычкырган. Пәйгамбәр (с.г.в.) туктагач, Сурака – аңа барып, бу кабахәтлеге өчен гафу үтенгән. Пәйгамбәрләр шәфкатьле, миһербанлы булалар бит алар. Ул аны шунда ук гафу иткән. Шуннан соң Сурака Мәккәгә, пәйгамбәр (с.г.в.) вә Әбү Бәкер исә Мәдинәгә киткән. Менә шулай итеп, Аллаһы Тәгаләнең ярдәме белән, пәйгамбәр (с.г.в.) мөшрикләрнең яман ниятләреннән котылган. Моннан соң аларга Мәдинәгә барып җиткәнче бернинди дә куркыныч янамаган.

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

ШАГЫЙРЬ НУРИ АРСЛАННЫҢ ТУУЫНА 110 ЕЛ

Яшь шагыйрьнең илһамланып иҗат иткән чагы

Нури Арслан

Шагыйрь, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1985), 1946 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы Нури Арслан (Нури Газиз улы Арсланов) 1912 елның 19 сентябрендә Казакъстанның (хәзерге мөстәкыйль Казакъстан Республикасының) Кызылъяр (Петропавел) шәһәрендә эшче-көнлекче гаиләсендә дөньяга килә. 1928 елда ул Күкчәтау шәһәрендә җидееллык татар мәктәбен тәмамлый, аннары, укуын дәвам итү теләге белән Казанга килеп, 1928-1931 нче елларда сәнгать техникумының рәсем бүлегендә укый. Техникумны тәмамлагач, 1933 елның көзенә кадәр ул әүвәл – Татарстанның Кукмара эшчеләр бистәсендә, аннары Урта Азия мәктәпләрендә рәсем-сызым укытучысы һәм Ерак Көнчыгыш шәһәрләрендә рәссам-бизәүче булып эшли.

Нури Арсланов 1991 елның 12 апрелендә вафат булды һәм Казанның Яңа бистә зиратында җирләнде.



Шагыйрь Нури Арслан

Атлантида

Атлантида булды микән чынлап?
Тынгы бирми сорау һич кенә:
Әллә кайдан, ерак-ераклардан
Һәлакәтле бер моң иштелә.

Кинәт юкка чыккан бөтен кыйтга,
Тау дулкыннар күккә ашканнар:
Бер мизгелдә илләр, шәһәрләрне,
Һәйкәлләрне сулар басканнар.

Океан упкан кебек Атлант җирен,
Дәүләтләрне монда җир упкан:
Дәште-Кыпчак, Болгар, Алтын Урда...
Бер-берсенең тамрын корыткан.

Ничә тапкыр килгән монда яулар,
Кичергәннәр илне кылычтан...
Калдыгын да көлгә дүндерергә
Миссионерлар күпме тырышкан.

Сәхифәләр тузган, юкка чыккан...
Ә без – менә, без – бар, булганбыз!
Фал ачабыз, ләкин баш ватабыз:
Әллә кыпчак, әллә болгар без?

Кем булгандыр бабам? Кыпчакмы ул,
Болгармы ул? Нинди аерма?!
Татар дигән исем йөртәбез без –
Татар каны ага тамырда!

Атлантида! Атлантида баткан!
Эз калмаган бөек халыктан...
Ә без – менә, без – бар, эз бар җирдә –
Без батырган саен калыккан.

Атлантида язмышы юк безгә,
Оныкларның ачык бабасы:
– Нәселең кем? – дип сорасалар әгәр,
Әйтерләр:
– Без – татар баласы!

Татарстан дигән Ватаным бар,
Татар дигән халкым бар минем!
Узганнардан түгел, мин халкыма
Киләчәктән урын барлыймын!

1969 ■

Татар шигъриятендә мөһаҗирлек хәрәкәте һәм Исхакый

Тәлгат Галиуллин, филология фәннәре докторы

Куш йөрәкле мөһаҗир

Татар җәмгыятендә, бигрәк тә шигърияттә мөһаҗирлек хәрәкәтенә игътибар үсү бөек язучыбыз, атаклы «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре авторы, көрәшче Гаяз Исхакыйның исеме һәм мирасы, әүвәл өлешчә, соңрак тулысынча акланып туган халкына кайтуга да бәйле иде. Мөһаҗир сүзе, язмышы, дип әйтүгә, иң беренче чиратта, күз алдына чит мәмләкәтләрдә яшәүче татарларны туплап, милләт гаме белән яшәгән Г.Исхакый образы һәм эшчәнлеге килеп баса[1].

Гаяз Исхакый (1878-1954)

Бу шәхеснең туган илдә ифрат хөрмәтле кеше булуын үләренә берничә атна кала үзгә бөегебез – Габдулла Тукай күтәреп чыга.

1913 елның 13 мартында иҗат ителгән «Мөхәрриргә» шигырендә ул Архангельск губернасының Мезень шәһәрендә сөргендәге Исхакыйга: *«Кайт әле монда, Ватанга, кайт әле, саргайтмале!»* – дип, ихласи үтенеп мөрәҗәгать итә. Алдагы юлларда шагыйрь шулай чакыруның сәбәбен дә ачып сала: синнән башка татар җәмгыяте *«алты ел торды чупансыз»* (җитәкчесез, көтүчесез)..., синең «пакь вә чын сүзеңнән», *«күз карашыңнан керер җир тапмас»* иде гамьсез, надан әрсезләр, монафикълар, ди – *«бер карашың иң шома ялганчыны сүздән тыя»*.

Үзенә күрә васыяте вә программ шигыре булган бу әсәреннән соң Тукай «Буш вакыт» һәм «Казан» дип аталган кыска күләмле ике шигырь иҗат итәргә генә өлгерә.

Күренә ки, Тукайның «Мөхәрриргә» кыйтгасында, шәхси, дустанә мөнәсәбәт белән беррәттән, Исхакыйның милләтне берләштерү, аңа тиешле сәяси юнәлеш

[1] Кара: Гаяз Исхакый һәм XX гасыр башында татар милли яңарышы. – Казан, 2018.

Ахыры. Башы журналның 8 нче (2022) санында.

бирү сәләте дә алга чыга.

Тукайның шушы әсәре хәзерге сүз осталарыбызны да тирән фәлсәфи вә тормышчан мәгънәсе белән уйга сала. «Эндәшү» шигырендә Р.Зәйдулла ул чордан алып безнең көннәргәчә милләт тормышында яхшы якка үзгәрешләрнең сизелмәвенә (*«Учагы сүнгән Казан»* гыйбарәсе барысын да ачып сала) басым ясый һәм җитди соравын калкытып куя:

«Тукай Гаязга эндәшкән,
Мин соң кемгә эндәшим?..»

Күпчелек шигъри багышлаулар Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге эшчәнлеген, милләтпәрвәрлеген, туган милләте өчен янып-көеп яшәвен тулырак һәм тирәнрәк чагылдыру омтылышы, нияте белән язылалар.

Бөек әдибебезне олылаган әсәрләр күләмнәре буенча Тукай намена багышлаулардан гына калыша булыр дип уйлыйм. Балалар шигъриятендә, проза өлкәсендә дә эзләнүләр тукталып тормый. Ф.Латыйфи соңгы олы сугыш чорында СМЕРШ майоры Гыймаевның *«үтә хәйләкәр... шпион, корткыч», «блуждающий атом»*ны – Исхакыйны – кулга алу хыялының челпәрәмә килүен «Ишелеп төшкән бәхет» романында сурәтли.

Назыйм Хикмәт (1902-1963)

Күләмле шигъри әсәрләрдән Р.Низаминың «Ике мөһаҗир», Ә.Мәхмүдовның «Пәйгамбәр» исемле сәяси поэмалары игътибарга лаек.

Р.Низаминың «Ике мөһаҗир» поэмасы ике тарихи затны – Гаяз Исхакый белән төрек шагыйре Назыйм Хикмәтне янәшә куеп сурәтләве белән үзенчәлекле. Аларны, үз теләк-ниятләреннән башка, чит илләрдә яшәү мәҗбүрияте якынлаштыра. Икесе дә – туган илләрендә урнашкан сәяси системаның дошманнары һәм корбаннары. Ләкин конфликтның шартлары, мотивлары төрле-төрле, капма-каршы. Мәкер, алдау юлы белән Россиядә хакимиятне кулларына төшергән большевикларның асылын пәйгамбәрләрчә сизгерлек белән төшенгән Гаяз Исхакый чит илгә чыгып китә һәм империянең гомерен озынайткан, милләтен караңгылык упкынына ташлаган советларга каршы көрәшен төрле шартларда соңгы сулышына чаклы дәвам итә. Төрек шагыйре Назыйм Хикмәт, киресенчә, коммунистлар йөзендә дөньяны коллык богауларыннан коткарырга килгән изге көч күрә һәм Ататөрек

төзеп калдырган республикага каршы көрәш юлына баса. Зыялылар арасында Назыйм Хикмәт кебек большевикларның кызыл шигарьләренә, аллы-гөлле вәгъдәләренә ихластан ышанган кешеләр аз булмаган.

«Исхакыйны Назыйм Хикмәт белән
Куеп карыйм кайчак янәшә.
Назыйм Хикмәт – сәяси бер корбан,
Ә Исхакый –
Туры Тукайга тиң ләбаса».

Үзенең чор һәм олы сәясәт турында уйлануларын автор «Идел белән Урал арасы» һәм «Казан. Ирек мәйданында уйлану» исемле соңгы бүлектә ачып сала. Беренче атаманы ул Г.Исхакыйның шул исемдәге тарихи-фәнни хезмәтенең исемен беркадәр үзгәртеп куя һәм биредә яшәгән халыклар бары шушы җирдә генә бәхетле була ала дигән фикер уздыра:

«Идел белән Урал арасы ла,
«Өф-өф» итеп кенә барасы.
Чөкердәшеп шунда яшәсеннәр
Башкорт белән татар баласы».

Поэманың соңгы бабында автор Ирек мәйданында милли киләчәк хакына ачлык игълан иткән Рәшит Әхмәтҗан, Зәки Зәйнуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Газинур Морат, Заһид Мәхмүди һ.б. каләм осталарының «татар телен саклап калыр өчен» халыктан ярдәм сорауларын хуплый.

Дөрес, автор, вакыт-вакыт, хыялый хискә бирелепме, ритмика яме артыннан куыпмы, шактый беркатлы фикерләр дә әйтеп ташлый:

«...Ир-егетләр атны иярләгән,
Кулларында – язмыш тезгене».

Йа Ходам, шундый гаярь ир-егетләребез кайларда йөри дә, ни өчен алар тарих биргән мөмкинлектән файдаланып кала алмадылар икән дигән сөальләр һавада асылынып кала. Ышандыру көченә үзе дә ышанып җитмәгәндә, бүгенгене җетерәк күрсәтү максаты белән, шагыйрь үткәнгә әйләнеп кайта, Бөек Болгар, Алтын Урда чорларын ярдәмгә чакыра һәм данлы тарихыбыздан көч-дәрт ала кебек:

«Ничек итеп яшәү кирәклеген
Күрсәткән бит юкса Алтын Урда!
Яшәгәнбез ләса алтын чорда».

Поэманың соңгы өлешендә автор мескенләнебрәк куя:

«Бер тамчы да артык сорамыйбыз,
Кирәк бары суверенитет!»

Яшьлек җилпенүенә хас мондый романтик беркатлылык чоры узганын, сәдака сорау урамда утыручы таҗик чегәннәренә генә килешкәнен тәҗрибәле

сәясәтче Р.Низами сиземләргә тиеш иде ләбаса. Бәйсезлекне (суверенитетны), азатлыкны теләнеп түгел, көрәшеп алалар, аның өчен халыкны гафләт йокысыннан уятырга, битарафлык «баз»ыннан чыгарырга, коллык психологиясеннән арындырырга кирәк.

Хакимияткә большевиклар килеп, ватандашлар арасында сугыш башлангач, мөмкинлеге, кыюлыгы, үҗәтлеге булган татар зыялыларының, шулар исәбеннән Гаяз Исхакыйның да илдән чыгып китү сәбәпләрен үзәккә алган лиро-эпик әсәрләрнең берсе – Ә.Мәхмүдовның «Пәйгамбәр»[2] поэмасы булды. Тарихи җирлеккә таянып язылган әсәрнең үзәк дискурсын XX гасыр башында татар милләте бирә алган шәхес белән горурлану хисе билгели, көрәшче рухының милли идея белән кушылуын раслау үткәнгә хөрмәт төсмерен ала. Исхакыйны автор *«милләтнең күз яше, сагышы», «милләтнең сакчысы»* дип зурлап, кылган изге гамәлләренең үлемсезлеген калкытып куя.

«

Чистай, Казан төрмәләре, салкын кышлы Архангельск сөргеннәре, аннан качулар, кеше фатирларында посып яшәүләр, совет хакимияте, Сталин, Берия иярченнәре тарафыннан эзәрлекләнүләр – барысы да Исхакый язмышына төшә; ул гомере буена диярлек үткен кылыч йөзеннән йөрергә мәҗбүр була.

Поэма авторының дөнья тарихыннан хәбәрдар булуы Исхакыйны киң җирлектә сурәтләп, олы шәхес булуын күрсәтергә мөмкинлек бирә: *«кадакта торган Гайсә»*не искә алу, Помпей язмышы, татарның мөстәкыйль дәүләтенә нигез салган Олуг Мөхәммәд ханны калкыту... Алдан күрүчән Исхакый акларның, бигрәк тә кызылларның татар халкына яхшылык эшләмәячәкләрен алдан сизенә: *«Дус түгел татарга Ленин да, Колчак та»,* – ди. Шушы җөмлә Ватандашлар сугышын оештырган ике көчнең, үзара сугышсалар да, *«бердәм һәм бүленмәс Россия»* сакчылары буларак уртак фикердә торуларын фаш итә.

Исхакый поэмада үз халкын мөкиббән китеп яраткан шәхес итеп сурәтләнсә дә, милләтенең холкында, яшәешендә урын алган, дөнья харитасында лаеклы урынын югалтуга китергән тискәре сыйфатларны да яшерми. *«Тигәнәктәй сатлыкларның үсеп торуы», «туганнарның туганнарга ук»* атуы, хәлиткеч мизгелләрдә бердәмлекнең җитешмәве милләтебезне шундый аяныч хәлгә китереп җиткергән. Халыкны һәлакәткә илткән иң яман чир итеп автор хыянәтне атый. Фикерен көн белән төн, яктылык белән караңгылык кисешкән яссылыкта очраштыру нияте белән шагыйрь афористик төгәллектә ике тарихи шәхесне янәшә куя:

«Мөхәммәд дәүләт торгызган,
Шаһгали дәүләт саткан».

Халык «ниләр генә күрми ир башы», дигәндә, Исхакый кебек олы йөрәкле, башбирмәс холыклы улларын күздә тоткандыр. Корыч та түзмәс авырлыкларны җибәрә язмыш Гаязга. Чистай, Казан төрмәләре, салкын кышлы Архангельск

[2] Мәхмүдов Ә. Инкыйразны тезгенләүче. – «Мирас» журналы. – №8, 2004.

сөргеннәре, аннан качулар, кеше фатирларында посып яшәүләр, совет хакимияте, Сталин, Берия иярченнәре тарафыннан эзәрлекләнүләр – барысы да Исхакый язмышына төшә; ул гомере буена диярлек үткен кылыч йөзеннән йөрергә мәҗбүр була.

Канатын канатсалар да, бөркетне кара көчләр сындыра, рухын җиңә алмыйлар. Исхакый большевиклар узаманы Ленинның акылдан язуын, Сталинның сәер үлемен, Гитлерның үз-үзенә кул салуын белеп үлә. Бирегә җәза һәм чистарыну (катарсис) мотивлары үзара бәйләнештә үстереләләр, ягъни гөнаһлылар үз җәзаларын күрәләр, ә Исхакый исә пәйгамбәр дәрәҗәсенә күтәрелә. Әлеге әхлакый-фәлсәфи катлам *«Халыкның гомерен даһилар озайтыр», «Гаяз фикере дә үлемсез»* кебек төгәл, үтемле юлларда ачыла. Хронотопның (вакыт белән ара бердәмлеге) иркен бирелеше каһарманның яшәү рәвеше, урыны белән бәйләнештә шәкел яңалыгына да уңай тәэсир итә. Татарны күтәргән, мактаган юллар беркадәр ясалма күренсә дә («Их, шулай булсачы!» – дисең), поэманың апофеозы күңелне иркәли:

«Пәйгамбәрләр иле –
Татарның иле дә,
Изгеләрнең теле –
Сөйләшкән теле дә».

Әмма мондый характердагы публицистик юллар артып киткәч (*«Татарда – сизгерлек, татарда – ис, акыл», «Исхакый – биектә, бөектер – җиңүче, залимнәр – түбәндә, залимнәр – бик аста»*), болай ук күпертү, хыял белән тормыш дөреслеген бутап, укучыны саташтыру кирәкмәс иде дигән фикер туа.

Ә.Мәхмүдов поэмасында публицистик хөкем көчлерәк булса, Р.Низами әсәрендә тасвирлау, хикәяләү компоненты өстенлек ала.

Исхакый бөеклеген аңлау һәм шәрехләү, сәяси-фәлсәфи уйланулар Г.Афзал, И.Юзеев, Зөлфәт, Ә.Баян, Р.Рахмани, А.Хәлим, Э.Шәрифуллина, Ф.Сафин, Л.Шагыйрьҗан, Ф.Тарханова, Ф.Мөслимова, Җ.Сөләйман, Г.Морат иҗатларында шактый тулы көчкә яңгырый. Аларга яңа буын әһелләренең тавышы өстәлә тора.

Халык әйтеменең мәгънәсен уйнатуга корылган «Тузга язылмаган сүзләр» шигырендә Газинур Морат Г.Исхакый образына яңача килә. Безне *«тузга язмаганны сөйләмә»,* дип яшьли алдашмаска, әдәпкә өйрәтергә тырыштылар, ди лирик герой. Ләкин мәгълүм елларда *«тузга язылганны яза-яза өйрәндек ич донос язарга»* дип, хыялында гына булса да, дөньяның эчке халәте үзгәрүгә, шикаятьләр чоры узуга ышанып, тузга язылмаган сүзләр эзләү юлына чыга. Автор үзенең рухи дөньясы, әхлакый эзләнүләре турында җанлы әңгәмәдәше белән гәпләшеп утыра, диярсең.

«Түрә, әнә, түргә элеп куйды:
«Син үзеңнән башла ислахны».
Тузга язмаганны сөйләр өчен
Кайтты, әнә, илгә Исхакый».

Исхакыйның фикри бөеклеген бер җөмлә – шигъри метафора ача да куя. *«Тузга язмаган»* берәмлегенә күп мәгънә сыйдырып була. Исхакыйның ни-нәрсә, нинди

сүзләр сөйләвен автор ачып бетерми, укучыга уйланырга, үзенә нәтиҗә ясарга урын калдыра.

Без аңа һаман бурычлы әле...

Исхакый образын, эшчәнлеген, иҗатын ачуга багышланган әсәрләр языла, басыла тора. Шул ук вакытта бөек шәхесебез наменә багышланган юлламаларның берьяклырак булуына, фикерләү тирәнлеге җитешмәвенә, шагыйрьләребезнең биографик детальләр, «Ике йөз елдан соң инкыйраз» даирәсендә генә калуына игътибар итми мөмкин түгел.

«Хәзерге шигърияттә Гаяз Исхакый рухы» исемле мәкаләсендә галимә Ф.Хәсәнова әдипкә багышланган тезмәләрнең эчтәлекләре, яңгырашлары бертөрлерәк булуларына дикъкать итә. *«Гаҗәп хәл: шагыйрьләр күбесенчә әдипне «Ике йөз елдан соң инкыйраз» әсәре фонында гына искә алалар. «Инкыйраз» термины шигырь исеме булярак та китерелә... Мөһаҗир язучы Исхакыйның башка күренекле әсәрләре, бигрәк тә татар менталитетына һәм заманга туры килә торган «Ул әле өйләнмәгән иде», «Өч хатын белән тормыш», «Җан Баевич» һ.б. әсәрләренең бөтенләй телгә алынмавы гаҗәп, әлбәттә»*[3]. Г.Исхакыйның барлык язганнарына атап шигырь иҗат итү ничаклы уңышлы булыр иде һәм ул кирәк тә микән? Иң мөһиме – Исхакыйга багышланган, аның исеме телгә алынган багышлауларда язучының милли рухы, өмете, ышанычы, фаҗигасе шигъри индивидуальлек аша ачылырга тиеш дип уйлыйм.

Бүгенге татар әдәбият белеме, тарихы һәм журналистикасы алдында торган бурычларның берсе – татар мөһаҗирләренең тормышын, эшчәнлеген, әдәби-гыйльми мирасын хәзерге көн күзлегеннән чыгып өйрәнү. Дөрес, И.Нуруллин, Р.Ганиева, Ф.Мусин, Ә.Сәхапов, А.Әхмәдуллин, Р.Рахман, Л.Гайнанова, тарихчылар – И.Таһиров, Р.Хәйретдинов һ.б. галимнәребез Г.Исхакый мирасын төрле яктан һәм шактый тирән тикшерделәр. Фәнни хезмәтләренең, монографик мәкаләләренең күләмен күз алдына китерү генә дә канәгатьләнү хисе калдыра.

Мөһаҗирлек хәрәкәтен, бигрәк тә аларның әдәби-шигъри мирасларын кайтару юнәлешендә армый-талмый эшләгән, чит илләрдә иҗат ителгән әсәрләрне «рухи мирасыбыз»[4], дип бәяләп, тәфсилләп өйрәнгән профессор Х.Миңнегулов бик хаклы искәрткәнчә, Г.Исхакый *«дистәләгән кешенең гомерен үзенә җыйган, алар өчен яшәгән, эшләгән кебек. Аның тереклегендәге һәр көн атнага, айга тиңләрлек. Язмыш төрле кыйтгаларга чәчкән татарларны «миллилек идеалы» тирәсендә туплауны үз өстенә алган Г.Исхакый төрки татарларның чын мәгънәсендә юлбашчысына әверелә»*[5].

Татар халкының олы тарихында, милли үзаңы үсешендә тирән эз калдырган, читят җирләрдә гомерләре өзелеп калган шәхесләребез образларын тирәнрәк яктырту, XXI гасырны аз санлы милләтләр өчен катлаулы вазгыять күзлегеннән чыгып бәяләү татар сүз сәнгате алдында торган изге бурычларның берсе дип уйлыйм. Өлкәннәргә һәрдаим ихтирам, хөрмәт белән яшәгән татар сүз сәнгатенең, милләтебез алдында торган башка мәнфәгатьләре белән беррәттән, бу олы йөкне дә үз җилкәсенә алырлык абруе да, куәсе дә җитәрлек. ■

---

[3] Исхакый иҗатына хәзерге караш. Гаяз Исхакыйның тууына 130 ел тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция. – Казан, 2008. – 200 б.

[4] Миңнегулов Х.Ю. Рухи мирасыбыз сәхифәләре. – Казан: «Халкыбыз мирасы» нәшрияты, 2022. – 480 б.

[5] Миңнегулов Х.Ю. Чит илләрдәге татар әдәбияты. – Казан: Мәгариф, 2007. – Б.24.

«Кыйссасел-әнбия» һәм төрки дөнья

Рәмил Исламов, филология фәннәре докторы


قصص الانبیاء
ربغوزی

قصص الانبیاده رباطا اوغوزی‌نینك قاضی‌سی برهان الدین اوغلی
ناصر الدین تصنیفی‌دور

قزان
١٢٩٩
سنه‌سنه

بو کتاب باصمه‌سنه رخصت بیرلدی ٨ نچی اوکتابر ١٨٨١ نچی یلده

بو کتاب قزان اونیوبرستیتی‌ننك طبع خانه‌سنده باصمه اولنمشدر
قزان اویازی توبان قورصا آولی‌ننك شمس الدین حسین اوغلی
ننك خراجتی ایلان ١٨٨١ نچی یلده بشنچی مرتبه

Рабгузи. «Кыйссасел-әнбия». 1881 ел

Әсәр кайчан язылган?

Пәйгамбәрләр турында һәм аларның тормышын тасвирлаган тарих китаплары гарәп һәм фарсы телләрендә урта гасырда күпләп язылган. Мәсәлән, шундый әсәрләрнең беренчесе Ваһһаб бине Мөнәббиһ исемле гыйлем иясенә нисбәт ителә.

XIV гасырның беренче яртысында Алтын Урда дәүләтенең Харәзем төбәгендә төрки телдә «Кыйссасел-әнбия» («Пәйгамбәрләр тарихы») барлыкка килә. Ул, нигездә, чәчмә әсәр булса да, текстта урыны-урыны белән шигырьләр дә китерелә. Аның авторы турында тулы мәгълүмат юк. Бары кереш өлештә генә теркәлгән зур булмаган белешмәдән күренгәнчә, әлеге эшне Рабат Угызы дигән шәһәрнең казые Борһанеддин угылы Насыйреддин башкарган һәм Насыйреддин Тукбога исемле бәккә багышлаган.

Ядкярнең ахырында шигырь юллары белән бәян ителгәнчә, әсәр 710, ягъни миляди 1310 елда тәгәлләнгән. Урта Азия белгече, фольклорчы һәм һәвәскәр археолог Әбубәкер Диваев, нишләптер, аны 1404 елда язылган дип белдерә.

1913 елда Казан университетында алтын медальгә тәкъдим ителгән эшләр арасында тарих-филология факультеты студенты А.В.Ерофеевның «Соломон патша турында мөселман риваятьләре» дигән хезмәте дә бар. Профессор Н.Ф.Катановның аңа язган бәяләмәсеннән күренгәнчә, дәгъва авторы «Кыйссасел-әнбия»не XVIII гасырның азагында башкарылган дип белдерә һәм, бернинди аңлатмасыз, күрсәтелгән вакытны икърар итә.

«Бәгъзе әйтер»: автор төрле чыганаклардан файдалана

«Кыйссасел-әнбия»нең текстында автор үзенең хезмәтен язганда бик күп чыганаклардан файданганлыгын белдерә. Бу хакта ул еш кына «риваять килмеш», «хикәядә андаг килмеш», «риваять кыйлурлар», «риваятьдә килмеш», «хәбәрдә килер», «әйтмешләр», «бәгъзе әйтер», «бер кыйсса китабында күрдем» һ.б. дип яза һәм кайбер исемнәрне дә күрсәтә. Алар арасында, мәсәлән, Әбубәкер Сыйддыйк, Гомәр әл-Фарук, Госман Зиннурайн, Гали әл-Мортаза, Гайшә (Гайшә әс-Сыйддыйка бинте Әбубәкер әс-Сыйддыйк), Өммеһани бинте Әбуталиб, Өммегөлсем бинте рәсүл, Ваһһаб бине Мөнәббиһ һ.б. күренеклеләр бар. Ул шулай ук Коръәннән аятьләр китереп, үзенең фикерләрен дәлилли, «Жарелбәйан» дигән һәм төзүчеләре билгесез тәфсирләргә дә сылтамалар ясый.

Профессор Габдерахман Таһирҗанов билгеләгәнчә, төрки

> **«Әсәрнең Париж, Лондон һәм башка чит ил китапханәләрендә саклана торган борынгы кульязмаларының күчерелмәләрен Казанга алдырып, безнең җирлектә табылган нөсхәләре белән чагыштырып, тулы академик басмасын киң җәмәгатьчелеккә җиткерү татар әдәбиятының мөһим һәм якын арада хәл ителергә тиешле мәсьәләләренең берсе булып тора.**

каләм иясе эш барышында Фирдәүсинең «Йосыф вә Зөләйха» поэмасына да мөрәҗәгать иткән.

Борынгы нөсхәләре Лондон һәм Парижда да саклана

«Кыйссасел-әнбия» күчермәләренең борынгырак саналган бер нөсхәсе хәзерге вакытта Лондондагы Британия музеенда саклана. Кульязманың үзендә язылу вакыты күрсәтелмәсә дә, Ч.Рье аны XV гасырга нисбәт итә. Профессор В.Р.Розен танылган галимнең әлеге билгеләмәсе белән, һичшиксез, килешергә мөмкин икәнлеген яза.

Әсәрнең кайбер башка күчермәләре Париж Милли китапханәсендә, Россия Фәннәр академиясе Көнчыгышны өйрәнү институтының Санкт-Петербург бүлегендә, Үзбәкстан Фәннәр академиясенең кульязмалар, Росиия Фәннәр академиясе Уфа тикшеренү үзәгенең Тел, тарих һәм әдәбият институты фондында бар.

Әсәр Казандагы басмаханәләрдә ун тапкыр нәшер ителә

Рабгузиның әсәре типография ысулы белән беренче тапкыр 1859 елда Казанда нәшер ителә. Дөрес, әлеге басмада бернинди шәрехләр, аңлатмалар бирелмәгән. Аның нинди кульязмаларга нигезләнеп төзелүе дә мәгълүм түгел. Шулай да П.М.Мелиоранский бу китап өчен Азия музеенда 361 сан белән саклана торган кульязманың файдаланылган булу ихтималын белдерә.

Әсәр 1915 елга кадәр Казандагы басмаханәләрдә ун тапкыр нәшер ителә. Шунысын да билгеләп үтү зарур: ядкяр төрле, аерым алганда, «Кыйссаи Рабгузи», «Кыйссасел-әнбия Рабгузи», «Кыйссасел-әнбия галәйһемес-сәлам», «Кыйссасел-әнбия» кебек атамалар белән дөнья күрә.

«Кыйссасел-әнбия»нең өйрәнелү тарихы төрле чорларда төрле галимнәрнең исемнәре белән бәйле. Н.П.Остроумов Казандагы Рухани академиянең Мөселманлыкка каршы миссионерлык бүлегендә укыганда ислам динендә пәйгамбәрләр турындагы өйрәтмәләргә багышлап хезмәт яза. Моның өчен ул Рабгузи әсәренә мөрәҗәгать итә.

Танылган тюрколог В.В.Радлов 1893-1911 нче елларда дүрт том күләмендә төрки шивәләр сүзлеген төзеп бастыра. Ул үзенең әлеге бибәһа хезмәтендә, башка чыганаклар белән бергә, «Кыйссасел-әнбия»нең лексикасыннан да киң файдалана. Шулай ук Л.З.Будагов тарафыннан әзерләнеп, 1869-1871 нче елларда нәшер ителгән ике томлык «Төрки-татар шивәләренең чагыштырма сүзлеге» өчен дә әлеге әсәргә еш мөрәҗәгать ителгәнлеге ачыклана.

Мәгълүм ки, Коръәндә «Әсхабе кәһәф» дигән сүрә бар. Шәрыкта һәм Көнбатышта бу сюжетка нигезләнгән шактый риваятьләр таралган. Италия галиме И.Гвиди әлеге мәсьәләне өйрәнүгә махсус хезмәт тә багышлый. Аның татарларда булган вариантын Н.Ф.Катанов Кытайга гыйльми сәфәре вакытында 1891 елда Чүгүчәктәге Мөҗиб ахуннан язып ала һәм «Кыйссасел-әнбия»дәге шул ук текст белән чагыштырып, кызыклы гына нәтиҗәләр ясый. Галим әлеге сәфәрендә янә Яхъя, Зәкәрия, Гайсә, Мәрьям турындагы төрки чыганаклар табып ала. Ул аларны тикшергәндә Коръәндәге һәм Рабгузи әсәрендәге аларга нисбәтле мәгълүматка мөрәҗәгать итә. Сөләйман турында Азиядә табылган риваятьләрне «Кыйссасел-әнбия» белән чагыштырып анализлау да – галимнең нәтиҗәле эшчәнлеге.

Нәсретдин бине Борһанетдин Рабгузи. «Кыйссасел-әнбия». Кулъязма. XIX гасыр ахыры. ***Китап Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә саклана.***

П.М.Мелиоранский «Кыйссасел-әнбия»нең Лондонда саклана торган күчермәсендәге Салих пәйгамбәр (г.с.) турындагы өлешен ул вакыттагы Азия музеенда, Император җәмәгать китапханәсендәге кульъязмаларда һәм Н.Ильминский нәшер иткән китаптагы шул ук бүлекләр белән чагыштырып өйрәнә. Галим Лондон нөсхәсеннән янә Исмәгыйльне корбанга китерү, Кәгъба төзелеше һәм Исхакның балалары турындагы өлешләрнең дә күчермәсен алдырган булган. Ләкин ул матбугатка яңа хезмәтен әзерләп өлгерми кала. С.Е.Малов соңыннан аларны Азия музеендагы һәм башка нөсхәләрдәге шул ук вариантлары белән чагыштырып, аны рус теленә өлешчә тәрҗемәсе белән бастырып чыгара.

С.Е.Малов янә борынгы төрки язма истәлекләр турындагы үзенең икенче бер хезмәтендә дә «Кыйссасел-әнбия»гә урын бирә. Анда Н.Ильминский нөсхәсе нигезендә әсәрнең авторы һәм аның китабы, Лут пәйгамбәр (г.с.) хакында, китапның бетем өлешеннән өзекләр китерә. Ул шулай ук әлеге текстларның русча тәрҗемәләрен дә урнаштыра.

«Кыйссасел-әнбия»нең тел үзенчәлекләре турында сүз йөртеп, Н.Ильминский әлеге ядкяр белән «Котадгу белек» телләренең якынлыгын билдерә. В.Р.Розен да Рабгузи әсәренең Йосыф Баласагуни поэмасының теленә ачкыч булуын билгели. Гали Рәхим әсәрнең борынгы, ягъни XV гасырга кадәр булган чыгтай телендә язылганлыгын әйтә.

С.Е.Малов тексттагы лексик материалның Көнчыгыш төрки характерда булганлыгын билгеләп үтә һәм бу әсәрнең Караханилар дәвере әдәбиятына якын икәнлеген күрсәтә дигән нәтиҗә ясый. Тюрколог Әмир Нәҗипнең дә фикере шундый. Ул үзенең бер мәкаләсендә Рабгузи әсәрен өйрәнүгә багышлаган махсус хезмәтен нәшер итәргә әзерләве турында яза, ләкин ул басманың күренгәне юк.

Татар халкы иң яратып укыган әсәрләрнең берсе

Рабгузи әсәре электә татарлар арасында киң таралган һәм яратып укылган китапларның берсе була. Ул мәдрәсәләрдә уку әсбабы сыйфатында да файдаланыла һәм аның атамасы «Кыйссасел-әнбия» буларак таралыш ала. Археографик экспедицияләр вакытында табылган күчермәләр әсәрнең популярлыгына ачык дәлил. Пәйгамбәрләр тарихының шулай ук 1917 елга кадәр һәм аннан соң да, нигездә, шушы әсәргә таянып язылган төрле атамада, төрле күләмдә типография ысулы белән нәшер ителү фактлары да шул турыда сөйли.

Кызганыч ки, Гали Рәхим хезмәтеннән соң, «Кыйссасел-әнбия» татар әдәбияты тарихында да, тел гыйлемендә дә берникадәр вакыт бөтенләй дип әйтерлек өйрәнелми. 1963 елда дөнья күргән «Борынгы татар әдәбияты» дигән күмәк хезмәттә ул бер җөмлә белән генә искә алына. Дөрес, күптомлы «Татар әдәбияты тарихы»ның 1984 елда нәшер ителгән беренче томында әсәргә игътибар чагыштырмача арта төшә, ә сигез томлы «Татар әдәбияты тарихы»ның беренче томында (2014) исә аңа шактый күләмле очерк багышлана. Әдәбиятчы Мәсгут Гайнетдинов тексттагы Йосыф хакындагы кыйссадан «Бәһарият» («Яз») дигән газәлне һәм бер дүртьюллык шигырьне «Татар поэзиясе антологиясе»нең беренче томында бастыра. Борынгы татар әдәбияты белгече Нәҗип Исмәгыйлев вакытлы матбугат битләрендә укучыларны әсәрдәге Адәм галәйһиссәлам турындагы кыйсса белән таныштыра.

Әлфия Хәлиуллина тарафыннан әсәр текстының графо-фонетик һәм морфологик үзенчәлекләрен тикшерүгә багышланган кандидатлык диссертациясе яклана.

«Кыйссасел-әнбия» – төрки халыкларда

«Кыйссасел-әнбия»не өйрәнү торышы башка төрки халыкларда да төрлечә. «Башкорт әдәбияты тарихы»ның беренче томында ул берничә тапкыр гына телгә алына.

Рабгузи әсәре 1895 елда Ташкентта бертуган Каменскийлар тарафыннан литография ысулы белән нәшер ителә. Соңыннан ул Голям Хәсән Гарифҗанның басмаханәсендә дөнья күрә. Шулай ук аның башка басмалары да билгеле.

Үзбәк әдәбиятчысы Фитрәт (Габдерәүф Габдерәхим улы. – *Р.И.*) үзенең «Үзбәк әдәбиятының нәмүнәләре» дип аталган хезмәтенең 1928 елда басылып чыккан беренче китабында Рабгузи әсәренең Йосыф турындагы өлешен урнаштыра. Үз вакытында аның белән танышкан С.Е.Малов әлеге нөсхәнең фәнни әһәмияткә ия булганлыгын белдерә. М.Бозрук үзбәк әдәбиятына гомуми планда анализ ясаган бер хезмәтендә «Кыйссасел-әнбия»гә дә урын бирә.

Әсәр хәзерге вакытта да үзбәк филологларының игътибар үзәгендә. Мәсәлән, С.Хәйдәров үзенең кандидатлык диссертациясендә әсәрнең текстында дөньяви мәсьәләләргә бәйле элементларның да мәгълүм дәрәҗәдә урын алып торуларын раслый. Ядкярнең тел үзенчәлекләрен өйрәнүгә Ү.Мирзакәримова, Б.Абдушөкеров, әдәби яктан тикшерүгә И.Останакулов мәгълүм дәрәҗәдә өлеш кертә.

Биш томлы «Үзбәк әдәбияты тарихы»ның беренче томында Рабгузига һәм аның иҗатына тиешле урын бирелә. «Кыйссасел-әнбия» үзбәк телендә ике том булып басылып чыга.

Казакъ әдәбиятчысы М.Юлдашбәков борынгы төрки язма истәлекләр һәм аларның казакъ әдәбиятына мөнәсәбәтен өйрәнүгә багышланган хезмәтендә рухи мирасның бары тик шигырь белән генә иҗат ителмәгәнлегенә, чәчмә ысул белән дә язылганнары барлыгына басым ясап, мисалга «Кыйссасел-әнбия» әсәрен китерә.

2001-2006 нчы елларда «Кыйссасел-әнбия» Алматыда казакъ телендә нәшер ителә. А.Кыраубаева тарафыннан «Кыйссасел-әнбия»нең идея-сәнгатьчел үзенчәлекләрен тикшерүгә багышланган диссертация яклана.

Әзәрбайҗан филологиясендә «Кыйссасел-әнбия»нең кульъязма нөсхәләре, лексик-семантик һәм синтаксик хосусиятләре турында Н.Н.Хаҗиева тарафыннан ике кисәктән гыйбарәт хезмәт бастырыла.

***

«Кыйссасел-әнбия» – әдәбият һәм тел тарихын өйрәнү өчен дә, урта гасыр төрки-гарәп, төрки-фарсы әдәби һәм фәлсәфи бәйләнешләрен тикшерүдә дә әһәмиятле чыганак. Әсәрнең Париж, Лондон һәм башка чит ил китапханәләрендә саклана торган борынгы кульъязмаларының күчерелмәләрен Казанга алдырып, безнең җирлектә табылган нөсхәләре белән чагыштырып, тулы академик басмасын киң җәмәгатьчелеккә җиткерү татар әдәбиятының мөһим һәм якын арада хәл ителергә тиешле мәсьәләләренең берсе булып тора. ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2022

Хаҗ сәфәре

Ләбиб Лерон

Ният иттем изге юлга чыкмакка...

Әйдә, халыкка хезмәткә,
Хезмәт эчендә йөз Мәккә.
Габдулла Тукай

Бисмилләәһир рахмәәнир рахиим.

«Буниял-исләәмү галәә хамсин: шәһәдәтү ән-ләә иләәһә илләллаһү вә әннә Мүхәммәдәр-расүллуллааһи вә икаамис-саләәти вә иитәә'из-зәкәәти вә сауми рамадаанә вә хәҗҗил-бәйти мәни-стәтаагә иләйһи сәбииләә (Мәгънәсе: «Ислам дине биш терәккә нигезләнгән: Аллаһы Тәгаләнең берлегенә һәм Мөхәммәд салләллаһу галәйһи вәсәлламнең Аның пәйгамбәре булуына күңелдән гуаһлык итү, намаз уку, малдан зякәт бирү, Рамазан аенда ураза тоту һәм мөмкинлеге булган кешегә, Кәгъбәтуллаһны зиярәт итеп, хаҗ кылу».)

Ислам динендә балигъ һәм акылы булган мөэмин кешегә фарыз булган олуг гыйбадәтләрнең бишенчесе – гомерендә бер мәртәбә Мәккәи Мөкәррәмәгә барып, хаҗ гамәлен кылу.

Әлеге өземтәне мәшһүребез – татар мөгаллиме, галим, җәмәгать эшлеклесе, журналист һәм нашир **Әхмәдһади Максуди**ның (1868-1941) «Гыйбадәте исламия» китабыннан (Казан: «Хозур-Тынычлык» нәшрият йорты, 2021) алдым. Бер ай чамасы элек кенә хаҗ сәфәреннән кайткан «белемсез хаҗи» буларак (Ә.Максуди әйтә: *«Хаҗиларга, Мәдинәи Мөнәвәрәгә барып, пәйгамбәребез Мөхәммәд салләлләһү галәйһи вәсәлламнең шәрифле кабере булган Рәүзаи Мотаһһәрәне зиярәт кылу – олы мөстәхәб. Мәккәи Мөкәррәмәдә дә, Мәдинәи Мөнәвәрәдә дә зиярәт кыла торган җирләр һәм мөбәрак урыннар бик күп. Аларны зиярәт иткәндә игътибарга алырга кирәк булган махсус кагыйдәләр дә бар. Алда әйтелгән ике шәһәрнең һәрберсендә хаҗиларга хаҗ гамәлләрен өйрәтүче һәм зиярәт иткәндә игътибарга алырга кирәк булган махсус кагыйдәләр бар. Белемсез хаҗилар үзләре белмәгән гамәлләрне әйтелгән дәлилләрдән өйрәнергә тиеш»,* – ди), алга таба әле өйрәнәсе дә өйрәнәсе, дип, хатирәләргә бирелеп йөргән мәлләрем...

...Очкыч Истанбулдан Казан аэропортына төшеп күпмедер вакыт үтүгә, чыгу юлында безне «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгы журналистлары каршы алды. Аларның беренче соравы: «Хаҗдан нинди хисләр белән кайттыгыз?» – булса, икенчесе: «Хаҗга бару теләге Сездә кайчан уянды?» – иде.

Беренче сорауга әйткән җавабымны язмамның киләсе өлешендә тәфсилләрмен, икенче сорауга килсәк, аңа җавабым кыска булды:

– Өч ел элек...

Хәзер уйланып утырам: өч кенә ел элек түгелдер, юк, хаҗга бару уй-ниятенә тагы да алданрак килгәнмендер кебек... Ул, бәлки, ният тә булмагандыр әле, үзем дә белмәгән-аңламаган көе, шуңа әкренләп әзерләнгәнмендер генә... Халык шагыйре Рөстәм Мингалим (1937-2014) әйтмешли: «Ул шулайдыр әле, уйласаң...»

Елларны артка чигерә-чигерә, хәтерне яңартам...

Өч яшь (әллә биш яшьме?..) тулганда миңа «кызыл ыштан» кидерделәр, ягъни сөннәткә утырттылар – балачак хатирәләремнең чишмә башы нәкъ менә шуннан юл ала сыман.

...Табын янына утырган саен әннәм (әнием) Шәргыянең кисәтүле сүзләре яңгырый:

– Аякларыңны селкеп утырма, шайтан чакырасың!

Мин әле шайтанның кем-ни икәнен белмим, әмма явыз, әшәке булырга тиешлеген чамалыйм, шуңа күрә аякларымны селкемәскә – шайтан чакырмаска тырышам. Ләкин аякларым гына тыңламый шул – һаман селкенәселәре килә...

Әнкәй дә (әннәмнең әнисе – Мөфәккирә) һәрдаим үзенекен тукып тора:

– Бисмилләңны әйттеңме?!

– Амин тотарга онытмадыңмы?

– Йәле, «әлпитиси»еңне кабатла!

Мин әнкәйгә кушылып кабатлыйм:

– Әлеф, би, ти, си, җөм, хи...

...Берничә көн элек кенә туган энекәшемә (әннәмнең энесе Рөстәмнең улы) исем куйган чак. Мулла абзый (безгә чапрыш күрше Җәмил бабай булмадымы икән?..) кыйблага каратып мендәргә яткырылган сабыйның уң колагына ярымпышылдап «Аллаһу әкбәр»ләп азан әйтә дә, ахырдан:

– Исемең Миңлерөстәм улы Миңлефирдәвис булыр! – ди.

...Университетта укыганда безгә чит телләр керде. Кемдер – немец, кемдер – француз телен, мин исә гарәп телен сайладым. Бер ай үтәр-үтмәстән, кайберләребез өйләренә хатны гарәп имлясында гына «сырлый» башлады. Безнең төркемне гарәп теле белгече Лена Кәлимулла кызы Таҗиева укытты. Аңа чиксез рәхмәтлемен!

...«Синең артыңнан догачы калырга тиеш!» – Кем әйтте миңа моны, кайчан һәм кемнән ишеттем (яисә укыдым) бу сүзләрне?!.

Минем ике бабам да сугыштан кайтмады. Әүхәди бабамның (әннәмнең әтисе) җәсәде – Бөек Новгород өлкәсендәге Старое Руссо шәһәреннән әллә ни ерак булмаган Борки дигән авылның Туганнар каберлегендә. Хөҗҗәт бабамның кабере әле дә билгесез. Әбиләрем Мөфәккирә белән Хәмдия дә күптән вафат инде: берсе – Актаныш районының Олы Имән авылындагы «бакый йорты»нда, икенчесе – Мөслим районындагы Түреш авылы зиратында мәңгелек йокыда. Әнием Шәргыяның вафатына да унбер ел булды. Аларга кемдер (ягъни мин фәкыйрегез) догачы булырга тиештер бит инде! Ә безгә, бездән соңгыларга кемнәр догачы булыр?!.

Догачы, дигәннән... Бу хакта «Туган авылым» комплексы мәчетенең имамхатыйбы **Нурулла хәзрәт Зиннәтуллин** «Шәһри Казан» газетасы хәбәрчесенә биргән интервьюсында болай дигән иде: *«Әрвахлар безнең догага мохтаҗ. Адәм баласы вафат булганнан соң, аның дөньялыктагы бөтен гамәле киселә, ошбу гамәлләре генә аңа әҗер-савап булып барып тора: халык файдаланырлык итеп таратып калдырган гыйлеме, догачы баласы һәм җария садакасы. Һәр кеше исән чагында: «Үлгәннән соң миңа нинди дивиденд килеп торыр икән?» – дип уйланырга тиеш. Кызганыч, күпләр үлгәннән соңгы тормышы турында кайгыртмый. Югыйсә иң яхшы дивиденды – аның дога кылучы иманлы баласы. Синең өчен дустың да, күршең дә дога кыла, әмма алар сине гел истә тотмаска да мөмкин. Ә догачы балаң беркайчан онытмый».*

وَإِذَا سَأَلَكَ عِبَادِي عَنِّي فَإِنِّي قَرِيبٌ أُجِيبُ دَعْوَةَ الدَّاعِ
إِذَا دَعَانِ فَلْيَسْتَجِيبُوا لِي وَلْيُؤْمِنُوا بِي لَعَلَّهُمْ يَرْشُدُونَ

«Әгәр синнән Минем *(Аллаһ)* хакта сорасалар, әйт аларга: «Дөреслектә Мин *(Аллаһ)* якынмын. Догачы миннән дога кылып сораса, Мин аңа, һичшиксез, җавап бирермен. Әмма сораучылар үземә һәм сүземә ныклап ышансыннар һәм Миңа буйсынып, Коръән белән гамәл кылсыннар! Әгәр Мин әйткәнчә эш кылсалар, шаять, туры юлны табарлар», – дип». *(«Әл-Бәкара» сүрәсе, 186 аять.)*

...2013 ел ахырында «Безнең мирас» журналы редакциясенә эшкә килдем – баш мөхәррир вазыйфасына керештем. Басмабызда, «Тарихи мирас», «Әдәби мирас» һәм «Сәнгати мирас» белән бергә, «Дини мирас» сәхифәсе дә пәйда булды. Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсенең ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин белән танышып, аның белән уртак проектлар башлап җибәрдек. Хәзрәтләр белән аралашу даирәсе киңәйгәннән-киңәя барды. Журналда Татарстан Дингия нәзарәтенең рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм Россия Диния нәзарәте рәисе,

мөфти шәех Равил хәзрәт Гайнетдин белән әңгәмә-язмалар, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев һәм Уфадагы «Ихлас» мәчете имам-хатыйбы Мөхәммәт Галләмнең вәгазьләре урын ала килә, әлеге күренекле авторлар белән күрешү-очрашулар да еш булып тора.

...Бер елны (2007 елда булса кирәк) бер төркем сәнгать әһелләре (Наил Шәйхетдинов, Айдар Хафизов, Исламия Мәхмүтова, Хәлил Мәхмүтов, Идрис Мәсгутов, Юныс Сафиуллин) хаҗга барып кайтты. Матбугатта ихрам киеменнән төшкән фотосурәтләре басылып чыкты. Шулай ук Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Әзһәр Шакиров, язучылар – Рабит Батулла, Тәлгат Галиуллин, Фәүзия Бәйрәмова, Фәйрүзә Мөслимова, Гөлзадә Бәйрәмова, Рифат Сәлах, журналистлар – Шәех Зәбиров, Тәүфыйк Сәгыйтов, Ислам Әхмәтҗанов, Фәния Хуҗиәхмәтова, Рәшит Минһаҗ, Шамил Садыйков, Данил Сәфәров та хаҗ кылып кайтты дип беләм. Соңыннан Тәлгат Галиуллин һәм Фәүзия Бәйрәмованың «Хаҗга зиярәт шәхси эшме?» һәм «Хаҗ көндәлеге» дигән язмалары матбугатта басылып чыкты. Үземнең дә бик барасым килеп, чын-чынлап кызыккан идем аларга...

Өч ел элек ниятем максатка әйләнә башлады, дигән идем. «Таҗлы зәхмәт» арага кермәсә, бәлкем, хаҗ сәфәренә алданрак бару насыйп әйләгән булыр иде. Хәер, барысы да Аллаһ ихтыярында...

«Әйдә, халыкка хезмәткә,
Хезмәт эчендә йөзмәккә!»

Сөекле шагыйребез Тукайның «Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?» шигырендәге әлеге юлларны күпләр хәтерендә тотадыр дип беләм. Бәләкәй чагында, шушы шигъри юлларны укыгач: «Ничек итеп хезмәт эчендә йөзеп була икән?» – дип уйлап куйган идем. Бактың исә, шигырьне икенче төрле дә аңлап була икән бит. Бары тик «дөресләп» кенә язасы:

«Әйдә, халыкка хезмәткә,
Хезмәт эчендә йөз Мәккә!»

«Хезмәт эчендә йөз Мәккә» – бу ни дигән сүз? Бу – газиз халкың, милләтең өчен хезмәт итсәң, савабы йөз мәртәбә Мәккәгә хаҗга барып кайткан кебек булыр, дигән сүз. Әлеге шигъри юлларның Тукай тарафыннан нәкъ шулай язылган булырга тиешлеген безгә мәрхүм шагыйребез Нияз Акмал әйтеп-аңлатып калдырды. Хәер, Тукай шулай язганмы-юкмы – хикмәт анда түгел. Хикмәт – «Хезмәт эчендә йөз Мәккә»дә!

2018 елның 4 гыйнварында, үземнең киләчәгемне фаразлап, шушы дүртьюллыкны язган идем:

Якты итеп, матур итеп
Киләчәкне күрәм:
Уң кулымда каләм минем,
Ә алдымда – Коръән...

Дәвамы бар ■

Истә, һаман да истә!

Актер Шакир Шамильскийның тууына 130 ел

Актер, режиссер, ТАССРның атказанган артисты (1945) Шакир Габделгани улы Шамильский (Вахитов) 1892 елның 10 сентябрендә Казан губернасының Лаеш кантонындагы (хәзерге Алексеевск районы) Юеш Көрнәле авылында туган.

1909 елда ул «Сәйяр» труппасы спектаклендә (Пермь) катнаша. 1912 елдан «Нур» труппасында – һөнәри артист, соңрак спектакльләр дә куя.

1918-1920 нче елларда Шакир Шамильский Идел буе, Урал, Себер шәһәрләрендә төрле труппаларда (Буа театры, Урал татар эшче театры һ.б.) эшли. 1921-1922 нче елларда ул – Казанда Татар академия театрында, 1922-1923 нче елларда – Уфада Татар-башкорт театрында, 1924-1928 нче елларда – Казанда Татар академия театрында артист, режиссер һәм баш режиссер, 1931-1935 нче елларда – Казан һәм Әстерхан татар театрында артист һәм режиссер.

1940 елдан Татар академия театрында эшли.

Ш.Шамильский 1945 елда вафат булды.

Актер Касыйм Шамилнең тууына 130 ел

Актер, режиссер, педагог, ТАССРның халык артисты (1940) Касыйм Шамил (Касыйм Шамил улы Шамилов) 1892 елның 11 сентябрендә Әлмәт авылында туган.

1909 елда ул «Сәйяр» труппасында эшли башлый, 1913 елда «Нур» труппасына күчә.

1920 нче еллар башыннан Касыйм Шамил «Бишбалта», «Елга аръягы», Татар яшьләре театрында артист һәм режиссер була. Татар театр техникумында укыта. Мамадышта «Сабанчы» труппасын җитәкли, Уфада, аннары Казанда Татар академия театрында эшли. 1920 нче еллар ахырыннан 1933 елга кадәр ул – Әстерхан татар театрының баш режиссеры, 1933-1934 нче елларда – Казан татар яшьләр театрының баш режиссеры. 1934 елдан – Камал театрында.

Касыйм Шамил 1981 елда Казанда вафат булды.

Тарихчы-галим Сәвия Михайлованың туууына 80 ел

Тарихчы, тарих фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасы ФАнең «Рухи культура һәм гуманитар белемнәрнең үсеше» дигән фәнни Советының рәисе, 1994 елдан Халыкара Төрки академиянең академигы Сәвия Мөхәммәтдин кызы Михайлова 1942 елның 21 сентябрендә Саба районының Туктамыш авылында туган.

Ул Көнчыгыш, Европа һәм Себер төрки халыкларының тарихын, аларның рухи һәм сәяси культуралары формаларын, Шәрык дөньясын һәм Россия Көнчыгыш халыкларының мәгърифәтчелек үзенчәлеге мәсьәләләрен, хәзерге заманда милләтара мөнәсәбәтләр һәм милли мәдәниятләрнең узара бәйләнышлары проблемаларын өйрәнә.

Сәвия Михайлова тарафыннан 150дән артык фәнни хезмәт иҗат ителгән.

Ул 2007 елда вафат булды. Казан шәһәренең Юдино зиратында җирләнде.

Актриса Гәүһәр Камалованың тууына 100 ел

Актриса, ТАССРның халык (1976), РСФСРның атказанган артисты (1983) Гәүһәр Габдулла кызы Камалова 1922 елның 29 сентябрендә Төркестан АССРның Сырдәрья өлкәсендәге Ташкент шәһәрендә (хәзерге Үзбәкстан башкаласында) туган. Әтисе – актер һәм режиссер Габдулла Камал (1893-1933), әнисе – РСФСРның атказанган артисткасы Фатыйма Камалова (1903-1974).

1949 елда ул Г.Камалова Мәскәүдә Дәүләт театр сәнгате институты каршындагы Татар театр студиясен тәмамлый. 1949-1950 нче елларда – Казан яшь тамашачы театрының татар төркеме артисты булып эшли, 1950 елдан исә Татар академия театрында уйный.

Уйнаган рольләре: Кунакай («Козы көрпеш һәм Баянсылу», Г.Мөсрәпов), Гайнавал, Ханзафа («Ташкыннар», Т.Гыйззәт), Мәргидә («Хөррият», М.Әмир), Камилә («Беренче мәхәббәт», Х.Вахит), Зөләйха («Әни килде», Ш.Хөсәенов), Гашия («Иргетләр», Т.Миңнуллин), Хәят («Мәхәббәтең чын булса», Х.Вахит), Диакониса («Сукыр», Э.Альт), Фәүзия («Әнә килә автомобиль», Ф.Яруллин), Гөлбану («Назлы кияү», К.Тинчурин), Камилә («Кыз урлау», М.Кәрим).

Гәүһәр Камалова 1990 елның 6 апрелендә Татарстанның Казан шәһәрендә вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Илһам абый

Фәрдия Сәфәргалиева, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

20 май, 1999 ел. «Әниегез исәнме?»

Ульяновскидагы Ленин мемориалының Зур залында Татарстан Республикасы халык уен кораллары дәүләт оркестрының концерты булды. Солистлар – җырчылар Илһам Шакиров, Айдар Фәйзрахманов, Резидә Галимова, Рөстәм Маликов һәм халык уен коралларында уйнаучы Виктор Киреев, Ольга Вайспекер, Гүзәл Мөхәммәтдинова. Концертның алып баручысы мин идем.

Булачак концерт турында өлкәнең «Өмет» (1 май, 1999 ел) газетасында «Илһам Шакиров килә» дип белдерү биргәндә мине дә искә алганнар иде: *«Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Илһам Шакировны күрү бәхетенә ирешербез. Татарстанның халык артистлары Айдар Фәйзрахманов белән Рөстәм Маликовны да сагынып өлгергәннәрдер инде тамашачыларыбыз. Әлеге сандугачларның күптәннән безнең якларда булганнары юк иде. Концертны алып баручы Фәрдия Сәфәргалиева шулай ук күпләргә таныш, чөнки ул хезмәт юлын Сембердә башлап җибәрде, хәзер исә Казанда уңышлы гына эшли».* Анда яшәгәндә «Сембер җыры» конкурсларының гала-концертларын алып барган идем шул.

...Концерт гөрли, сәхнәдә Айдар энемнең җырлаган чагы. Мин сәхнә артында киләсе чыгышны игълан итәргә әзерләнеп, шигырь юлларын шыпырт кына кабатлыйм. Янәшәмдә Илһам абый басып тора икән: *«Үзеңнекеме?»* – дип сорап куйды ул шигырь турында. Кызык өчен генә сорагандыр, «Сәйдәш» поэмасын укымый калмагандыр, әлбәттә. *«Юк, Равил Фәйзуллинныкы»,* – дидем мин, тагын шигырь юлларын кабатлый-кабатлый:

«Халыкларның җаны ул – җыр, диләр,
Җыр, диләр дә, бездә – моң, диләр.
Телгәләсә, киссә бәгырьләрне,
Татар җыры инде шул, диләр».

«Әниегез исәнме?» – дип сорап куйды Илһам абый бераздан. *«Юк шул, Илһам абый... Былтыр май аенда җирләдек, 83 яше тулар алдыннан вафат булды...»* – дидем. Илһам абый, нindидер дога укып, тынып калды. Башка сөйләшү булмады, миңа сәхнәгә чыгарга кирәк иде.

Концерт матур узды. Зал тулы тамашачы бик җылы кабул итте безне.

Илһам абыйның сәхнә артында әниебез турында сорау бирүенең сәбәбен соңыннан да аңларга тырышып карадым. Аның үз әнисенә җылы караштa, рәхмәтле, ихтирамлы булуын, «Казанның кайсы җиреннән телисең, шуннан фатир бирәбез», – дигәч тә, тору урынын сайлап йөргәндә, әнисе күрсәткән йорттан фатир алганын беләидем. Алай гына да түгел, барлык әниләр турында уйлануы турында да.

Ахыры. Башы журналның 8 нче (2022) санында.

«Әниемә хат» җырын җырлавым да очраклы гына булмады. Җырны башкарганда мин үз анамны гына күз алдымда тотмадым. Бөтен аналарга да үз улларының хисләрен, үз улларының сәламнәрен ишеттерәсем килә иде», – дип язган Илһам Шакиров җыр тарихы турында («Татарстан яшьләре», 1959 ел, ноябрь).

Бәлки, әнисе Нуриәсма апаның концертларына килеп йөргән елларда шатланып, горурланып яшәвен исенә төшергәндер… Безнең әниебез дә, исән чагында, Айдар энемнең концертларын карап, «күкләргә менгәндәй» шатлана иде.

15 ноябрь, 1999 ел. «Картлыктыр инде...»

Илһам абый белән сөйләшеп алдым, иртәнге планеркадан соң булды бу. 22 ноябрьдә Хәмдүнә Тимергалиеваның иҗат кичәсе булырга тиеш иде. Мин анда алып баручыларның берсе һәм кичәнең режиссеры. Шул кичәне уздыру турында сөйләштек. *«Бу көннәрдә авырдым әле,* – диде Илһам абый, – *бер атна авырып алдым... Әлмәткә концерт белән барырга чыккан идек, күз ачмаслык буран булды, күп итеп кар яуды, концерт куя алмыйча кайттык. Әллә шунда салкын тиде инде, белмим.* – Аннан соң: *Картлыктыр инде...»* – дип өстәп куйды.

Илһам абыйның авырганлыгы йөзенә чыккан. Елмайса да, кыяфәте моңсу иде. *«20се Мәскәүгә барам, Хәйдәр Бигичевны искә алу кичәсенә, аннан 21ендә Лупповның иҗат кичәсендә җырлыйм әле»,* – диде Илһам абый. *«Бик авырга килмәсме?»* – дип сораган идем, Илһам абый: *«Әйбәт ул»*, – диде. Артистка сәхнә, тамашачы кирәк шул! Йа Ходаем, исәнлек бир җырчыбызга. Җырчы өчен сәхнәдә чыгыш ясау – үзе бер шифа.

Ноябрь ахыры, 2000 ел. «Чыга ул аңа кадәр...»

Яздан башланган иде, көзләргә кадәр начар хис иттем үземне. Врачларга да йөрдем, ачыклый алмадылар. Нервлар какшаган, дигән нәтиҗәгә килеп, «Новопассит» эчәргә куштылар. Аптекадан алдым да, хәзер хәлем рәтләнер инде болай булгач, дип, тизрәк шул даруны эчтем. Бүлмәдә берүзем. Бераздан, даруның тәэсире булдымы икән, ниндидер бер томан эчендә калгандай булдым, берни эшли алмыйм, кыймылдарга да көч тапмыйча, тик утырам. Куркыныч булып китте. *«Шушында үлеп китсәм?»* – дигән уйлар килде хәтта башыма… Үземне ничек тә урыннан күтәрелергә мәҗбүр итеп: *«Андый-мондый хәл була калса, кеше арасында булырмын, ичмасам»,* – дип, автобуска утырдым да өйгә кайтып киттем. Кайта торгач, хәлем рәтләнде. Икенче көнне тикшеренеп, сәбәбен ачыклап, дәвалану өчен хастаханәгә ятарга туры килде. Аннары, икенче авыру табып, операция дә ясадылар. Озакка китте. Барысы да узгач, ноябрь ахырларында гына эшкә чыктым. Бүлмәмә керешкә афишага күзем төште: Филармониянең концерт залы ачылышына багышланган, 18 ноябрьдә узган чара афишасында режиссер дип минем исем язылган. Бүлмәдәш кызлардан сорашкан идем: *«Илһам абый яздыртты,* – диләр. – *Без аңа Сезнең хастаханәгә кергәнне әйткәч: «Чыга ул аңа кадәр», – диде».* Гаҗәпләндем: минем бит Илһам абый белән беркайчан да авыруым, хастаханәдә дәвалануым турында сөйләшкәнем булмады. Шул ук вакытта шатландым да! Илһам абый яздырткан бит!

19 гыйнвар, 2001 ел. «Яныл китмәде...»

Илһам абый бүлмәбезгә керде, сөйләшеп утырдык: *«Уфадан кичә генә кайттым. Хәмдүнәнең концерты иртәгә бит инде, аны Филармония эшләмимени?*


ТАТАР ҖЫРЫН БАШКАРУЧЫЛАРЫНЫҢ
Илһам Шакиров
исемендәге
Халыкара конкурсы
II тур
24, 25 апрель - Филармониянең Концерт Залы (Павлюхин ур., 73)
Башлана 18 сәгать 30 минутта
III тур
26 апрель - Филармониянең Концерт Залы (Павлюхин ур., 73)
Башлана 17 сәгатьтә
ГАЛА - КОНЦЕРТ
28 апрель - С.Сәйдәшев исемендәге
Дәүләт Зур Концерт Залы (ГБКЗ)
Башлана 18 сәгать 30 минутта
КОНКУРС БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ, "ТАТАРСТАН" ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕРАДИОКОМПАНИЯСЕ, "ЯҢА ГАСЫР" ТЕЛЕРАДИОКОМПАНИЯСЕ КАТНАШЫНДА УЗА.
МӘГЪЛҮМАТИ ЯРДӘМ: "ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН", "РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН",
И. Шакиров

Ниндирәк була икән инде ул? Мин дә җырлармын, дигән идем Хәмдүнәгә, хуплап алмады, җырламам инде, – ди. Бераз тын торганнан соң: *– Янып китмәде...* – дип куйды Илһам абый. *– Алайса кирәкмәс инде дип уйладым».*

«Уфага баруым шул булды, – дип дәвам итте ул. *– Күзләремне караттым. Бер хирургны, Мулдашев фамилияле, бик мактаганнар иде, аңа эләгеп булмады. Икенчесенә күренергә туры килде. Күңелемне теге хирургка салган идем, булмады инде. Монысы да бик әйбәтләп карады үзе, әлләниләр белән. Кабинеттан-кабинетка йөрттеләр».* Бераз тын торганнан соң: *«Һаман да шул Мулдашевны эзләп барсаң, монысы алдында уңайсыз инде хәзер...»* – дип куйды Илһам абый.

Әңгәмәбез тагы да дәвам иткән булыр иде, безне бүлдерделәр. Илһам абыйны эзләп олы яшьтәге бер апа килгән иде.

8 февраль, 2001 ел. «Син «5»кә түгел, «6»га чишкән идең мәсьәләләрне...»

«Әллә нинди сызымнарны сыза идек. Нинди генә дәрәҗәгә күтәрми идек саннарны! Мәсәлән, 15 санының квадраты – 225. Ә 25нең квадраты 625», – дип сөйләп китте Илһам абый, бүлмәбезгә керә-керешкә. 5кә тамамланган саннарның квадратын тиз генә табу «сер»ен мин белә идем, ләкин Илһам абыйны бүлдереп, уңайсыз хәлгә куясым килмәде. *«Мин, укыганда, математикадан бик көчле идем. Әллә нинди катлаулы мәсьәләләрне чишә идем. Әллә нинди катлаулы юллар белән дә чишә идем. Өйгә биргән эшләрне чишә идем дә, берсенә дә бирми идем,* – дип көлә-көлә дәвам итте сүзен Илһам абый. *– Берзаман шулай контроль эш эшлибез. Мин бик катлаулы мәсьәләне бик катлаулы юллар белән чишеп бетердем. Артта утырган кыз, төрткәләп, күчерергә бирүемне сорый. Мин, моны жәлләп, бирдем инде. Шуннан икенче көнне укытучы икебезгә дә икеле куйган иде... «Мәсьәләне бик катлаулы юллар белән чишкәннәр, тик икесенеке дә бертөрле бит», – диде укытучы». «Илһам абый, әллә математик булырга теләк бар идеме?»* – дип сорап куйдым. *«Буласы идем шул,* – диде ул, *– Алабуга педучилищесына барып имтиханнар да бирдем. «Бишле»гә чиштем мәсьәләләрне, укырга керермен дип уйлаган идем. «Төрмә белән бәйле гаилә», – дип, кабул итмәделәр мине. Ул вакытта анда Люстиг дигән немец иде укытучы. Еллар узгач, Алабугага инде җырчы булып концерт куярга килгәч, Люстиг, минем янга килеп, гафу үтенде... «Син «5»кә түгел, «6»га чишкән идең мәсьәләләрне», – диде».* Бу сүзләреннән соң мин: *«Шундый моңлы тавышың була торып, нигә инде математик булырга хыялланырга?» – дияргә өлгермәдем, ул: «Математик булсам, җырлап йөреп булыр иде дип уйлый идем. Хәзер менә җырлап йөрим, математик булып булмый»,* – диде дә, бүлмәбездән чыгып китте.

«Фәрдия ханымга... Илһам Шакиров. 12 март, 2002 ел»

Кулыма Разил Вәлиев төзегән «Илһам» дигән китапны алдым да Илһам абый янына кердем. Исәбем шушы китапка аннан кул куйдырту, «тамга салдырту». *«Илһам абый, китабыңа кул куеп бир әле»,* – дидем мин. *«Мин язмаган ич аны»,* – ди Илһам абый. *«Беләм. Синең турыда бит ул. Килер әле андый көннәр дә, үзең язган китапка кул куйдыртырга да насыйп булсын»,* – дидем, китапны аңа сузып. *«И-и, барысы турында яза башласаммы...»* – дип куйды Илһам абый.

Алай да үтенечемне кире какмады. Башта бер юлга мин укый белмәгән гарәп язу-

ында, аннары: *«Фәрдия ханымга Филармониядә бергә эшләгән вакытлар истәлеге. Илһам Шакиров. 12 март, 2002 ел»,* – дип язып бирде.

Күргәннәрен, үзе генә белгәннәрен язып калдыра алдымы икән Илһам абый?..

Февраль, 2003 ел. Илһам Шакиров исемендәге халыкара җыр конкурсы

Филармониядә режиссер булып эшли башлавыма бишенче ел. 2002 елның ноябреннән мине директор урынбасары итеп билгеләделәр. Шул ук вакытта, инде җайга салынган «Таныш моңнар, таныш исемнәр» әдәби-музыкаль кичәләр циклын уздыруны да минем өстә калдырдылар. Февраль ае, Илһам Шакировның туган көн концертына әзерләнеп йөргән көннәр. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы Татар җырын башкаручыларның Илһам Шакиров исемендәге халыкара җыр конкурсын уздыру турында карар кабул итте. Конкурсны оештыру эшләре Филармония коллективына йөкләнде. Шул уңайдан мәдәният министры Илдус Тарханов әдәбият-сәнгать әһелләре катнашында «түгәрәк өстәл» уздырды. Конкурсның беренче (сайлап алу) турлары республиканың 8 зонасында узачагы, икенче-өченче турлары – Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә, гала-концерт Зур Концерт залында булачагы турында сүз барды.

Эшкә керештек. Мәдәният министрлыгы тарафыннан конкурс шартлары турында Низамнамә төзелде, жюри, оештыру комитеты билгеләнде. Оештыру комитеты әгъзалары арасында мин дә бар идем. Гала-концертның режиссеры итеп дә билгеләделәр. Сценарийсын да яздым.

Булдырам-булдырам, дип эшләп йөргәндә дүртәр сәгать кенә йокларга туры килде. Афиша, чакыру билетлары, җиңүчеләргә дипломнар эшләтү дә Филармония өстендә иде. Барысын да җиренә җиткереп башкардык. Югары сыйфатлы булды эшебез.

27 апрель, 2003 ел. «Сәфәргалиевага өч зарплата бу эшләре өчен, Әсгать Зөфәрович!»

Өченче тур концерт формасында узды. Конкурста катнашучылар барысы да сәхнә киемнәреннән, матурлар иде.

Өченче турны тәмамлап, жюри әгъзалары белән китеп барганда, оештыру комитеты рәисе, мәдәният министры И.Г.Тархановның Филармония директорына: *«Сәфәргалиевага өч зарплата бу эшне башкарып чыккан өчен, Әсгать Зөфәрович!»* – дип әйткәне хәтеремдә.

Әйе, булды, ди, өч зарплата... Алга китеп шуны әйтим: май ахырларында директор, мине кабинетына чакыртып: *«Йә, хәл итәргә кирәк, директор урынбасары булып каласыңмы, әллә режиссермы?»* – диде. Мин: *«Үзегез билгеләдегез ич директор урынбасары итеп, үзегез хәл итегез инде»,* – дидем. Аптырап куйды директор шул вакытта. Мондый җавап көтмәгән иде, мөгаен. Артыграк тырышканмын, ахры, директор урынбасары булып эшләгәндә... Мине кире үз урыныма кайтардылар.

28 апрель, 2003 ел. Гала-концерт

Зур Концерт залында Татар җырын башкаручыларның Илһам Шакиров исемендәге халыкара җыр конкурсының гала-концерты узды. Президентыбыз

Минтимер Шәймиев тә килгән иде. Алар Илдар Хәкимовка Гран-прины Илһам Шакиров белән икесе бергә тапшырдылар. Тантаналы, затлы булды концерт. Матур гына уздырдык. Илһам абыйның йөзе балкып тора иде ул көннәрдә. Афишаларның эчтәлеген, «Ш» хәрефенә охшатып ясалган конкурс билгесен дә ошатты Илһам абый. 2005 елда Минтимер Шәймиев ярдәмендә «Җыен» фонды рәисе Фоат Рәфыйков тырышлыгы белән нәшер ителгән альбом-китапка бизәлеш буларак кергән конкурс билгесе һәм афиша фотолары да шул хакта сөйли.

3 октябрь, 2003 ел. «Русчасы матур булмый икән»

Илһам абый мине кабул итү бүлмәсенә телефонга чакыртты. «Татарстан яшьләре»ндә чыккан мәкаләсен русчага тәрҗемә итүемне сорады. *«Фәрдия ханым, син русчаны бик шәп беләсең, миңа, Алсудан алып, мәкаләне тәрҗемә итеп бир әле»,* – ди. Мин: *«Ярар»,* – дидем дә, шул көнне үк тәрҗемәне эшләдем. Икенче көнне миннән тәрҗемәне алгач, Илһам абый: *«Үзем генә укыйм әле»,* – дип, бүлмәсенә кереп китте. *«Хаталар булмаса ярар иде»,* – дип уйлап калдым. Бераздан ул, безнең бүлмәгә кергәч: *«Русчасы матур булмый икән»,* – диде. Бәлки, мин ясаган тәрҗемә матур булмагандыр?..

3 февраль, 2004 ел

Филармония. Тиздән, 15 февральдә, Илһам абыйның туган көненә багышланган кичә узачак. Мин – кичәнең сценарий авторы, режиссеры һәм алып баручысы. Сценарий, программа әзер, җырчылар чакырылган. Тик менә сәхнә бизәлеше Илһам абыйга ошап бетми. Камал театрында эшләгән рәссамга тапшырган идек. Ул эшләгән эскиз академик рухтагы концертка бик әйбәт тә бит... Илһам абыйның милли бизәкле «задник» куйдыртасы килде. Шул теләгебезне җиткердек рәссамга.

6 февраль, 2004 ел. «Сиңа ярамый ул...»

Илһам абый белән кечкенә генә музей бүлмәсендә – аның эш урынында (без Илһам абый хакында «тере экспонат» дип тә шаярта идек үзара) бер сәгатьтән артык сөйләшеп утырдык. Бу еш эләкми, аның белән сөйләшергә теләүчеләр бик күп. Сүзебез 15 февральдә булачак концерт, аның сценарийсы турында барды. Илһам абый барысы белән дә килеште. Афишага исеме язылган Марат Хуҗинның көтмәгәндә вафат булын ишеткәч, аны искә алып видеоязма – бер генә куплет булса да, җырын бирергә сөйләштек. Узган елгы концертта катнашып, матур гына җырлаган иде.

Бераздан Илһам абый безнең бүлмәгә килеп керде дә бүлмәдәшемә: *«Бер анекдот сөйлим сиңа»,* – ди. Мин: *«Ай-яй, Илһам абый, бер сәгать яныгызда утырдым, миңа сөйләмәдегез»,* – дигән идем: *«Сиңа ярамый ул...»* – дип әйтеп куйды. Көлештек инде.

10 февраль, 2004 ел

Кичкә таба. Илһам абый өеннән шалтырата: *«Ә, Фәрдия җаным, үзең икәнсең. «Сөенечкә дисәм» җыры алдыннан бераз аның язылу тарихын да сөйләсәм ярыймы?»* – ди. Мин, ике дә уйламыйча: *«Бик әйбәт булыр, Илһам абый, сөйләрсең»,* – дидем.

Ул: *«Ярар»,* – дип, трубканы куйды. Шундый бөек кешенең миннән рөхсәт соравына исем китте. Сүз 15 февральдә туган көн концертында җырланачак «Сөенечкә дисәм» (Шәүкәт Галиев сүзләре, Илһам Шакиров көе) җыры турында бара иде.

14 февраль, 2004 ел. «Синең шикелле матур итеп җырлап булмас инде»

Бүлмәбезгә Фәрит Хатыйпов килеп керде. Керешкә: *«Илһам абыйга җырымны бирдем әле. Җырлап та күрсәттем. «Синең шикелле матур итеп җырлап булмас инде», – диган иде. «Менә, җырымны яздырган кассетаны калдырам, шуннан өйрәнерсең», – дидем үзенә»,* – дип, рәхәтләнеп көлә Фәрит абый. Артистлар арасында бик күп мәзәк йөри. Алар моңа күнеккән. Очрашканда һәрвакыт диярлек берберсен «төрттерешеп» торалар. Шуңа да Фәрит Хатыйпов Илһам абыйның шаян сүзләрен җавапсыз калдырмаган. Сүз «Сарман юллары» (Фәрит Хатыйпов көе, Дамир Гарифуллин сүзләре) җыры турында бара.

25 февраль, 2004 ел

Эш урыным Илһам абый бүлмәсе янында, дигән идем. Шуңа күрә ачык ишектән (үзем дә бүлмәдән чыгарга тора идем) аның үтеп киткәнен күреп, исәнләштем: *«Ни хәлең бар, Илһам абый? Бу көннәрдә күргән дә юк сине...»* Илһам абый, елмаеп: *«Һаман бер-береңә елышып кына йөрергә димәгән»,* – дип җавап бирде. *«Әйе, бераз күрешмичә яшәсәң дә ярый»,* – дидем мин дә. Көлештек. Шунда ук мин Илһам абыйга 19 апрельдә Ләбиб Айтугановны искә алу кичәсе буласын әйттем. *«Ике җырын беләм»*, – диде ул. Аннан соң 22 апрельдә Тукайның туган көненә багышланган кичә булачагын әйттем. *«Оркестр да катнашсын»,* – диде Илһам абый. Илдус Әхмәтҗановка шигырь сөйләргә бирәбез, дип сөйләштек.

Декабрь, 2006 ел. «Юкка киттең Филармониядән...»

2006 елда Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе Татарстан Республикасы фольклор музыкасы дәүләт ансамбле сәнгать җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Айдар Фәйзрахмановны Тукай премиясенә тәкъдим итте. Шул уңайдан комиссия төзелде, утырышка мине дә чакырдылар. Кирәкле кагәзьләр әзер булгач, аларны тапшырырга дип, комиссия әгъзаларының берничәсе белән, кечкенә автобуска утырып, Мәдәният министрлыгына киттек. Автобуста Илһам абый белән янәшә утырдык. Ул шунда: *«Юкка киттең Филармониядән...»* – дип әйтеп куйды. Киткәнемә ике елдан артык вакыт узган иде инде ул көннәрдә. «*Башкача булмый иде, Илһам абый»*, – дидем мин аңа. Мәдәният министрлыгы урнашкан бина янына килеп җиткән идек инде. Сүзнең дәвамы булмады.

Тукай премиясенә документлар кабул итү бүлмәсен күз алдыма иркен, якты, гөлләр белән бизәлгән, диварына Тукай портреты эленгән тантаналы, атмосфералы бүлмәдер дип уйлаган идем. Алай түгел икән...

Апрель башы, 2007 ел. «Бер генә сүзен дә үзгәртмәсеннәр...»

Гадәттә, Тукай премиясенә кандидат турында күренекле шәхесләр, әдәбиятсәнгать әһелләре үз фикерләрен көндәлек матбугатта язып чыгалар. Илһам Шаки-

ров та Айдар Фәйзрахманов турында язды. Кыска гына, әмма саллы эчтәлекле иде ул. Илһам абый шул язмасын «Шәһри Казан» газетасына илтеп тапшырырга миңа кушты. Кулыма тоттырганда: *«Бер генә сүзен дә үзгәртмәсеннәр, кыскартмасыннар»,* – диде.

Язманы тотып редакциягә килгәч, Әгъзам Фәйзрахманов янына керергә тиеш булдым, шулай аңлаттылар. Язманы карагач та: *«Менә бу әйбәт, ичмасам – Илһам Шакиров!* – дип куйды Әгъзам абый. *– Алайса күз күрмәгән, колак ишетмәгән бер кешенең исем-фамилиясен куеп мәкалә алып килгәннәр. «Мин бу кешене белмим, язганын газета битләрендә бастыра алмыйм. Ә Айдарны, аның иҗат эшчәнлеген күптән беләм», – дип әйттем үзләренә. Алмадым язганнарын».* Андый язманы алмау гына түгел бу, Әгъзам абый, бу – намуска тап төшермәү, вөҗдан саклау! Егетлек!

Шул язма булгандыр инде, җаен табып, укучыга тәкъдим итү формасын үзгәртеп, интернетта чыгарганнар иде аны... «Пычрак» иде ул язма. Нишлисең бит, «эчебез поша, исәнендә берәребез гөрләп үскәнгә...» (Равил Фәйзуллин, «Сәйдәш» поэмасыннан).

Ул «пычрак» хатка җавап итеп укучыларга Рәдиф Гаташ сүзләрен ирештерәсе килә: «Гайбәтләргә ышанмагыз! Кеше һәрчак гайбәтләрдән өстенрәк...»

«Шәһри Казан» газетасында Илһам абыйның «Милләтне горурлык яшәтә» дигән язмасы (17 апрель, 2007 ел) үзгәртүсез басылып чыкты.

Сәхнәгә соңгы чыгуы

Илһам Шакировның туган көн концертларын үткәрүне Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе 2002 елда башлап җибәргән иде. Беренче өч концертны уздыру миңа насыйп булды. Филармониядән киткәч тә Илһам абыйның туган көненә багышланган концертларны үткәрергә чакырдылар әле – 2013 һәм 2014 нче елларда. Алары да тамашачыларга бик ошады, матур булды. 2014 елның 15 февралендә Илһам абыйның Филармония сәхнәсенә соңгы тапкыр чыгып җырлавы булган икән...

2018 елда Айдар Фәйзрахмановның «Олы юл әйтте...» дип исемләнгән авторлык әдәби-музыкаль кичәләр циклыннан берсе – «Кара урман аша» дигәне Илһам абыйның туган көненә багышланды. Илһам абыйсыз гына узды ул, сәламәтлеге какшау сәбәпле, катнаша алмады. 2019 елның 16 гыйнварында 83 яшендә Илһам Шакиров мәңгелеккә китеп барды...

«Сирәктер ул, ак чәчәкләр белән, үз көйләрең белән күмелү...» (Равил Фәйзуллин, «Сәйдәш» поэмасыннан.)

Шундый сирәкләрнең берсе – Илһам Шакировны соңгы юлга озатканда аның «Мәңгелеккә китеп барам» (Габделхак Игебаев сүзләре, Илһам Шакиров көе) җырының язмасы яңгырап торды...

«Тәүге таныш офыклардан
Ерагая һаман арам...
Мин бит сөю җырын җырлап,
Ил халкының күңелен нурлап,
Мәңгелеккә китеп барам...»

Авыр туфрагың җиңел, урының җәннәттә булсын, Илһам абый! ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2022

Җуелмас хәзинә

«Умырзая» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Тәртип радиосы

Умырзая

(Әхмәт Фәйзи сүзләре, татар халык көе)

Боз катлавы эрегәч, җир өстенә
Умырзая чыга, карагыз:
Умырзая чыга,
Умырзая калка,
Умырзая суза сабагын.

Боз катлавы кебек көнкүрештән
Чыгасым ла килә тиз(е)рәк,
Умырзая кебек,
Умырзая кебек,
Умырзая кебек тиз үрләп...

Умырзая бик тиз үсеп чыга,
Бик аз гына яши тураеп,
Умырзая бик тиз
Башын аска ия,
Умырзая сула моңаеп...

Юк, мин яшәр идем, җәй ясаучы
Зур чәчәкләр белән җыелып,
Юк, мин үлмәс идем
Умырзая кебек,
Умырзая кебек боегып...

Шагыйрь Әхмәт Фәйзи сүзләренә җырлана торган бу көйне 1955 елда Татарстанның Буа якларыннан баянчы **Оркыя Ибраһимова** отып кайта. Радиокомитетта эшләүче бер иптәш аңа:

– Бу көй Җәүдәт Фәйзинеке булырга тиеш, – ди.

Әхмәт Фәйзи (Әхмәт Әхмәтсафа улы Фәйзуллин, 1903-1958, драматург, прозаик һәм шагыйрь, тәнкыйтьче, публицист, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты (1958), атаклы «Умырзая» жырының текст авторы). 1948 ел. ***Кәгазь, карандаш. Бакый Урманче эше***

Шуннан соң баянчы аны композитор Җ.Фәйзигә уйнап һәм җырлап күрсәтә.

– Миңа таныш көй түгел бу, – ди аңа композитор. – Дөрес, Мәскәүдә укыган чакта мин Әхмәт Фәйзинең шушы «Умырзая» шигырен музыкага салган идем салуын. Аны Марзия Сафина белән Рәшит Ваһаповлар җырлап та йөргән иде. Ләкин ул, умырзая чәчәкләре кебек, гомерсез булды...

Җәүдәт Фәйзи, әлеге җырның гомере озын булачагын әйтеп, Оркыя Ибраһимованы тынычландыра. Озак та үтми, Оркыя Ибраһимова Зифа Басыйрова белән бергә бу яңа көйне радио аша халыкка тарата.

Әлеге җыр турында язучы **Гомәр Бәширов** болай дип язган иде: *«Җырлар дөньясында кайвакыт таң калырдай гаҗәеп һәм гыйбрәтле хәлләр дә булгалый. Әхмәт Фәйзинең «Умырзая» дигән шигыре бар иде. Әмма шагыйрь үзе исән чагында ул җырның беркайда да ишетелгәне булмады шикелле. Әхмәт Фәйзинең вафатыннан соң күп тә үтмәде, каяндыр, ничектер, «Умырзая» дигән җыр килеп чыкты. Бу көй шундый моңсу, анда шундый юксыну аһәңнәре ишетелә ки, әйтерсең, халык бу көйне вакытсыз дөнья куйган сөекле шагыйренең истәлегенә багышлап махсус рәвештә иҗат иткән»* («Гөлҗамал кайсы як кызы?». – «Казан утлары», №3. – 1969 ел).

Тәртип радиосы

*Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан күзгә» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – **Гөлфия Мөхәммәтгәрәева**) материалларына нигезләнеп, **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Усак

Усак – яшькелт кайрылы, түгәрәк яфрагы кырыйдан вак киртләч, йомшак агач.

Усак яфрак ярмастан ук чәчәк ата.

Татарларның хуҗалыгында, бигрәк тә Татарстанның көньяк-көнчыгышында яшәүчеләрендә нарат, чыршы кебек төзелеш өчен кирәкле агачларга кытлык булганга, күп төзелешне, шул исәптән йорт салуны да усак белән башкарып чыкканнар. Усак чагыштырмача нык агач исәпләнә һәм, коры торса, аннан салынган өйләр дә шактый вакыт череми саклана.

Юкә табу авыр булган төбәкләрдә усактан калаклар, кашыклар, май язу өчен гөбе һәм башка кирәк-ярак ясаганнар. Шул исәптән малларга башак бирү өчен тагаракларны да усактан ясарга тырышканнар, чөнки кипкән усак ярылмый, ә башка агачлар, вакытлар үтү белән, бигрәк тә җәй көннәрендә, яргалана-чатный.

Татар аңында усак образы үзенчәлекле урын алган. Усак яфракларының үзара лепердәшеп утыруын алар изге эш дип санаганнар. «Усак җилсез дә калтырый» гыйбарәсе шуңа ишарә итә, чөнки алар Аллаһыны зикер кылып утыра икән. Татар зиратларында каберлек өстендә усак күплеге дә шул ышанулар белән аңлатыла: «Әгәр кабергә усак агачы утыртсаң, аның һәрбер яфрагы, җил искән саен, лепер-лепер килеп, зикер әйтеп торыр, ди».

Җен алмаштырган авыру баланы, ишек тупсасына салып, усак ботагы белән суккалаганнар.

Усакны уенчыклар, тартмалар, мичкә һәм төрле савыт-саба ясау өчен, шулай ук бура бурау өчен файдаланалар. Шырпы ясау сәнәгатендә исә бары тик усак агачы гына кулланыла, чөнки усак шырпы тиз кабына, тигез янып китә, төтенләми. Сөремләнеп-корымланып янмаганлыктан, усак утыны кирпеч һәм чүлмәк яндыру эшендә дә файдаланыла. Усак эшкәрткәндә дә җиңел эшкәртелә, ансат ярыла, кипкәннән соң яргаланмый-чатнамый. Кәгазь, картон эшләгәндә дә чыршыга билгеле күләмдә усак кушалар. Шушы ук катнашмадан целлюлоза эшлиләр, ә ул исә ясалма ефәк алу өчен китә. Усак чәчәгеннән умарта кортлары бал җыя.

Сәхифә «Татар халкы традицияләрен саклау һәм үстерү «Татар ядкярләре» шәхси учреждениесе (җитәкчесе – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе ***Фәнзилә Җәүһәрова****) белән берлектә әзерләнде.* ■

Усак турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Усак дәвалый

Мәшһүребез Каюм Насыйри үзенең «Хәвасе нәбатат» («Шифалы үләннәр») китабында усакның шифасы турында болай дип яза: «Усак агачы (осина), гарәпчә *шәҗәр-л-хәвар* диләр, бик билгеле агач.

Дару өчен усак агачының бөресе кулланыла. Аны яз көне яфракка йомарлангач, яфрак чыгармас борын җыярга кирәк. Тәме бик ачы. Авыртуны бетерә һәм йомшак тота торган үзлеге бар.

Артыннан кан килә торган кешегә кайнатып эчерсәң, файдасы күп, кан китүне туктатыр.

Коры сызлаулар өчен усак бөресен кайнатып, суы белән сызлаган җирләрне усаң, тынычландырыр.

Байтарлар (ветеринарлар) корчаңгы булган атны, усак кайрысы кайнатып, суы белән юалар».

Усак кайрысында углеводлар (глюкоза, фруктоза, сахароза һ.б.) бар.

Усак кайрысы төнәтмәсе (экстракт) описторхоздан дәваланганда бик файдалы. Цистит, геморрой булганда, үпкә яки ашказаны ялкынсынганда, тамак төбе шешкәндә, йөткергәндә, шикәр авыруы белән интеккәндә, сидекне тоту авырлашканда да усак кайрысы кулланалар.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Усак бөреләре

Усак кайрысы

Усак

«Май уны»ннан соң чәйгә тәмле сый

«Чәй эчүдә – өй яме», «Өч чынаяк чәй эчсәң, өч кешелек көч җыясың», «Чәй ике кешене ярата» һәм башка шундый мәкаль һәм әйтемнәр белән татарлар борынгыдан ук үзләренең чәй эчү йоласын якын күрүләрен белдертәләр. Бу күркәм йола татарлыкның нигезеннән үк килә дисәң дә була, чөнки ул туган ягыбызның кайсы гына төбәгендә, нинди генә шәһәрләрендә сакланып калмаган. Әлеге матур күренешнең эзләре дә безне Буа ягына, аның авылларының тарихына илтте.

Буа җирләренең тарихы Казан ханлыгыннан башланып китә һәм Явыз Иван яулап алганнан соң ул Россия составына кушыла. Шәһәргә нигез салынуның да датасы билгеле – Буа шәһәре Екатерина II указы белән 1780 нче елның 15 сентябрендә барлыкка килә, ул соңрак губерна итеп үзгәртелә. Биредә күпчелекне татарлар һәм чуашлар тәшкил итә, рус крестьяннары да була.

Татар халкы чәй эчү гадәтен гади күренеш кенә түгел, ә сихри, тынычландыргыч һәм көч бирүче йола дип санаган. Шуңа да чәй ясау буенча төрле үләннәр, тәмләткечләр һәм төнәтмәләр кулланырга тырышкан. Буа якларында бу күренешне тулаем тасвирлаган бәйрәм дә бар икән. Буа районының Каенлык авылында бүгенге көнгә кадәр «Май уны» дип аталган бәйрәм сакланып калган. Бу көнне авыл халкы урманга бара, төрле үләннәр, чәчәкләр җыя, бәйрәм итә. «Май уны» турында хәтта шигырьләр дә иҗат ителгән. Мәсәлән, биредә мондый шигъри юлларны искә төшерделәр:

«Бәйрәм ясый халык урманнарда «Май уны»нда,
Андый бәйрәм юк башка җирдә беркайда да.
Халык шифалы үлән җыя бу бәйрәмдә,
Кунак чакыра, башка авыллардан җалык җыя».

Самавыр, шифалы үләннәр һәм кунаклар – Буа җирлегендә яшәгән татарлар әлеге җыелманы бик яхшы аңлый. Бу – тизрәк чәй кайнатып, өстәлгә төрле сыйлар әзерләр вакыт җитте дигән сүз. Гадәттә, гади халыкның зур, күп ингредиентлы ризыклар, тәмтомнар әзерләргә вакыты да, кереме дә булмый. Андый чакта татар хатыннары тиз пешә, өстәлдәге бал, җиләктән кайнатма белән ашап була торган һәм кыйммәтле булмаган камыр ризыгы әзерләү ягын караган. Буа якларында бу ризык юка дип атала. Әйдәгез, без дә юканы Буа районыннан килгән, әмма бүгенге көндә бераз үзгәргән рецепт белән пешереп карыйк.

Кирәкле ингредиентлар:

- 600-800 г он;
- 2-3 йомырка;
- 200-250 мл сөт;
- ¼ чүпрә (шулай ук 20 г катык та кулланырга була);
- 50 г шикәр комы;
- 2 г чәй содасы;
- 100 г атланмай;
- ванилин (теләгегез буенча);
- тоз.

Эш барышы:

1. Камыр әзерлибез. Савытка чүпрә (яки катык), сөт салабыз, йомырка сытабыз, шикәр комы, тоз, эретелгән атланмай өстәп, яхшылап болгатабыз.
2. Шуннан соң серкә (уксус) белән сүндерелгән сода, ванилин салабыз һәм он өстәп, камыр басабыз. 20 минут чамасы үзләндерәбез. Аннары аны 100 г.лы кисәкләргә бүләбез һәм түгәрәк формага китерәбез.
3. Камырны 1,5 мм калынлыкта җәябез. Һәр түгәрәкне ике яктан да алсу төскә кергәнче майлы табада пешерәбез.
4. Кайнар юкаларны табынга сары май белән һәрбер ягын майлап, бер-берсе өстенә өеп чыгарабыз. Бал, кайнатма, повидло белән бирәбез.

Юканы татар халкы элек-электән бик яратып табыннарына чыгарган. Буа төбәге халкы оста катык ясаучылар булып дан казанган, шуңа күрә алар күбрәк әлеге рецептта аны куллану ягын карый.

Юка, алда әйтелеп узганча, табынга чәй янына куярга дигән камыр ризыгы булып саналган һәм тиз пешерелгән. Шуңа сез дә өйдәгеләрегезне бу тәмле сый белән куандырырга ашыгыгыз!

*Сәхифәне **Айзилә Сабирова** әзерләде.* ■

Юка әзерләү турындагы видеоязманы шушы QR-код ярдәмендә кереп карарга мөмкин.

Көлке куа килә...

Илдар Юзеев. *Зөлфәт Хәйруллин шаржы*

Илдар Юзеев (1933-2004)

Ниһаять!

Революция,
Ниһаять, бездә!
Алга сикереш –
Тәрбиябездә!
Ата-аналар
Тынычлансыннар,
Бала калдырып,
Ялга барсыннар.
Бакчага бала
Йөрмәсен барып,
Дәү әниләре
Илтмәсен арып.
Кем үз постында
Борчуга төшкән –
Китә аласыз
Мөһим бу эштән.
Газапланмагыз
Процент җыеп,
Мескен балага
Икеле куеп.
Нәшрият, туктат,
Чыгарма китап.
Кино-театр,
Ишегеңне яп.
Тәрбиянең иң
Мөһим чарасы:
Табылды инде
Ата-анасы!
Ниһаять, бала
Гел өйдә ята:
Телевизор – ана,
Кампитр – ата!

2002

Гәрәй Рәхим (1941-2021)

Гаилә этюды

Тышта – буран котыра.
Өйдә – мин...

1974

Туфан Миңнуллин (1935-2012)

Без шундый халык инде

Бөтенесен яратабыз,
Барысын иш итәбез.
Безгә «осел» дигәнне дә
«Асыл» дип ишетәбез.

Мөхәммәт Мәһдиев (1930-1995)

Өйләнгәч белерсең

Сикертән Г. абзый хатынын киткән саен барып ала икән. Бервакыт барып алмаган, хатыны үзе кайткан.

– Ник килеп алмадың? – дип дулый.

– Әнә Сөнгатулла шәкерт котыртты, – ди юаш Г. абзый.

Хатын әти янына керә. Әтинең каникулга кайткан вакыты икән.

– Ник кеше котыртасың син? Менә үзең өйлән әле, аннары белерсең, – дип сугә.

Шуннан соң хатын бер тапкыр да китми.

Әхсән Баян (1927-2013)

Төшке аш

Минем оныгым Сәрвиназ булган хәлләр турында сөйләгәнне ярата. Үзе дә сөйли. Авылда ишетеп кайткан шундый бер хәлне исенә төшереп сөйләде.

Хуҗабикә төшкелек аш әзерләгән – үзләренә дә, чучкага да. Ире абзар тирәсендә бик мавыгып эшләп йөри икән. Бер чакыра апа ирен, ике чакыра. Һич керми ир, эштән аерыла алмый. Аптырагач, үзе дә чыгып эшкә керешә.

Күпмедер вакыттан соң ир үзе генә кереп ашап чыга.

Бераздан хатын өйгә керә дә, яңадан чыгып, күтәрмәдән җан-фәрманга кычкыра ди:

– Нишләдең син, ә?! Чучкага дигән ашны ашап чыккансың. Хәзер нәрсә ашатыйм инде мин аңа?!

Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

Тормышка ашмас хыял

(Мәзәк)

Данлыклы Саба урман хуҗалыгы директоры Васыйл Гыйззәтуллин бала вакытта әнисе казыган бәрәңгене чүпли икән. Әтисе Нурулла абзый лесник булгач, бик өйдә тора алмаган, күрәсең.

Аяз, матур, кояшлы көзге көн була бу. Күктә сирәк-мирәк самолетлар да оча икән. Шуннан кечкенә Васыйл әйтеп куйган:

– Үсеп җитиең дә, йә лесник, йә летчик булыең...

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №9 сентябрь 2022



БЕЗ БАРЫБЫЗ ДА – БАЛАЧАКТАН

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны, озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Каюм Насыйри (1825-1902)

Күләгә

(Мәсәл)

Бер сабый бала, кояшлы көн бер җирдә йөргәндә үзенең күләгәсен күреп, күләгәсе артыннан җитәмен дип бара. Ул барган саен, күләгә һаман алга китә. Бу баланың ачуы килеп, күләгәнең өстенә басарга теләп йөгерә башлый. Ул йөгерсә, күләгә дә йөгерә. Бала тәмам арый, янә киткән урынына кайтып барганда, артына әйләнеп караса, күләгә артыннан ияреп килә: «Һи, мин юкка йөгердем, ул миннән үзе дә калмый икән!» – ди.

Марзия Фәйзуллина (1930-2021)

Сыер рәсеме ясадым

Башта ике түгәрәкне
Ак кәгазьгә төшердем.
Аннан аларны гәүдә һәм
Баш итеп килештердем.

Коточкыч итеп ясадым
Зур-зур ике мөгезен.
«Үгез булып чыкмасмы?» – дип,
Куркып калдым мин үзем.

Усал үгез итмәс өчен
Ярый юлын тиз таптым.
Сөтле имчәкләр ясадым,
Аннан койрык та тактым.

Күзләр, аяклар ясадым...
Кабул итеп алыгыз.
Инде һәркөнне иртә-кич
Җылы сөтен савыгыз.

Әйдәгез, уйныйбыз!

Буяу сатыш

Балалар, бер рәт хасил итеп, тезелешеп утыралар. Арадан берсе буяу сатучы, берсе буяу алучы була. Буяу алучыны икенче бүлмәгә чыгарып җибәрәләр дә, буяу сатучы, аңа ишеттермичә генә, монда калганнарга төрле буяу исемнәре (ак, кызыл, яшел, көрән һ.б.) кушып чыга. Шуннан алучы «ишек кагып керә»:

– Дөбер-дөбер!

– Кем бар?

– Олаучы бар.

– Ни кирәк?

– Җеп мандырам, буяу кирәк.

– Нинди?

– Сары *(яки нинди дә булса башка төсне әйтә)*.

«Сары» дигән буяу тора да йөгерә башлый. Алучы тота алса, аның урынына утыра. Тота алмаса, яңадан буяу ала. Сары буяуга яңа исем кушалар.

Әби битен юмаган

(Такмаза)

Әнчи, чумадан,
Әби битен юмаган.
Әби битен юар иде,
Комганда су булмаган;
Комганда су булыр иде,
Кызы суга бармаган;
Кызы суга барыр иде,
Көянтәсе булмаган;
Көянтәсе булыр иде,
Әтисе ясамаган;
Әтисе ясар иде дә,
Агачлары булмаган;
Агачлары булыр иде,
Урманчы агач бирмәгән;
Урманчы агач бирер иде,
Акчалары булмаган;
Шуның өчен әбекәй
Битен юмый башлаган.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

АВГУСТ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Августта атаклы Үтәмешевләр династиясе вәкиле, күренекле педагог, җәмәгать эшлеклесе, хәйрияче Маһруй Үтәмешевага (1862-1904) кагылышлы яңа китап дөнья күрде. Авторлары мәшһүрләребез Галимҗан Баруди һәм Шәһретдин Шәрәф булган әлеге китап (бастыру өчен җаваплы – тарих фәннәре кандидаты Нияз хәзрәт Сабиров, басмага әзерләүче – филология фәннәре кандидаты Айдар Гайнетдинов), ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең Кукмара районы мөхтәсибәте ярдәмендә, «Иман» нәшриятында басылды.

● 3 августта, Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты Равил Габдерахман улы Фәйзуллинга нисбәтле, инде 1979 елдан бирле дәвам итеп килгән «Фәйзуллин йөзүләре» булып узды. Лаеш районының Атабай һәм Ташкирмән авылларында үткән чараларда ТР Дәүләт Советы депутаты, ТР Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, әдипләр – Зиннур Мансуров, Ләбиб Лерон, Зиннур Хөснияр, Илсөяр Иксанова, Марат Закир, журналистлар – Римзил Вәлиев, Атлас Гафиятов, Данил Сәфәров, Данил Гыйниятов, Лилия Йосыпова, галим Булат Хәсәнов, олпат әдипнең уллары Алмаз белән Газиз һәм оныклары катнашты.

● 4 августта ТР Язучылар берлегендә әдәбият галиме, тәнкыйтьче, педагог Рифат

Хәсән улы Сверигинны 90 яше тулуы белән котладылар.

● 4 августта ТР Язучылар берлегендә Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еники әсәрләренә нигезләнгән нәфис фильмның (режиссеры – Ирек Хафизов) кайбер эпизодларын төшерделәр.

● 5 августта Казанның «Пирамида» күңел ачу үзәгендә журналистларның XXV «Бәллүр каләм» бәйгесенең йомгаклау чарасы булып узды. Быел Гран-прига журналист, галим, филология фәннәре докторы, Казан (Идел буе) федераль университетының Социаль-фәлсәфи

фәннәр һәм гаммәви бәйләнешләр институты Журналистика һәм медиакоммуникация югары мәктәбенең милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы мөдире Васил Заһит улы Гарифуллин лаек булды.

● 10 августта «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Кама Тамагы районындагы гипс руднигында булып, аның тарихы һәм эшчәнлеге белән таныштылар.

● Августта «Иман» нәшриятында «Дүртенче Мәчкәрә укулары» дигән китап-җыентык (басмага әзерләүче – Нияз хәзрәт Сабиров) дөнья күрде.

● 17 августта Кукмарада «Бишенче Мәчкәрә укулары» үтте. Чарада катнашучылар (алар арасында «Безнең мирас» журналы хезмәткәрләре Ләбиб Лерон һәм Ленар Гобәйдуллин да бар иде) Мәчкәрә авылы зиратында, Авыл тарихы музеенда һәм быел төзекләндерелә башлаган атаклы мәчеттә булдылар.

● 17 августта Кукмараның Туеш авылында «Хидаят» тәрбия үзәген ачу тантанасы булып узды. Чарада Кукмара муниципаль район хакимияте башлыгы Сергей Димитриев, Татарстанның баш казые, Балтач районы имам-мөхтәсибе Җәлил хәзрәт Фазлыев, Кукмара районы имам-мөхтәсибе Рәдиф хәзрәт Тимергалиев, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, Бөтендөнья татар конгрессының Казан муниципаль шәһәре җирле иҗтимагый оешмасының җитәкчесе Фәрит Мифтахов катнашты һәм чыгыш ясады.

● 20 августта Чүпрәле районының Мунчәли авылында «Мунчәли укулары» булып үтте. Әлеге чарада республикабызның күренекле дин әһелләре, галимнәр Индус һәм Энгель Таһировлар, җырчы Миңгол Галиев һәм «Безнең мирас» журналы хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин катнашты. ■

МИРАСВОРД

Кап, капчык (иск.)

Башкорт халык биюе

Сунарчы

Җәйнең бер көне ... туйдыра

Калмык ханы

... Гыйззәт (әдәбият галиме, тәнкыйтьче)

Рамазан аенда укыла торган намаз

Халык авыз иҗаты әсәре

... өй / Агач чиләк (диал.)

Мәҗүси потханә, табыну урыны (бор.)

Баренц диңгезенә коючы елга

Фәннур Сафин туган авыл

Хан сугышчысы

Батыр шунда беленә

Ау эте (диал.)

Урта гасырларда: рыцарьлар ярышы

Иван Тургенев повесте

Тәгам җыю, ризыклану

Тарантаста утыру өчен чыбыктан үреп ясалган әрҗә

... Карнай

Сәгыйть ... (башкорт язучысы)

Кәрим Тинчурин драмасы

Грузия акчасы

Язучы ... Галиев

Хәния Фәрхи җырындагы елга

Хәмзә Хәкимзадә ...

Морза

Язучы, «Утызынчы ел» романы авторы

... Купала

Ямь, матурлык (диал.)

Сакал үсә торган урын



Шагыйрь ... Идиятуллин

Үзбәк күмәче

Фатих Кәрим поэмасы

Идел-... штаты

Ашлык әрҗәсе

Диктор ... Абдулла / ... Бикчәнтәева

... Туишева

Анатоль ... (француз язучысы)

8 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Сулдан уңга: тәрәш, кумә, Тутай, Рекс, рун, «Кыямәт», дуадак, әпә, апа, зир, кына, имче, чиру, Киров, дус, оту, Оноре, Таһиров, Аван, тумача, Икар, шура.
Өстән аска: «Татарлар», кот, Ита, ротонда, груһ, Иктин, Шәйхразыев, ук, дин, Кормаш, карачы, ару, Ык, карья, ир, наза, Мәхмүдов, «Мәктәп», ура, тәберсен.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»

елъязмасы / сентябрь

Гыйльфан Батыршинның «Дан аллеясы»ндагы бюсты. Биектау

635 ел элек (1387)

Туктамыш хан көз башында, биниһая зур гаскәр туплап, Мәвараәннәһергә – Аксак Тимергә каршы яу сәфәренә кузгала.

625 ел элек (1397)

Идегәй морза бөтен Алтын Урда гаскәрен үз кул астына берләштерә һәм Туктамыш ханны Алтын Урдадан куып җибәрә.

425 ел элек (1597)

Россиядә «крепостное право» тәртибе кертелә. Авыл халкы, җирбиләүчеләр карамагына беркетелеп, яшәгән урыннарында калырга мәҗбүр ителә, урыс илендә «яңа колбиләүчелек» дәвере башлана.

105 ел элек (1917)

Сентябрь аеннан Хукәнд (Хоканд) шәһәрендә (хәзерге Үзбәкстанга карый) татар һәм үзбәк телләрендә «Ил байрагы» дип аталган милли шурачылар газетасы чыга башлый. Нашире – «Гайрәт» ширкәте, мөхәррире – Булат Салиев.

90 ел элек (1932)

Әстерхан шәһәрендә татар драма театры ачыла.

80 ел элек (1942)

«Совет әдәбияты» журналында Фатих Кәримнең «Саратский яшел гармун» («Кыңгыраулы яшел гармун») әсәре дөнья күрә.

55 ел элек (1967)

15 сентябрьдә татар совет шагыйре Әхмәт Ерикәй (1902-1967) вафат була.

«Казан утлары» журналында Атилла Расихның «Ямашев» романы басыла башлый.

30 ел элек (1992)

18 сентябрьдә татарлардан беренче Советлар Союзы Герое Гыйльфан Әбүбәкер улы Батыршинга (1913-1947) бюст ачыла. Әлеге тантанада язучы Шамил Рәкыйпов катнаша.

*Журналга **Айдар Закиров** әзерләде.* ■



Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Содержание. Сентябрь 2022

И останется в мире слово моё...: Гумер Тулумбай.

Историческое наследие: «Как мы стали славянинами и русскими?» А.Чанышев; «Татарский боцманмат». Г.Хисамиев; «Хан Данияр». Л.Губайдуллин; «Путешествие 1992 года». Т.Ильяси; «Татарский мир 100 лет назад»; «Мухаммадия». Б.Урманче.

Татарский мир: «Ранис Камартдинов: «Нужны ясномыслящие умелые люди!»

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Мнение и наблюдения о Мураде Рамзи». Х.Миннегулов; «Буинский край – религиозный край». Р.Каюмов; «Религиозный ученый Нургали Хасанов». Р.Амишов; «Ислам. Религиозный словарь»; «Хадисы пророка Мухаммеда (с.г.в.)». А.Рахими; «Уроки религии». С.Бикбулат.

Литературное наследие: «Нури Арслан»; «Отражение эмиграционного движения в татарской поэзии и Исхаки». Т.Галиуллин; «Кыйссасел-анбия» и тюркский мир». Р.Исламов.

В глубинах памяти: «Поломничество». Л.Лерон; «В памяти, до сих пор в памяти!»

Алхәбәр:

Әхмәд бай салдырган «Хөсәения» мәдрәсәсе бинасы. XX гасыр башы фотосы
(«Бакыйга мәхәббәте куәтле иде». Ләлә Мортазина)

«Безнең мирас» галереясы

Хәсән Туфан. 1986 ел. ***Язучы Марсель Галиев эше. Тушь, 29х21 см***

Бакый Урманче. «Ибне Фадланның Болгарга килүе». 1973 ел

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:
- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.